# Казан утлары

50

11

НОЯБРЬ 1967

## *Котлыйбыз!*

*Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре һәм хезмәт иләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә актив катнашулары өчен хөкүмәтебез язучы Габдрахман Әпсәләмовны Ленин ордены белән, язучы Атилла Расихны „Почет билгесе“ ордены белән бүләкләде.*

*Татарстан язучылары каләмдәш дусларын бу зур шатлык белән тәбрик итә, тагы да зур иҗат уңышлары һәм ныклы сәламәтлек тели.*

# КАЗАН утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

11

НОЯБРЬ
1967

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## Бу санда:

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ШИГЫРЬЛӘР

М. Гафури. Бир кулыңны! Шигырь . . . . . 3
А. Расих. Ямашев. Роман . . . . . . . . . . 4
Х. Туфан. Бәйрәмгә килгәндә. Шигырь . . . . 38
Ә. Ерикәй. Минем өчен Казан — әткәм йорты. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . 40
Р. Гәрәй. Яратам мин Ленин районын. Шигырь 41
Н. Фәттах. Мөдир Саҗидә. Повесть . . . . 42
Н. Арслан. Диңгез ярында. Шигырь . . . . 70
Г. Бәширов. Туган ягым — яшел бишек. Повесть 72
И. Беляев. Имәннәрең илтеп утырт шунда. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . 93
Ш. Маннапов. Ышандыр. Хис. Хатирә. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 99

СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

З. Әхмәтҗанов. Октябрь яшьтәше. Очерк . 100
Татар мәдәниятының көндәлек дәфтәреннән . 106
Тарих һәм тарихчылар . . . . . . . . . . . 108
Л. Антов. Артистның тормыш юлы . . . . . 112

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Уянган Африка җырлары . . . . . . . . . . . 124

СӘНГАТЬ

Рәссам һәм тормыш . . . . . . . . . . . . 128

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Х. Госман. Халыкның үзеннән . . . . . . . 130

ЧИТ ИЛ ЯЗУЧЫЛАРЫ КАЗАН ТУРЫНДА

Җ. Камалетдин. Казан турында кайбер тәэсирләр . . . . . . . . . . . . . . . 146

БӘХӘСЛӘШӘБЕЗ, ФИКЕР АЛЫШАБЫЗ

А. Гыйләҗев. Ә син үзең кем, укучы! . . . 151

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 157

*Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

*Мәҗит Гафури*

## Бир кулыңны!

Кил әле син, иптәш! Бир син миңа
Сөялләнеп каткан кулыңны.
Янган йөрәк белән чын ихластан
Тәбрик итим изге юлыңны.

Бир син миңа, туган, көн-төн эшләп,
Таш пулатлар салган кулыңны,
Бир син миңа утлар тирәсендә
Эшләп, кызарып янган кулыңны.

Бир син миңа кырда сабан сөреп,
Туфракланып каткан кулыңны,
Бир син миңа дошман күкрәгенә
Төзәп мылтык аткан кулыңны.

Бир син миңа, сугышып, шул сугышта
Кызыл каннар аккан кулыңны,
Дошманнарның биек кальгаларын [1]
Тар-мар итеп ваткан кулыңны.

Бир син миңа хәлаль көчең белән
Эшләп тиргә баткан кулыңны,
Эштән арып, тагын көч җыярга
Аска салып яткан кулыңны.

Кулга тотыйм синең изге кулны —
Күп эш белән талган кулыңны;
Бир син миңа, туган, күкрәк киереп,
Царицынны алган [2] кулыңны.

Бир син миңа гайрәт белән сугып,
Дошман башын ваткан кулыңны.
Дуслар битен үпкән кебек үбим
Сөялләнеп каткан кулыңны.

1920.

---

[1] Кальгаларын — крепостьларын.

[2] Монда Царицынны дошманнан саклап калган мәгънәсендә.




*Атилла Расих*

## Роман[1]

### Мартның егермесе иде

Мартның егермесе иде. Хөсәен, трамвай тәрәзәсен ачып, яз һавасын бөтен күкрәге белән сулады да Екатеринская урамының үз өйләре торган ягын күзәтеп бара башлады. Трамвайның өстәге дугасы чатыр-чотыр итә, бөтен тирә-юньгә очкыннар чәчрәтә. Бельгия акционер җәмгыяте әле күптән түгел Казан трамвайларын электрлаштырды.

Ә урамда яз. Бала-чага чыр-чу килә. Түбәчекләрен башларына куеп баручы, чапан бөркәнгән татар хатыннары хәзер урамда гадәттәгедән күбрәк күренә. Тротуарлардан җылы бу күтәрелә. Рәхәт тә соң бу яз көннәре! Әйе, бары каһәр трамвай гына артык әкрен кыймылдый. Берәр лихачка утырып барганда яхшырак булыр иде Хөсәенгә. Акчаны да саклап тотмый булмый шул. Әнә трамвайга кергәндә дә, Хөсәен, аның арткы өлештәге беренче классына кермичә, алдагы ягына, икенче классына, өч тиенлегенә, кереп утырды. Хәйләкәр бельгиялеләр халыкны үзләренә тарту өчен эшне оештыра беләләр. Һәрбер класс чаршау белән икегә бүленгән. Янәсе, татар ягы, юкса татар хатыннары ирләр белән бер вагонга утырып йөри алмый, янәсе.

Чаршау ярыгыннан Хөсәеннең күзенә теге якта утыручы чапанлы абыстайлар чагылып китте.

Трамвай чыелдап чаттан борылды да Печән базары аша Болакка таба китте. Монда базар икәнлеген хәзер күзне йомган килеш тә белеп булыр иде. Чөнки андагы шау-шу, тавыш доңгырдык трамвай гүләвен дә ишеттермәс булды. Көнбагыш маенда кыздырылган төрле камыр ашларының исе борынны кытыклап вагон эченә керә башлады.

Трамвай чатлыкта чиркәү янында тукталды. Юл буенча ләм-мим сүз сөйләшмичә барган чапанлы абыстайлар төшеп киттеләр. Алар артыннан Хөсәен дә чыкты. Базар халык белән шыгрым тулы иде. Кем-

---

[1] Дәвамы. Башы 9, 10 саннарда.

нәрдер дарчин, имбир сата, кемнәрдер бик каты кычкырып дөгеле, итле вак бәлеш тәкъдим итә. Ачык һавага куелган озын өстәлләрдә май баскан ит түшкәләре, казылыклар, сап-сары симез каз, тавык күренә. Вак такта кибетләрдә галантерея товарлары, кызыл мал, түбәтәйләр, камытлар, каюлы читекләр күзгә чагыла. Кыскасы, монда барысы да бар, татар агайның һөнәр осталары ни булдырса, шул Печән базарында.

Теге чапан ябынган хатыннар вагоннан төшү белән халык арасына кереп юкка чыктылар.

Хөсәен, халык дәрьясын кичеп, Московская урамындагы Көфер почмагына таба юл тотты. Артта кәйләп-кәйләп товар тәкъдим итүче кырык тартмачылар, нәүруз әйтеп утыручы сукыр хәерчеләр, сәләмә киемле, ялтыр күзле сукбайлар калды.

Мәчет чатында кемдер Хөсәеннең беләгенә орынды.

— Бай абый, исән-сау гынамы?

Авызы колагына җиткән Фәрхетдинне күреп, Хөсәен көлеп җибәрде.

— Я, нихәл, Фәрхетдин, әйбәт кенә торасыңмы? Эшлисеңме?

— Бик аллага шөкер. Эшлим, эшлим. Инде мачтыр әйтте, у тибә башка работает, эшкә төшендең, ди. Рәхмәт инде сиңа, Хөсәен абый, син булмасаң, эш харап не.

— Садыйк абыеңа рәхмәт әйт, ярый тимерче карт аның эшнәсе икән әле.

— Ана да зур рәхмәт инде.

Хөсәен егетне башыннан аягына кадәр карап чыкты. Өстендә шул ук тузган манчестер бишмәт, башында тәвәккәл бүрек, аягында шул ук иске чабаталар, ләкин йөз бөтенләй башка, тазарып, матурланып киткән.

— Я, ничек соң, атка акча җыеламы? — дип сорады Хөсәен.

Фәрхетдиннең күзләре нурланып китте, ул тирә-якка ялт-йолт карап алды да, «әйе» дигәнне аңлатып, балаларча шатлык белән ике күзен бердән кысып куйды.

— Бик шәп, — диде Хөсәен, — алайса озакламый авылга икән! Нәдергә кайтабыз инде алайса?

— Юк әле. Алла боерса, быел җәйне монда уздырам әле, — диде Фәрхетдин, Хөсәенне аптырашка төшереп. — Нигә дисәң, бай абый, акчаны, мин әйтәм, бәлкем, тагы күбрәк җунәтеп булыр.

Хөсәен башын селкеп торды.

— Нишләп йөрүең соң монда? Бүген отгул алдыңмыни?

— Бүген төнен эшлибез. Әле баракта йокы симертеп алдым да хас Обжорный рәткә дип килдем. Анау чакны бик тә шул үпкә-бавыр шулпасына нәфесем төшкән иде, абый, тик кесәмдә сукыр бер тиен дә юк иде.

Фәрхетдин, күзләрен ялтыратып, керле зур кулы белән майлы авызын сыпырып куйды.

— Кинәндем бер затлы аш ашап.

Хөсәен кузгала башлады.

— Ярар, бик әйбәт, инде эшкә керешкәнсең икән, тырышып эшлә, — диде. — Сине авылда карчыгың көтә бит. Кара аны, акчаңны саклап тот.

Хөсәен саубуллашты да китеп барды, Фәрхетдин исә шатлыклы елмаю белән аны озатып калды.

Хөсәенгә Көфер почмагы тирәсеннән тиз генә китәргә язмаган иде, ахры. Аның Фәрхетдиннән аерылып китүе булды, каршысына Галимҗан Сәйфетдинев килеп чыкты. Дус егетнең йөзе җитди, хәтта ни өчендер ачулы да иде. Хөсәен сорау белән аның йөзенә текәлде.

— Ни булды сиңа? Бер-бер күңелсезлекме әллә?

— Хөсәен, бик зур күңелсезлек булды, — диде Галимҗан. — Җәгъфәр безнең окончательно дошман лагерена күчте.

— Ничек инде? Нидән чыгып әйтәсең?

— Шулай. Кичә «Кәрвансарай»да бераз моназара булды. Шунда бу, халык алдына чыгып, Рәшит казыйлар позициясен яклады.

— Безнең «Кәрвансарай»дамы? — диде Хөсәен.

— Әлбәттә, нинди «Кәрвансарай» бар тагы!

Бу бик күңелсез хәбәр иде. Аерата күңелсезлеге шунда иде: Җәгъфәр төрмәдә утырып, аннары атасы байгура тарафыннан тагы бер тапкыр тибәрелеп Казанга кайткач, гади эшче сыйфатында Крестовников заводына эшкә керде. Хөсәен аны бары бер тапкыр гына, анда да исерек килеш күрсә дә һаман әле бу сәләтле һәм кызу канлы егеттән өметен өзмәгән иде. Барысы да челпәрәмә килгән икән. Хөсәен, күңелсезләнеп, башын аска иде.

Галимҗан сүзен дәвам иттерде:

— Авыр хезмәт егеткә ошамаган. Сабын кайнатуны әйтәм. Ай ярым чамасы изаланды да тәмам гайрәте чикте мәсләксезнең.

— Теге бай хатынга яңадан әйләнеп кайтмагандыр бит?

— Бөтен бәла дә шунда шул! Кире кайткан. Аягына егылып елаган, гафу үтенгән.

Хөсәен, ярсуына түзә алмыйча: «Фу, шакшы!» — дип, җиргә төкереп куйды.

— Шуннан?

— Шуннан тегесе Җәгъфәрне гафу иткән...

Хөсәен эченнән үз-үзен табалап алды. Ничек ул аны алданрак белмәде? Ничек ул аны тоймады? Юкса, уйланырлык һәм тиешле бәя бирерлек хәлләр булмады түгел бит.

Хөсәен кашларын җыерып Галимҗанга текәлде.

— «Мөхәммәдия»дәге группа членнарын ул беләме?

— Белә.

— Хәзер үк тиешле чаралар күрегез, Галимҗан! Юкса янабыз. Мостафинны да, башкаларны да кисәт, бернинди язу-сызу калмасын.

— Шулай итәргә кирәк шул.

— Болай булгач, андый икс яклы пычактан барысын да көтәргә була. Ул иртәгә үк дүртенче отделениегә барып үзебезне биш тиен акчага сатачак.

Хөсәен читкә карап уйланып торды.

— Бәлки, син ялгышкансыңдыр? — диде ул, кинәт өметләнеп. — Бәлки, ул әле бөтенләй үк бетмәгәндер... дошман лагерена күчмәгәндер? Бәлки, аның белән сөйләшеп карарга кирәктер?

— Юк, Хөсәен, бу эш мөмкин түгел, — диде Галимҗан. — Әгәр андый имканият булса, мин сиңа әйтеп тә тормас идем.

Галимҗан кискен рәвештә сөйли башлады:

— Ул ачык итеп, халык алдында, бүгенге көннән башлап безнең белән мөнәсәбәт өзелгәнлеген, безнең ялгыш бер юлда булганыбызны үзенчә исбатлый башлады. Янәсе, без халыкны кызганмыйбыз, һич кирәкмәгән корбаннар ясарга җыенабыз. Рас, Хөсәен, ул рәсми рәвештә бездән аерылганлыгын икърар итте!

Хөсәен җавап кайтармады. Ләкин аның шул ук минутта бу хыянәтче белән сөйләшәсе, әгәр ул шундый юлга баскан икән, аңа каты-каты нәфрәт сүзләре әйтәсе килде. Ул ничектер салмак кына бер хәрәкәт белән Галимҗанның кулын кысты.

— Сөйләшербез әле, монда урыны түгел, — диде. — Әнә тегеңә күз сал.

— Ә юк ла, ул городовойның башы тишек түгел. Ул безнеңчә аңламый.

— Шунда да саклык житенкерәми сиңа, — диде Хөсәен. — Җитәрлек сабак алмаган кешедәй...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, этисеннән мирас булып калган көмеш сәгатьне кесәсеннән чыгарып карады да, бу юлы үзен кулга алып, күтәренке рухта:

— Ашыгам, очрашырбыз әле, — диде.

Калган юлны ул һаман шул Җәгъфәр турында уйланып узды. Сулга бер тар тыкрыкка борылды. Бераз баргач, кызыл кирпеч капкадан кереп, ишек алды түрендәге бер катлы кечкенә агач өйгә якынлашты. Тукталып өйнең сул як тәрәзәсенә карады. Әгәр керергә ярамаса, тәрәзә төбендә кына гөле булмаска тиеш.

Хәлбуки, кына гөле, үзенең кып-кызыл чәчәкләре белән Хөсәенне чакыргандай, матур булып балкып утыра иде.

Хөсәен звонокка басты. Ишек ачылу белән, чишенеп, түргә узды, тәмәке төтене тулган зур бүлмәдәге кешеләр белән исәнләште.

Әкренләп караңгыга ияләшкән күзләргә берәм-берәм комитет членнары чагыла башлады. Түгәрәк өстәл тирәсендә Саммер, Дамперов, Лозовский һәм Адоратский утыра. Читтәрәк, стена буендагы утыргычларда, Хөсәен таныган тагы берничә кеше күренә. Алар арасында — әле күптән түгел генә Самарадан Казанга күчеп килгән РСДРПның Көнчыгыш бюросы члены Лихачев.

Саммер ниндидер язулар карый, ә читтәрәк урнашканнары үзара сөйләшәләр. Әле тагы ике кеше килеп җитмәгән икән. Узган утырышта Яков Михайлович та бар иде. Ай күрде, кояш алды, үзенең эшен менә дигән итеп башкарды да китте дә барды.

Хөсәен утыргычын өстәл янынарак тартты һәм Саммерның нинди эш белән шөгыльләнүен карап утыра башлады.

— Карагыз әле, Хөсәен Минһаҗетдинович, — диде Саммер, Хөсәеннең күз карашын тойгандай. — Бөгелмә өязендә татарлардан безнең кеше бармы? Сез Карабаш авылындагы вакыйгалар турында ишеткәнсездер инде?

Шулай, Хөсәен ул турыда белә. Бөгелмә өязе Карабаш авылындагы крестьяннар недоимка түләүдән баш тартканнар, алай гына да түгел, исправник һәр өйгә килеп тентү ясый башлагач, агайлар урядник һәм пунәтәйләрне камап алып, барлык полиция чиннарын куып җибәргәннәр. Хөсәен бу хәлне белә. Ләкин бу үзлегеннән, бернинди җитәкчелексез килеп чыккан бер баш күтәрү. Хөсәен үзе дә мондый чакны актив рәвештә ярдәм күрсәтү турында, тиешле кешеләр аша эш алып бару турында уйлана. Бөгелмәдә генәме соң! Канлы якшәмбе залплары Казан губернасының бик күп өязләрен уятты. Минзәлә, Чистай, Спас һәм башка өязләрдә крестьяннар алпавытларга каршы баш күтәрә, аларның утар һәм урманнарына кул суза башладылар. Чәчү вакытлары җитү белән, әлбәттә, бу хәрәкәт киңәячәк, җиргә интеккән крестьян тагы алпавыт җирләренә ташланачак. Татар крестьяннары арасында ышанычлы кешеләр булдырырга кирәк. Хөсәен үзенең шул фикерләрен Саммерга әйтте.

— Бу мәсьәләне безгә бер махсус тикшерергә кирәк булыр, — диде «Сакалбай». Аның партия кушаматы шундый иде.

Университетның иреклe тыңлаучысы Накоряков белән студент Кулешa соңга калып килделәр.

Хөсәен Андрей Степановичның оста оратор булуына һәрвакыт соклана иде. Бик күп белем бирде ул Хөсәенгә. Ә икенчесен, Николай Никандрович Накоряковны, шулай ук Хөсәен дус күрә иде. Коля — имәндәй тaзa, зәп-зәңгәр күзле, ачык чырайлы егет. Ул хәтта бервакыт Хөсәенгә университетка керү өчен билет та әмәлли алды. Шул билет белән Хөсәен изге фән бинасының яңгырап торган коридорларыннан, аудиторияләреннән ничәмә тапкыр узды. Биология лабораториясендә фәнни түгәрәк исеме астында политик диспутлар уздырыла. Хөсәең бик күп нәрсә алды шул диспутлардан.

Узган елның көзендә Казан университетының йөз еллыгын бәйрәм итәргә булдылар. РСДРП комитеты моңардан файдалануны тиеш тапты. Ул чакны комитет башында әле генә сөргеннән качып кайткан Завадский тора иде. Бергәләшеп шул комитет члены белән бардылар. Профессор Капустинның шалтыравык нотыгы артык тешкә тия башлагач, Завадский тыңлаучылар арасыннан: «Җитәр! Бу кирәкми безгә! Бетсен самодержавие! Әйдәгез, урамга чыгыйк, шунда үзебезнең таләпләребезне әйтербез!» — дип кычкырды. Профессорның күзләре акаеп китте. Залга төрле яктан прокламацияләр ява башлады. Кинәт Завадский утыргычка басты да яңгыравык тавыш белән ялкынлы нотык сөйли башлады. Хөсәеннең күңеленә бу вакыйга бик нык сеңеп калды. Бөтен зал бер булып тынып тыңлады Завадскийны. Студентларны күзәтү эшен башкаручы педельләр ораторга ташлангач, егетләр, Завадскийны аралау өчен, тотынышып тыгыз койма ясадылар. Төрле яктан: «Бетсен самодержавие!» — дигән тавышлар яңгырады. Залның биек түшәме, андагы кандилләр бу тавышларны хуплагандай чыңлап, зыңгылдап тордылар. Ни арададыр кемдер кызыл флаг күтәрде. Студентлар, бердән кубып, «Марсельеза» җырлый-җырлый урамга агылдылар. Митинг уздыру өчен халык театр мәйданына таба юл тотты. Бераздан соң чаттан атлы полиция күренде. Шул чак Хөсәен рәхимсез патша ялчылары белән кулга корал тоткан хәлдә генә көрәшергә мөмкинлеген үзе тәне һәм җаны белән тоеп аңлады. Ничәмә кеше кыйналды ул көнне, ничәмә кешене төрмәгә илтеп ташладылар...

Хөсәенгә уйларын бүлергә туры килде. Саммер аягүрә басты да комитетның чираттагы утырышы ачык икәнлеген игълан итте.

— Иптәшләр, — диде ул, — безгә шактый «сугышырга» туры килде. Хәл, минемчә, хәзер төзәтелде, үзәкнең ярдәме һәм үзебезнең тырышлык белән без максатыбызга ирештек. «Вперед» газетасын хәзер без үзебезнең җитәкче орган итеп таныйбыз. Мин бүгенге көн тәртибендәге мәсьәләнең әһәмиятенә игътибар юнәлтүегезне сорар идем. Ленин һәм аның тарафдарлары РСДРПның өченче съездын якын арада уздыруны зарур дип табалар. Без бүген шуның турында уйлашырга һәм тиешле резолюция кабул итәргә тиеш булабыз.

Ул беразга гына тукталды да алдындагы кәгазьләрне кулына алды.

— Минем исемгә Надежда Константиновна Крупскаядан шифрлы хат килде, — диде ул. — Мин аңа бүген расшифровка ясап бетердем, сезгә укып күрсәтмәкче булам.

Ул кулындагы хатны укый башлады. Барлык комитетлар белән, Ленинның шәхси секретаре буларак, бәйләнеш тотучы Крупская Казандагы хәлләр белән кызыксынган, анда хәзер нинди кешеләр бар? — дип сораган иде.

Адоратский шушы җирдә Саммерны бүлдерде.

— Владимир Ильичның Казан өчен ни дәрәҗәдә борчылуын күз алдыма китерәм мин.

Әлбәттә, Хөсәен дә аңлый. Надежда Константиновна Ленин кушуы буенча язган. Ленинның Казанны онытмавын, һәр даим Казан хәлләре белән кызыксынуын комитет членнары барысы да бик яхшы беләләр. Крупская исә — Ленинның барлык корреспонденциясен алып баручы кеше.

Саммер хатны укуын дәвам иттерде. Надежда Константиновна якында уздырылырга тиешле III съездның большевиклар өчен әһәмияте турында, анда көрәш тактикасы билгеләнәчәген яза иде. Казан большевиклары III съездны кирәк дип тапкан хәлдә үз араларыннан делегат билгеләргә һәм аны чит илгә озату чараларын күрергә тиешләр.

Комитет членнары арасында фикер алышу башланды. Ниһаять, карар да кабул ителде. Казан РСДРП комитеты съездны кирәк һәм вакытлы дип таба. Секретарь Дамперов — какча йөзле, кылыч борынлы

студент — карарны укып чыгып, тавышка куйды. Каршылар юк иде, хәтта буйчан курсистка Астафьева Катя да, әле меньшевистик сатулашуларыннан арынып бетмәсә дә, бераз икеләнгәннән соң, үзе сөйләгәннәренә каршы килеп, кул күтәрде.

Кулеша Саммерны делегатлыкка тәкъдим итте. Димәк, күпчелек хупласа, Иван Адамович съездга китәргә тиеш. Хәер, күпчелекнең, әлбәттә, Саммер кандидатурасын яклаячагын Хөсәен анык белә иде инде. Чөнки бу революционерны хөрмәт итмәгән бер генә иптәш тә юктыр.

Хөсәеннең күңелен кытыклап, аңлатып булмый торган ниндидер бер тойгы узды. Юк, бу көнләшү түгел, хәтта Саммерга кызыгу да дип әйтеп булмас иде. Ул ниндидер горурлык кебегрәк тойгы булды.

Төп мәсьәлә хәл кылынып, карар кабул ителгәндә лампа кабызылган, комитет членнарының йөзләренә ару галәмәтләре чыга башлаган иде.

— Иптәшләр, инде мондый хәл, — диде Саммер. — Безгә берәр чара табып, Трофим Завадскийга ярдәм күрсәтергә кирәк.

— Аның хәле ничегрәк соң? — дип сорады курсистка. — Мин аңа бер кергән идем, ләкин, кызганычка каршы, ул квартирасын алыштырган булып чыкты.

— Мин аның янында әле кичә генә булдым, — диде Саммер. — Шулай шул, ул квартирасын алыштырды. Шулай итәргә мәҗбүр булды. Аның хәле әйбәт түгел, иптәшләр, — дип өстәде ул.

Хөсәен игътибар белән тыңлый башлады. Сүз әле генә үзе хәтерләгән, университет вакыйгаларында җитәкчелек иткән кеше турында бара иде. Төрмә, сөрген, үз-үзен аямыйча, ачлы-туклы, йокысыз узган тормыш Завадскийны тәмам аяктан еккан. Ул хәзер үпкә чире белән каты авырып ята. Кызганыч иде аның хәле. Казанда туган тиешле кешеләре булмавы аның хәлен аерата авырлаштыра иде.

— Берәр ашыгыч чара күрергә кирәк бит безгә, — диде Саммер. — Завадский күзгә күренеп, шәмдәй эри, иптәшләр.

— Элекке квартиры аның ярыйсы иде, — диде Дамперов. — Мин аның хуҗасы белән дә сөйләштем ул чак, әйбәт, гадел кешеләр иде алар. Тик шпектер филерлар сизенгәннәр, шик туган...

Дамперов тынып калды. Хөсәенгә барысы да ачык иде, Трофимны хәзер аерата нык сакларга кирәк. Чөнки ул сөргеннән качкан кеше, фиргавеннәр аның эзенә төшсәләр, рәхим-шәфкать булмаячак аңа. Хөсәеннең күңелендә тыелгысыз бер теләк туды.

— Ә безгә күчерсәк аны? — диде ул. Утырыштагылар Хөсәенгә текәлделәр, уйга калдылар. Саммерның да, Накоряковның да Хөсәеннәрдә булганы бар. Аның нинди шартларда яшәвен барысы да диярлек белә. Һичшиксез, Хөсәен чагыштырмача хәвефсез яшәүчеләрнең берсе, шулай да бөтенләй үк түгел. Саммер тамак кыргалап куйды.

— Син хәвефсез булыр дип ышандырасың инде? — диде ул, уйланып.

— Мин аңа тыныч шартлар тудырачакмын, — диде Хөсәен. — Аңа...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, Накоряков бүлдерде:

— Ай-һай, синең дә, Хөсәен дус, квартираң күзәтү астында бит. Әгәр берәр хәл була калса... — диде.

Чыннан да, Хөсәеннең квартирында бер тапкыр полиция булган иде инде. Ләкин берни дә табылмады бит. Шпикларның сагалап торуларын да Хөсәен белә. Ләкин бит аны гаепләргә барыбер берниндн дә матди дәлил юк. Хөсәен, әлбәттә, саклану чараларын күрәчәк һәм ни кылса кылыр, мәгәр иптәшен үлемгә дучар итмәс.

— Мин сезнең ничек яшәвегезне беләм, — диде ул Накоряковка каршы. — Сез бөтенегез дә миңа караганда авыррак шартларда. Без бит инде, иптәшләр, Трофимны ташлый алмыйбыз.

— Болай итәргә кирәк, — диде Лозовский. — Син аны, Хөсәен Минһаҗетдинович, үземә алам, димә, син аны тыныч һәм әйбәт урынга урнаштырам, диген. Әгәр дә шулай булса, мин риза.

— Мин дә шулай уйлыйм, — диде Дамперов. Башкалар да шуңа кушылды.

— Алайса, Завадскийны урнаштыру мәсьәләсе миңа тапшырыла. Шулаймы? — диде Хөсәен. Ул күңеленнән план корып өлгергән иде инде. Әлбәттә, кемгә генә урнаштырмасын, ул авыру революционерны бераү дә Хөсәеннең әнисе һәм Хәдичә кебек итеп бага алмаячак. Аннан соң, Хөсәеннең ышанычлы докторы да бар бит әле. Ул доктор Дәүләткилдиев, бөтен Казаныңа бер мөселман доктор...

— Алайса, шулай сөйләштек, — диде Саммер. — Завадский сиңа тапшырыла.

Комитетчылар таралышканда язгы төн үзенең якты йолдызлары белән бизәлгән зәңгәрсу кара шәлен ябынган иде. Төн уртасы булуга карамастан, һава салкын түгел, хәтта түбә кыекларыннан су тама, кар баскан саен шытырдап сеңә, аяк эзләрендә каралып су кала. Хөсәен, Московская чатына җиткәч беразга туктала, Печән базары ягын күзәтте.

Хәзер бөтен дөнья тынлыкка чумган, көндезге мәхшәр, әйтерсең лә, бөтенләй булмаган да: кибетләр ябык, бөтен тирә-юнь йокыга талган. Хөсәен Завадский турында уйланды. Ул аны ышанычлы иптәшләре белән бергәләп үз өенә күчерер. Аңа урын бар, аңа әйбәт булачак. Белмәссең, бәлки әле аягына да басар. Юкса, бик җаваплы вакытлар якынлаша бит. Әйтерсең лә, җиһанны утлы камчылар белән кыйныйкыйный гөлдерәп яшенле-давыллы яңгыр килә. Ул җир өстенә чиләклэп рәхмәт яңгырын актарачак, бәхетсез, җәберләнгән, кимсетелгән ил өсте аруланып, сафланып калачак.

Шундый хәлиткеч көннәрдә, бөтен гомереңне, бөтен барлыгыңны шул эшкә багышла да күзгә күренмәслек кечкенә микроблар аркасында ыргытылып читкә ташлан. Дөньяда моннан да мәгънәсезрәк хәлнең булуы мөмкинме! Хөсәен хәзер урыныннан тора алмый яткан Трофимның хәлен яхшы аңлый. Аңлау гына түгел, хәтта барысын үзе кичерә кебек иде.

Ул Җәгъфәрне хәтерләде, бая шушы урында сүз булды бит. Аның йөрәге сыкранып куйды. Бер бай хатынга сатылыр икән кеше, яшьлектә эчкән антларына хыянәт кылыр икән кеше! Ә теге көнне нәрсә килеп чыкты тагы! Мин Рабига туташны сөям диме?

Алда күренгән фонарь янында кемдер басып тора иде. Ахры, городовойдыр. Бераздан каравылчыларның иренеп кенә бер-бер артлы шакылдатканнары ишетелде. Каршы яктан, бөтен дөньясын онытып, бәхеткә тиенгәндәй бер исерек адәм җырлап-әйттереп узды. Күрәсең, городовойга ялгызлыкта төн ката тору күңелсездер. Ул Хөсәенгә исерекне күрсәтеп:

— Менә кемгә диңгез тубыктан ул! — дип куйды.

— Шулай шул, — диде Хөсәен. Ашыккан аякларын тыебрак будка яныннан узды.

Хөсәен тагы Завадский турында уйланды, аннары уйлары сеңелесе Хәдичәгә күчте. Аның ярамас бер эш эшләп ташлавы турында фикер йөртә башлады. Ничек тә бер барып чыгасы иде шул Әлмәткә. Ләкин вакыты андый түгел шул!

Хөсәен, абайламыйчарак, кар астына яшеренгән суның күзенә үк китереп басты. Яз җиткән иде шул. Иң матур чаклар якынлаша. Шушы яз уртасында күңел ниндидер ашкынулар, шатлыклы дулкынланулар кичерә башлый. Ул әллә кайларга ашкына, җилкенә. «Менә Беренче май бәйрәме дә якынлаша, — дип уйланды Хөсәен, — ул быел аерата тантаналы булачак. Аңа бик шәп итеп әзерләнергә кирәк».

Хөсәеннең күз алдына яшеллеккә күмелгән кырлар, урманнар килде. Сайрар кошлар, гүзәл чәчәкләр. Ул вакытларга да күп калмады шул. Шунда ук күз алдына чәчәктән үрелгән такыя һәм, шуңа бәйләнеп,

хатыны Хәдичә килеп басты. Шулай чәчәкләр җыеп, такыялар үреп йөргәннәр иде алар бервакыт. Хөсәен үз алдына елмаеп куйды. Татлы уйларга чумып алга баруында булды. Мартның егермесе иде.

## Безнең гүзәл бәйрәмебез

Әле сәгать иртәнге дүрт тә юк иде. Биш кеше, печән салынган кабык арбага утырып, Казанның Ягодный бистәсе ягыннан үзәккә таба юл тотты. Ат башында Шәрифулланың кече улы Гыйззәтулла утыра. Әтисе — аның белән янәшә, уң якта. Ул эш четереклерәк чакта дилбегәне үз кулына алып, улына булышкалап куя. Сул якта алда — Тәгъзимә, аның белән янәшә — Садыйк, ә иң артта, артка карап, аякларын салындырып, Фәрхетдин утырып бара иде.

Вакыт иртә әле, Казан халкы уянмаган. Түм-түгәрәк битле Гыйззәтулланың йокысы да туймаган. Шулай да ул сер сынатмаска тырыша. Ә май иртәсе ничектер шомлы-борчулы. Кемнәрдер сагалап торалардыр, ташланырга җыеналардыр кебек. Бәлки, бу— Садыйкка гына шулай тоелгандыр. Юк, тоелса да, ул дөрес сизенгән. Әнә күрмисезмени, таң тишегеннән атлы полиция патруле бистә урамнары буйлап кыдыра. Садыйк үзләре янынннан узып киткән полицейскийларга кашын җыерып ачу белән карап калды. Фиргавеннәрнең мыеклары хәтәр, үзләре юан, ә елкылдап торган көр атлары уйнаклап баралар иде. Ул атлар белән чагыштырганда Шәрифулланың чаптары бөтенләй югалып, бер йолкыш булып кала. Садыйк, патруль узгач: «Сизенәләр, дуңгызлар, хәтәр буласын сизенәләр», — дип әйтмәкче иде дә тыелып калды. Фәрхетдин белән Тәгъзимәнең куркып киреләнүләреннән шикләнде ул. Хәлбуки, шикләнмәслек тә түгел иде. Шәрифулла маевкага барырга шатланып риза булган чакта, Тәгъзимә икеләнеп торды, ә Фәрхетдин исә бөтенләй куркуга төште. Екатеринбургта эшләп уздырган еллары, андагы революционерлар белән аралашуы, инде хәзер туку фабрикасындагы идән асты эшенә катнашуы Садыйкны күп нәрсәгә өйрәткән иде. Ул бик яхшы белә: революция оештырылса гына нәтиҗәгә ирешеп була, юкса берни дә килеп чыкмаячак. Шуңа күрә Садыйк барлык көчен җигеп, бернинди хәвеф-хәтәрләр белән исәпләшмәстән, берәм-берәм татар эшчеләрен түгәрәккә йөрергә чакыра башлады. Шәрифулла абзый аның түгәрәккә тартылган беренче кешесе булды. Ул аны әллә ни күп үгетләмәде дә, чөнки агай дөньяның әчесен-төчесен байтак татыган иде инде, ул тирәюнендәге гаделсезлектән котылу юлларын эзләп күптән интегә, күптән, Садыйк кебек, үзенә юл күрсәтүчене көтә иде. Шәрифулла абзый белән алай матавыклы булмады, иллә мәгәр Тәгъзимә җиңел генә Садыйклар, Хөсәеннәр белән китәргә батырчылык итмәде. Күрәсең, аны бик нык өркеткәннәр иде. Ләкин шулай да ул теге вакытны ялган прокламацияләрне учакка атып, көлен күккә очырды. Бәхеткә каршы, тотылмады да.

Артык фәкыйрьлектә һәм өметсезлектә яши иде шул ул. Хатын, җитмәсә, мондый хәлдә яшәвен тәкъдиремдә шулай язылгандыр инде дип уйлый иде. Садыйк аның белән берничә тапкыр сөйләшеп карады, хәтта бер тапкыр Тәгъзимәнең өенә дә барып чыкты. Тик хатын Садыйкларга туры булышлык күрсәтүдән баш тартты. «Аллам сакласын, — диде, — сезнең турыда беркемгә дә әйтмәм, тик арагызга катнаштырып, башларымны гына вәйран итә күрмәгез», — диде. Өенә килеп йөрмәскә кушты, тол хатынның ишеге ачылмаса да шыгырдый, дип Садыйкны тизрәк озатып җибәрде.

Садыйк татар хатын-кызлары арасында эш алып барырлык башка кеше табу турында уйлана башлаган иде инде — көтелмәгән бер хәл Тәгъзимәнең карашын кинәт үзгәртеп җибәрде. Кызы сәбәпче булды.

Кызы аның үндүртечне яше белән бара иде. Ул баласына Тәгъзимәнең өмете зур иде, әллә шуны фабрикага урнаштырып, тормыш итәргә җиңелрәк булмасмы, дип уйлый иде. Көннәрдән бер көнне Тәгъзимә теләгенә иреште: үзе эшләгән тегү мастерскоена кызы Нәсимәне дә урнаштырды. Кызы хәзер аскы каттан өскә йөгерә-йөгерә постау ташый башлады. Тик, озакламый, кызын күргән саен, Тәгъзимәнең йөрәге әрни торган булды. Чөнки кыз артык ябыкты, бәрәңге үрентеседәй зәңгәрсуланып агарды, ул да булмады, бер заман ямьсез итеп ютәлли үк башлады.

Бу хәл бик авыр иде анага. Ул, тормышын ләгънәтләп, әле уйнап-шатланып йөрергә тиешле кубәләктәй баласының шулай газап чигеп, сасыда, тузанда көннәрен уздыруына байтак күз яше түкте. Бер ара инде хәлсезләнә башлаган Нәсимәгә әкрен йөрисең дип мастер җикеренергә кереште. Ә көннәрдән бер көнне йөзе кара Пальчиков аны анасы алдында ук яңаклады. Тәгъзимә түзмәде, мастерның якасына ябышты.

Шул көнне үк хатын эштән соң Садыйкны эзләп тапты. Әлбәттә, ул: «Мин барысына да әзер», — дип әйтмәде. Ләкин Тәгъзимәнең күз карашыннан ук Садыйк шулай икәнлеген төшенде.

Инде Фәрхетдингә килгәндә, эшләр башкачарак иде. Садыйк аңа иртәгә Беренче май бәйрәме, эшчеләр бәйрәме дип аңлатты, маевкага чакырды. Фәрхетдин башта чырай гына сытты, ә инде маевкаданиләр буласын ишеткәч, тәмам куркуга калды. Ләкин нишләмәк кирәк соң ул бичарага? Фәрхетдин үзе Садыйк алдында бурычлы саный иде шул!

Чаптар бия дамба буйлап лерт-лерт Казанга таба юрта. Идел ягыннан сәрин җил исә. Әнә кремль, Сөембикә манарасы, аның өстендәге патша гербы, крепость эчендәге чиркәүләрнең алтын гөмбәзләре. Алар иртәнге кояшта күзләрне чагылдырып ялтырыйлар. Юлда атлы һәм җәяүле кешеләр, хәрбиләр һәм полиция чиннары шәһәргә якынлашкан саен ешая бара.

Менә безнең юлчылар тын Казан урамыннан, Проломный буйлап баралар. Шәһәр халкы соң тора. Мещаннар әле тәмле төшләр күреп йоклап яталар.

Печән базарына да җиттеләр. Кабан күле кояшта ялтырап җәйрәп ята иде. Яр буена җиткәч, барысы да ашыгып арбадан төштеләр. Шәрифулла өйгә кайтканда үзен ни рәвештәрәк тотарга кирәклеге турында Гыйззәтуллага киңәшләр бирә башлады.

— Белмим инде, — диде Шәрифулла Садыйкка карап, — малай атны әйбәт кенә алып кайтып җиткерсә ярый инде.

— Ул апкайтмыймы? — диде Садыйк. — У-у, ул! Ул әле синең малай, кирәк икән, атыңны Порт-Артурга алып барыр!

Шәрифулла «Ай-һай!» дип башын чайкап куйды.

Җыйнаулашып пароход туктала торган басмага таба юнәлгәндә, Гыйззәтулланың чәрелдек тавыш белән: «На, на!» дип атын куалаганы ишетелде. Ул китте. Садыйклар беркадәр башны әйләндереп чайкалып торган басмага керделәр. Бәләкәй булса да, «Нептун»ның моржасыннан кара төтен көлтәләре ургыла башлады. Чак урнашып өлгерделәр, пароход богырдатып бер кычкыртты да үзеннән биек көпчәге белән суны шапырдатып, бөтен гәүдәсе белән калтыранып китеп тә барды.

Дүшәмбе көн булганга, пароходта пикникка чыгучылар аз иде. Булганының да күбесе ярлы-ябагай эш кешесе: Борискин авылы крестьяннары, ресторанңарда эшләүче официантлар, буфетчылар, су, сыра сатучылар. Садыйк шулай да шәйләп алды: пассажирлар арасында Казанның төрле заводларында эшләүче татар агай-эне юк түгел иде. Тәгаен, алар да, Садыйклар кебек, маевкага баручылардыр. Сыра мичкәләре арасында тагы бер төркем эшче күренде, болары инде Алафузов мастерскойларыннан, Садыйкның танышлары иде. Ләкин Садыйк

алар янына бармады, ерактан гына, ым кагып кына исәнләште. Тиздән иптәшләрен ияртеп, өскә, палубага менеп китте.

Яшькелт сулы күл бүген аерата матур, ямьле булып күренде. Сулъяк ярдагы агачлыкларда хәтта сандугачлар да сайрый. Быел яз бик иртә килде шул, матур, җылы көннәр иртә башланды. Иртәнге саф һава күңелләрне сөендерә, ярсу йөрәкләргә тынычлык бирә иде. Моңарчы гел чытык йөз белән, тавышсыз-өнсез килгән Фәрхетдин дә җанланып китте. Ул үзенең авылы, гүзәл Зәй тугайлары турында сөйли башлады. Тәгъзимәнең дә һәрвакыт сагышлы була торган күзләренә яктылык шәүләсе йөгергән иде. Рәхәт иде су өстендә. Хәтта жил сабын заводы ягыннан искәндә борынга бәрелеп киткән авыр ис тә кәефне бозмый иде.

— И ходаем, — диде Тәгъзимә, — минә ирем үлгәннән соң бер генә тапкыр да мондый матурлыкларны күргәнем юк ие, каян акылың житте дә, каян мине алып чыгасы иттең, Садыйк!

— Әле моннан да матуррагын күрербез, килен, аллаһы боерса, — диде Шәрифулла. — О-онә, күрәсеңме, бик матур агачлык, анда дайча йортлары, шуннан чак кына арырак Ботан бакчасы инде. Шунда барып, бер мәл мин үзебезнең директорга яшь җимеш агачлары алып кайткан идем. Бер дә әйтеп бетергесез хозур урыннар инде анда, Тәгъзимә килен. Һай-һай-һай!..

Шәрифулла, андагы хозурлыкны сүз белән генә әйтеп аңлата алмам дип, ахры, байтак вакыт телен шартлатып торды.

— Байлар рәхәттә тора беләләр, — диде Садыйк, җиңелчә генә, хатын-кыз да күтәрерлек кенә итеп сүгенеп.

Алар дүртесе дә палубаның читендә тимер киртәгә тотынып баралар иде.

— Беләләр инде, беләләр, — диде Шәрифулла. Яр буендагы яшеллекләргә күмелгән дачаларга карап бары да тынып калдылар. Сандугачларның чут-чут итеп сайраулары хәзер ачык ишетелә. Ярга якынлашканда әле генә яфрак ярган агачлардан сагызлы бөре исе аңкый.

— Ә бит барысы да менә шушы безнең кара, ямьсез куллар белән эшләнә, — диде Садыйк.

Тәгъзимә уң кулына карап алды. Чыннан да, аның кулы каралып, кискәләнеп, катып беткән иде. Аның бер генә дә исән бармагы юк, барысы да азырта. Ә бит аның да яшь, матур чаклары бар иде. Аның да ап-ак йомшак һәм иркәли белә торган куллары бар иде. Ул тирән итеп көрсенде дә:

— Ходай бәхет бирмәсә, сатып алып булмый икән шул инде, — дип куйды.

— Алла адәмнәрне тигез итеп яратмаган, — диде Фәрхетдин. — Кеше генә түгел, кулдагы бармак та тигез түгел, өлешеңә төшкән көмешең инде.

Садыйк гасабиланып өске иренең бер почмагын гына селкетеп куйды. Ләкин дәшми калды. Фәрхетдин:

— Аллаһы тәгалә әйткән ди бит, — диде. — «Бирәм дигән колыма — чыгарып куярмын юлына», дип әйткән ди.

Садыйк, артык түзә алмыйча, кинәт ачу белән:

— Тот менә капчыгыңны! — диде.

— Нигә? — диде Фәрхетдин, аптырый төшеп.

Шәрифулла да сүзгә кушылды.

— Юк, алай түгел ул, энем Фәрхетдин. Аллаһы тәгалә, тырышканга бирермен, дигән ул. Инде тәкъдир дип кенә авызыңны ачып торасың икән, тере килеш тиреңне тунап китәрләр синең. Беләсеңме?

Садыйк Уралда ук аллага ышанмый башлаган иде инде. Ләкин бу динле кешеләр алдында аларның күңелендә бик изге таяныч булып торган нәрсәгә кагылырга теләмәде. Бер сөйләнү белән генә кешегә

дөреслекне аңлатып булмый. Бу дөреслекне авыр эзләнүле еллар китерә.

«Нептун» Ботаника бакчасына килеп туктады, у-һу килеп, шаулаша-шаулаша, ике мичкә сыраны басмадан тәгәрәтергә тотындылар, кемнәрдер төшеп калды. Бер мәл ыгы-зыгыдан соң, пароход тагы бик гайрәтләнеп бер богырдады да юлны Аркадия бакчасына таба тотты.

Пәри почмагында пароходның соңгы тукталышы иде. Анда барып җиткәндә Юнусовлар мәчетенең манарасыннан мәзиннең моңлы нәзек тавыш белән азан әйткәне ишетелде. Садыйк эченнән генә: «Безнең иртәнге намаз ферма урманында булыр инде», — дип көйде.

Быелгы маевканы комитет аерата зур һәм тантаналы итеп уздырырга карар кылды. Руслар һәм русча белүчеләр өчен ул Идел буендагы бер утрауда булачак. Татарлар өчен — ферма артында. Анысы — әле Садыйклар бара торган земледелие училищесының авыл хуҗалыгы фермасы.

Маевканың кайсы урында уздырылачагын ачыклап, юлда очрарга тиешле пикетчылар хәбәр итәчәк.

Юлчылар, пароходтан төшкәч, ак ком сибелгән матур юл буйлап бөдрә куаклыкка күмелгән тауга таба юнәлделәр. Юл читендәге чирәмнәрдә чык тамчылары ялтырый. Кабан күле бу Пәри почмагы дип аталган урында ак томан белән өртелгән иде. Кошлар сайравын тыңлап, юлчылар чакрым ярым чамасы ары киттеләр. Үзләре кебек төркем-төркем булып баручылар татарыннан да, русыннан да аз түгел иде хәзер. Хәлбуки, аларның пикникка дипме, я булмаса маевкагамы барулары мәгълүм түгел. Әнә бер төркем кеше, күбесе яшьләр, берсе каеш белән аркасына гармун аскан, икенчесе кечкенә генә җиз самовар күтәргән. Садыйкларны узып киттеләр. Арада олырагы, түбәтәй өстеннән картуз кигәне, мәгънәле генә итеп Садыйкка карап күз кысты.

Садыйк, иптәшләрен Ерак Кабан дип аталган икенче күл янына китереп җиткергәч, күзләрен йөртеп, игътибар белән кемнедер эзли башлады. Ниһаять, тапты. Күл читендә кармак таяклары янына чүгәләгән кечкенә буйлы, киез эшләпәле, җирән сакаллы бер картка таба китте ул. Бабай, калкавычларына текәлеп, шул кадәр мәз беткән иде, — ул Садыйкка игътибар да итмәде.

— Ни әйтсәң дә, балык ит түгел инде, — диде Садыйк көлемсерәп.

Карт җәһәт кенә борылды да җитди генә:

— Ярлыга балык та аш, — дип җавап кайтарды.

— Кайсы якка китәргә? — дип сорады Садыйк шыпырт кына.

— Әнә арттагы чокыр буйлап барыгыз, — диде карт борылмыйча гына. — Анда очратырсыз... әйтерләр...

Садыйклар төркеме, куе агачлыкка күмелгән озын чокыр буйлап бара торгач, тагы бер пикетчыны очратты. Бусы инде Садыйкның күптәнге танышы Минһаҗ Шаһиәхметов иде. Аңа парольне әйтеп тормадылар, бәйрәм белән котладылар.

Ир-ат, тукталудан файдаланып, тәмәке төреп кабызды, тик озак тормадылар, ашыгып, Минһаҗ аңлаткан юлдан урман эченә кереп киттеләр.

Әйтелгән аланда байтак кеше җыелган иде инде. Күп кенә танышлар очрады. Алар ничек, нинди юлдан килгәннәрдер, — билгесез. Ахры, күбесе җәяүләп килгән. Таныш булмаганнар арасында Садыйк, гаҗәпсенүенә каршы, европача шактый пөхтә киенгән кешеләрне дә күрде. Студентлар, гимназистлар, реалистлар һәм форма киемле чибәр кызлар да күренә иде. Халык арасында башларына фәс яки түбәтәй чәпәгән, утырма якалы казаки я җөббә кигән шәкертләрне дә абайларга булыр иде.

Бер карт каен янына җиткәч, Садыйк юлдашларына урнашырга кушты, үзе төенчеген ташлап, әчкә, халык арасына, кереп китте.

Аланның аргы ягында, зур карама төбендәге яшел чирәмгә җәелгән чүпрәк паласта, кемнәр беләндер сөйләшеп Ямашев утыра иде. Садыйкны күрү белән ул елмаеп кул суздЫ. Хөсәен бәйрәмчә киенгән иде. Садыйк өс-башының фәкыйрьлегенә бераз күңелсезләнә төште. Ләкин ана үз шәхсияте турында күп уйланырга ирек бирелмәде, үз итеп, тиң күреп сорашу башланды. Садыйкка маевка мөнәсәбәте белән байтак эшләр йөкләтелгән иде. Ул аларның барысын да җиренә җиткереп үтәп чыкты. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Зур эш өчен кырыкка ярылырга риза иде ул.

Хөсәен белән янәшә утырган ак чырайлы яшь кенә хатын Садыйкка эндәште:

— Садыйк иптәш минем белән исәнләшми дә! — диде.

Садыйк аптырап китте. Бу кеше Хөсәеннең хатыны Хәдичә ич! Аның болай маевкага килеп чыгу ихтималын һич уйламаган иде егет.

— Ә-ә-й, Хәдичә туган, — дип сузды ул, — үзегезне танымыйча торам бит. Юкса теге чакны сыйлаган вареньелы чәегезнең тәме әле дә авызымнан китми.

Февраль аенда гына Садыйк аларда булып, корбан бәйрәменнән калган тәмле-төмле белән сыйланып китте. Әле әйткәне шуның турында иде.

Хөсәеннең уң ягында Гафур белән янәшә бик матур кара күзле, киң маңгайлы, егерме биш-егерме алты яшьләр чамасындагы ниндидер бер кеше утыра. Аның башында өр-яңа хәтфә кәләпүш, өстендә кара костюм. Садыйк артык кызыксынып текәлде булса кирәк, Хөсәен елмайды да, матур кешегә ым кагып, Садыйктан:

— Сез танышмы? — дип сорады.

Юк, белми иде аны Садыйк.

— Бу Галиәсгар Камал әфәнде, — диде Хөсәен.

Садыйк, хәтерен җыеп, аны исенә төшерергә тырышты. Әйе, ишетелгән исем иде бу.

— Ул язучы, — диде Хөсәен, — бәлки, ишеткәнең бардыр әле, аның «Бәхетсез егет» дигән театр китабы бар.

— Син, Хөсәен, мине эшчеләр белән таныштырганда «әфәнде» дип атама әле, зинһар. Күрше хакы — тәңре хакы, сүземне тыңла, — диде Галиәсгар.

— Ничек дип атыйм соң?

— Иптәш дип ата, — диде Галиәсгар. — Үзегезчә.

Садыйк җанланып китте.

— Галиәсгар иптәш, ниуҗили бездә дә, татарда да, театр булыр икән?

— Менә тырышабыз, — диде Галиәсгар.

Хөсәен өстәде:

— Ул синең белән минем иҗтиһат кылуымнан тора, Садыйк.

Садыйкның Екатеринбургта рус спектакльләрен караганы булды. Ул бер тапкыр хәтта туманный картина да күрде. Шул чагында ул: «Безнең татарда да шундый хикмәтләр булыр микән», — дип уйланган иде. Ләкин бит...

Ул Хөсәенгә:

— Э-и-х, бездән генә торса иде ул! — диде әрнеп.

Хөсәен тигез ак тешләрен күрсәтеп елмайды да:

— Ә монысын таныйсыңмы? — диде шаяртып. — Монысы Коләхметов. Мөгаллим.

Садыйк көлеп Гафурга кул сузды.

— Анысын таныйм! Анысы үзебезнең учитель.

Сүз шул җирдә өзелде. Барысы да агачлар арасыннан чыгып бирегә юнәлгән яшь егеткә күз ташладылар. Ә егет исә, тәгаен, Хөсәенне эзләп килә иде. Аның фуражкасы кулында. Күпереп торган җирән

чәч, өстендә ыспай гына реальный училище формасы, матур ак йөз, зәп-зәңгәр күзләр. Хөсәен аны тану белән кул изәп чакыра башлады. Егет исә, Хөсәенне күргәч, адымнарын тагы да кызулата төште. Якынлашкач, төркемдәге кешеләр белән кул бирешеп исәнләште дә, елмаеп:

— Көчкә таптым, — диде. — Мин, пикетчикларга күренмичә генә табып булыр микән дигән идем, көчкә таптым.

— Ә-ә, монысы әйбәт түгел инде, — диде Хөсәен кинәт күңелсезләнеп, — димәк, безне фиргавеннәр дә эзләп таба алачак.

— Булмас. Тапмаслар дип уйлыйм, — диде егет. — Әгәр дә менә бу якка бер сакчы куйсак, булмас, Хөсәен абый.

— Куярга кирәк, — диде Хөсәен. Ашыгып урыныннан торды, кесәсеннән зур көмеш сәгатен чыгарып, карап алды. — Ә, әйе, — диде ул кинәт хәтерләп, — сез танышмы бу яшь иптәш белән? Мулланур Вахитов, реалист, менә үзегез күргәнчә, бик чибәр һәм хәйләкәр егет.

Мулланур каршы килеп нидер әйтмәкче иде. Ләкин Хөсәен:

— Хәзер сөйләшергә вакыт калмады инде, Мулланур, — диде. Ул агач төбендә яткан камыш әрҗәдән бер пачка кызыл прокламация алды, аны икегә бүлеп, яртысын Мулланурга сузды: — Мәле, шуны халыкка җиткерегез!

Прокламацияләрнең калганын Садыйкка тоттырды.

— Монысы синең өлеш, Садыйк туган. Ләкин җаен белеп таратырга кирәк. Аңлыйсыз инде, — диде ул, мәгънәле генә күз кысып. Аннары, артык берни әйтмәстән, халык арасына кереп китте. Садыйк ихтыярсыздан игътибар итте: бу секундта Хөсәеннең йөзе утә җитдиләнеп киткән, аның яшь чыраена олылык кергән иде.

Хөсәен үз юлында кемнәрнедер туктатып,ниләрдер әйтте. Садыйк бу кешеләрне белми дә иде. Крестовников, я булмаса башка берәр завод эшчеләредер. Алай дисәң, араларында Хөсәеннең үзе кебек киенгәннәре дә бар. Хөсәенне алар әйләндереп алдылар. Бераздан барысы җыйнаулашып алан уртасындагы зур агач төбенә таба киттеләр.

Сәгать сигезне сукканда Хөсәен, фуражкасын кулына тотып, табигать әзерләгән «трибуна»га менде. Игътибар таләп итеп кулын күтәреп торды. Кинәт кискен хәрәкәт башланды. Таралышып, митингның башлануын аерым төркемнәрдә көткән кешеләр Хөсәен тирәсенә ашыктылар. Халык урталыкка җыелгач, бераз вакыт тынлык хөкем сөрде. Сандугачлар сайравы хәзер аерата ачык ишетелә иде.

— Иптәшләр, — диде Хөсәен, күтәренке көр тавыш белән, — без бүген Беренче май бәйрәменә җыелдык. Халыклар төрмәсе булган Россия империясенең бер ягыннан икенче ягына кадәр революция дулкыннары чайкала. Эшче сыйныфы, барлык хезмәт ияләре күп түзделәр. Аларның күргәннәре тәмуг газапларыннан ким булмады. Ләкин, туганнар, күп калмады инде. Пролетариат үзенең көчен туплап, кулына корал алып, канэчкеч патша золмәтенә каршы күтәреләчәк, бу вәхшәт тар-мар ителәчәк, бөтен Россия өстенә шәһитләр канына манчылган кызыл байрак, тигезлек, хөррият байрагы күтәреләчәк!

Кинәт мәйданның дүрт почмагында да кызыл флаглар күренде. Хөсәен артында торучы кара тутлы карт эшче дә, янындагыларны сискәндереп, югарыга зур кызыл флаг күтәреп җибәрде. Хәзер май җилендә салмак кына җилбердәгән кызыл комач шәүләсе Хөсәеннең йөзенә төшә һәм аның сөйләгәннәрен тагы да тантаналырак һәм үзен тагы да мәһабәтрәк итеп күрсәтә иде.

Хөсәен хезмәт ияләренең буржуазиядән күп тапкыр көчлерәк булуы турында сөйли башлады. Моны исбатлау өчен эшче сыйныфының иң ышанычлы вәкилләре большевиклар тирәсенә тупланып, көрәшкә, рәхимсез, аяусыз соңгы коралды көрәшкә күтәрелергә генә кирәклеген әйтте. Ул, ниһаять, Беренче май бәйрәменең килеп чыгу тарихын сөйли башлады.

Фәрхетдин белән Тәгъзимә Садыйк янында торалар иде. Бары Шәрифулла гына алга ук чыккан, башын югары күтәреп, барлык дөньясын оныткан хәлдә Хөсәенгә текәлгән. Фәрхетдин Хөсәеннең беренче сүзләреннән соң ук аптырап калган иде. Инде «бай абыеның» шундый котчыккыч сүзләр сөйләп митингны ачуын ишеткәч, үз колакларына ышанмас булды. Өнме, төшме бу? Фәрхетдин ахыр чиктә түзмәде, муенын сузып, Садыйкның колагына пышылдады.

— Мин бит бу абыйны бер дә алай дип белми идем... Ул бит безнең Якуб байның кайнагасы...

— Булса ни, — диде Садыйк.

— Әстәгъфирулла, — диде Фәрхетдин, бөтен гәүдәсе белән калтыранып, — әллә ниткән куркыныч сүзләр сөйли бит.

Якында гына торучы яшь эшче ачулы күзләрен Фәрхетдингә төбәде.

— Тавышланма, егет!

— Тынла, — диде Садыйк та коры гына егетнең янтыгына төртеп. Ләкин Фәрхетдиннең дәһшәтләнүе йөзеннән китмәде.

Хөсәен, сүзен тәгәлләп, май митингысын ачып җибәрде. Беренче булып сабын заводында эшләүче кешегә сүз бирделәр. Хөсәен урынын алган оратор Кабанда балык тотып утырган әлеге җирән пикетчы карт булып чыкты. Аның аркасы бөкрәйгән, йөзе картлыктан җыерчыкланган, пешкән алма шикелле иде.

— Җәмәгать, җанекиләрем, дусларым! — диде ул, барлык көченә кычкырырга тырышып. Тик аның тавышы карынкы, зәгыйфь иде, шуңа күрә җитәрлек яңгырамады. Карт соры күзләрен югарыгарак текәп торды да: — Эт көнендә яшибез! — дип кычкырды. — Ничек итеп мондый тормышка түзмәк кирәк! Бәләкәй чагымнан ук Казанда яшим мин, җәмәгать. Әти-әнием ваба чиреннән үлеп, гүр иясе булдылар. Мин бәләкәй малай, нужа куып, бер сынык икмәк артыннан килдем монда. Инде килү белән, ярый, мин бичараны шушы Крестовниковның сабын заводына эшкә алдылар. Инде менә бу историягә илле елдан артык вакыт узды. Илле елдан артык гомеремне, җанекиләрем, байга хезмәт итеп уздырдым. Исәпләә инде, значит, бөтен гомерен бай өчен эшләде дип. Инде шуның өчен ни чыкты миңа, җәмәгать? — Ул тынып халыкка карап торды. — Менә нәрсә, — диде, күлмәк изүләренә тотынып, — җыртык киндер күлмәк, ямау салган чалбар! Әллә сез мине юри шулай фәкыйрь киенеп килде дип беләсезме? Юк, җанекиләрем, юри түгел. Булганы шул. Тешләр коелып бетте, авыррак әйбер күтәрсәм, буыннар калтырый. Ә бит эшләмәсәң, сиңа акча бирмиләр. Ә эш авыр, җәмәгать. Син карт, артык ватылма, диюче юк, әз генә мастер әйткәнчә булмаса, «ананны» дип аты-юлы белән тотына ул. Инде шуны да әйтим, җанекиләрем, нинди гөнаһ шомлыгына каршы татар булып туганмын мин?! Татар баласы булмасам, әллә, бәлкем, акчалырак эшкә дә күтәргән булырлар иде. Юк, аллам сакласын, барлык эшнең серләрен әйбәт беләм, тик якын да җибәрми начальство, син татарин гололобый, син бит хайван, тыгылма, дип кенә тора. Илле ел буена, завод ачылганнан бирле, Крестовниковка тир түгеп хезмәт иттем, хәҗәен заводын елдан-ел үстерде, череп баеды, ә миңа нәрсә булды? Менә шул булды, — мине бүген булмаса иртәгә эт урынына урамга чыгарып ташларлар, мин шунда дөмегермен. Ярый ла, малайлар үлгәнче тәрбияләсәләр. Ә бит аларны да, җанекиләрем, шул ук нәләт төшкере язмыш көтә. Үлсәк үлик, туганнар, үзебезнең правабызны даулап үлик. Мин корал күтәреп бәдбәхетләрнең җаннарын җәһәннәмгә җибәрү өчен әзер. Әйдә, рәхмәт әйтерләр балаларыбыз, балаларыбызның балалары рәхмәт әйтер. Менә мин шулай дип барам. Мин инде ул илле ел хуҗага эшләп күкрәгеп череткән Мифтахетдин Сәмигулла улы булам!

Мифтахетдин агай артыннан төп өстенә Галимҗан Сәйфетдинев күтәрелде. Садыйк бу кешенең Хөсәеннең иң якын дусларыннан берсе икәнен белә иде. Аның заводка килеп йөргәнлеген, прокламацияләр таратышканын һәм аларны басуны оештыруга бик нык катнашканлыгын ишеткәне бар иде. Садыйк Галимҗанның митингларда ясаган чыгышларын да тыңламады түгел. Ләкин Галимҗан бүген аерата шәп итеп ялкынлы нотык сөйләде. Кинәт Садыйкның күз алдына бөтен тулылыгы һәм барлык фаҗигасе белән узган тормышы килеп басты. Садыйкны әнисе мастерскойда туку станогы янында тапкан. Туку станогындагы сосалар гомере буе Садыйкның күз алдыннан китмәстер. Күрәсең, әнисенең карынында чагында ук ул тукучы һөнәрен үзләштергән иде. Ләкин аннан ни файда? Оста куллар аңа бәхет китердеме соң? Ул кимсетелү һәм җәбердән башка берәр нәрсә күрдеме? Кая гына барса да, аның йөрәк сызуы үзе белән булмадымыни?! Ул һәр даим үзен тончыктыргыч баз эчендә яшәгәндәй тойды. Шул һаваны тоткарлаган капкачларны пыран-заран итеп ертып ташлыйсы иде дә, саф һава сулап, ирекккә, яктыга чыгасы иде!

Садыйк ораторны тыңлаганда шулай уйланды. Ләкин моны ул, күрәсең, үзе генә кичерми иде. Аның уң ягында торган Тәгъзимәнең дә күзләре ялтырый, ул да еш-еш сулый, әйтерсең лә, оратор ул әйтергә теләгән сүзләрне нәкъ үзе уйлаганча килештереп сөйли иде. Хатынның һич көтелмәгәндә иреннәре селкенә башлады. Ул, тәгаен, я әйтелгәннәрне үзенчә кабатлый, я булмаса үзе өстәп бара иде.

Галимҗан Сәйфетдинев сүзен бетергәч, алан алкышлар белән тулды. Аннары кинәт тирә-юнь тынып калды. Шул чак Тәгъзимәнең: «Ничек түзик соң, ничек, и ходаем?» дигән сүзләре ишетелеп китте. Хөсәен кинәт аңа таба борылды да йомшак кына: «Сөйләр сүзегез бармы әллә?» — диде. Тәгъзимә ниндидер көч аркасында алга омтылды. Садыйк, аның беләгеннән тотып, «Сөйлә, әйт сүзеңне, Тәгъзимә», — диде. Хатынга агач төбенә менәргә ярдәм итте. Тәгъзимә, югары күтәрелгәч, бераз каушап, тирә-ягын күздән кичерде. Аннары әкрен, зәгыйфь бер тавыш белән кыюсыз гына сүз башлады:

— Без бик каты, аяктан егылырлык каты, алҗыганчы эшлибез, — диде ул. — Ә алган палучка ашарга җитми. Безне һаман талыйлар, акчабызны алып калалар, юкка-барга штраф салып интектерәләр, тиешеннән артык эшләтәләр. Машинада утыра-утыра аякларыбыз ойый, шешә, тынчу һавадан башларыбыз сызлый. Ә мастер Пальчиков безгә эткә кычкыргандай кычкыра. Без көненә унөч сәгать эшлибез. Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр. Өйгә кайтып кергәндә безнең кешелегебез калмый. Ә кемгә җалу белән барасың? Барыр кеше юк! Нәчәлникләр барысы да бер яклы, барысы да мастерны яклый. Пальчиков, үзе кара, балаларны, кыз балаларны кыйный.

Кинәт Тәгъзимәнең күзләрен яшь элпәсе каплады. Ул еламсырап:

— Безнең кызларыбызны кыйный ул, аларга оятсыз сүзләр әйтә, — диде. Тәгъзимә ярсып кулларын өскә күтәрде һәм: — Карагыз, зинһар, менә шушы кулларга карагыз! — дип кычкырды. — Бер генә киселмәгән бармагым да юк бит. Әллә сез мине карт дип уйлыйсызмы? Юк, миңа нибарысы утыз биш яшь, ә миңа инде карчыклар кыяфәте кергән. Нигә кирәк безгә мондый тормыш, абыйлар, әйтегез?!

Садыйк кинәт сул ягында торган Фәрхетдиннең мыштым гына артка чигенүен абайлады. Егет, сиздермәскә тырышып, әкрен генә халык төркеменнән чыга иде. Садыйк, сәерсенеп, аны күзәтә башлады. Фәрхетдин мәйданнан читкәрәк китте дә мәче җитезлегендә агачлар арасына кереп югалды.

Садыйкның күңеле «жу» итеп китте. Бу нинди хәл, әллә бу җүнсез малай безне сатмакчы буламы?

Садыйк та ашыгып, халыкны этә-төртә, агачлыкка таба бара башлады. Фәрхетдин артыннан урманга ташланды. Байтак вакыт агачлар арасында йөргәннән соң, иелә төшеп урман эчендәге тар сукмакка таба баручы Фәрхетдинне күрде. Садыйк Фәрхетдинне инде урманнан чыгар алдыннан, ферманың таш биналары күренә башлагач, куып җитте.

Ул аны каты итеп кулыннан эләктерде:

— Син кая барасың болай, сволочь, сатлык җан?

Фәрхетдин куркуыннан сыгылып төште. Бермәл күзләрен беткәнче ачып, ни әйтергә белмичә торды, аннан кулының авыртуына йөзен чытты.

— Син кая барасың, дип сорыйм мин синнән?

Ниһаять, Фәрхетдин өнен җыйды.

— Мин киттем, абый, гаеп итмә, мин киттем...— диде ул.

— Син беркая да китмисең! Башың ике булмаса, китмисең.

— Абый җаным! Миңа кирәкми болар. Кирәкми! Алла хакына! — Фәрхетдин буш кулы белән изүенә ябышты. Садыйк атның өч аягына җитәрлек акчаның изү эчендә икәнлеген белә иде. Ул, ачуына түзә алмыйча, Фәрхетдинне этеп җибәрде.

— Җаныңны алам мин синең хәзер!

— Абый җаным, Садыйк абый. Мин... берегезне дә сатмам.— Фәрхетдин кибеп киткән авызын чапылдатып алды.— Озакламый җыела. Валлаһи газим, дим, Садыйк абый. Җибәр мине. Алла хакына...

Садыйк Фәрхетдиннең кызганыч һәм ачу китергеч кыяфәтенә нәфрәт белән бераз вакыт карап торды.

Кинәт ачык һавадагы ресторанда тынлы оркестр уйный башлады.

— Бар кит, куркак җан,— диде Садыйк.— Кит! Югал! Тик безне сатсаң, менә бу кулларны күрәсеңме?..

Ул җиргә төкерде дә, борылып, урманга кереп китте. Артта музыканың яңгыравык җиз тавышы калды.

## Чистайга сәяхәт

Трофим Завадскийның хәле шәп түгел иде. Менә бер айга якын инде ул Хөсәеннәрдә ята. Бибифатыйма аны үз улыдай итеп карый. Аның алдыннан тәмле ризык өзелми, соңгы көннәрдә Нәкыя аңа Аркадия, я Бакыр бабай бакчасыннан кымыз алып кайтып тора. Хөсәен берничә тапкыр доктор Дәүләткилдиевне чакыртты. Хәдичә ничәмә төрле дару табып алып кайтты. Ләкин авыруның хәле әз генә дә яхшырмый иде. Җитмәсә, тышта сандугачлы яз бит! Трофим, кояшта җылынып, сәгатьләр буе террасада утыра. Тик шулай да... Булса да була бит! Шундый кирәкле бер вакытта тәҗрибәле революционер урында кадакланып ятсынчы!

Хәер, әгәр Хөсәен апрель төннәренең берсендә аны кыз урлагандай яшереп кенә өенә алып кайтмаса, тәгаен, ул хәзер кояш яктысын да күрә алмаган булыр иде. Ләкин болай ике чик арасында җан саклап яшәү дә һич канәгатьләндерми иде аны. Барасы иде менә иптәшләр белән маевкага, күңелләрне дөрләтеп яндырырлык сүзләр сөйлисе иде шунда! Йөрисе иде стачкалар, забастовкалар оештырып, атасы иде дары базларына утлы факелларны! Кабынсын, шартласын иде бу чәнчелгере гаделсез тормыш! Ләкин тәндә дә, беләкләрдә дә көч-куәт юк иде. Трофим урыныннан бик зур авырлык белән генә кузгала, күкрәген тотып, иелгән хәлдә генә йөри.

Өченче съездның Лондонда булганлыгы мәгълүм иде. Хәбәрләрдән шул съездга киткән Саммерның юлда тоткарлануы, соңгарып баруы һәм әле дә тиз генә кайта алмаячагы мәгълүм булды. Комитет членнарыннан Адоратский да хәзер Франциядә. Свердлов та Казанда

түгел. Кыскасы, шундый җаваплы бер чор хәзер, шул кадәр кеше кирәк, ә Трофим көннәрен ятакта аунап уздыра.

Съездның карарлары әлегә кулга кермәсә дә, анда каралган мәсьәләләр яшерен хат буенча мәгълүм иде. Хөсәен съездның рус булмаган милләтләр арасында эшне көчәйтергә, хәтта ул телләрдә большевистик матбугат булдырырга дигән фикеренә куанды. Ул бит менә кайчаннан бирле инде татар телендә газета чыгару турында хыялланып йөри! Һәм хәзер Хөсәен газета булдыруны ерактагы бер хыял итеп түгел, ә үзенә тапшырылган партия йомышы дип караячак.

Әлбәттә, яңалыкларның күбесен Завадский Хөсәеннән ишетеп белә иде. Башка иптәшләр дә килеп чыккалый, ләкин Хөсәен, кагыйдә буларак, һәркөнне Трофимга яңа хәбәрләр алып кайта. Мондый минутларда ул үзенең авыру икәнлеген дә оныта, йөрәксенеп урыныннан сикереп тора, киенеп чыгып китәрдәй була.

Хөсәен авыру иптәше янына бүген төнге унбердә керде. Ямашевның киемнәренә тәмәке исе сеңгән, ә үзе шат иде. Ул инде вакытның соң икәнен дә белә, ләкин шул ук вакытта авыру иптәшенең түземсезләнеп үзен көтүен дә аңлый.

Хөсәен пинжәген иңбашына салган, галстугын чишеп бушаткан, күлмәк якасы төймәсен ычкындырып җибәргән. Ул караватянындагы утыргычка урнашты.

— Я, нихәл, Трофим, кәеф нишли?

Трофим әрнеп елмаеп куйды:

— Көндәгечә, дустым.

Хөсәен үрелде дә авыруның маңгаен тотып карады.

— Шулай да бүген синең температура төшенке кебек, — диде ул.

Завадский бу сүзләрнең бары күңел күтәрү өчен әйтелгәнлеген сизенә иде, кәефе кырыла төшеп кашларын җыерды.

— Анысын доктор тикшерсен инде, — диде.

Хөсәен елмаеп җибәрде. Трофим бу юлы аңа үтенгән төсле карады:

— Зинһар, тилмертмә, Хөсәен. Сөйлә.

Хөсәеннең күзләре бердән очкынланып киткән кебек булды.

— Бүген «Пролетарий»ның съезд номерын алдык,— диде ул һавалана төшеп. — Алдык та...

— Я, я? — диде Трофим, җанланып, — теге ишетелгән хәбәрләр дөрескә чыктымы?

— Дөрескә чыкты, — диде Хөсәен. — Кораллы восстаниегә чакыра Үзәк!

Трофим яткан урынында кыбырсый башлады. Ниһаять, ул башын күтәрде.

— Хөсәен, аңлыйсыңмы син минем хәлемне?! — диде ул кинәт, ниндидер күңелне тетрәткеч газап белән. Хөсәен аның ябык йөзенә текәлде. Әйе, Хөсәен аңлый иде. Завадскийның киң маңгае өстәлдәге лампа яктысында ялтырап күренә, күзләре эчкә баткан, ә аскы ирене дерелди. Хөсәеннең кинәт чигәләре чыңлап китте.

— Их! — дип куйды Трофим. Хәлсезләнеп башын мендәренә салды. Хәзер аның йөзен караватбашындагы җәймәдән төшкән күләгә каплый, Трофимның күзләрендәге авыр кичереш шәүләләрен ул Хөсәеннән яшерә иде.

— Я, сөйлә, ничек булды җыелыш, тегеләр нишләде? — дип сорады Трофим бераздан. Күрәсең, ул үзен кулга алган иде. Аның «тегеләр» дигәне, әлбәттә, меньшевиклар, яңа искрачылар иде. Хөсәен моны аңлады, салмак кына сөйли башлады. Ул җыелышның бик шау-шулы һәм җанлы булганлыгын, күпчелекнең «Пролетарий» яклы булуын әйтте. Хөсәен күптән белә инде, Трофим өчен вакыйгаларның һәрбер вак-төягә дә кызыклы. Хөсәен аңа әле үткән айда гына Женевадан

кайтып төшкән Кливанскийның өченче съезд билгеләгән тактик линияне танымыйча, меньшевиклар оештырган Женева конференциясенең резолюциясе яклы булуын хәбәр итте.

— Ләкин аларның эш хәерти, — диде ул, — аны яклап элекке комитетчылардан берничә сакаллы адвокат кына чыкты. — Бераз тынып торгач, уйчанланып: — Ә шулай да без бик аз, — диде. — Без, Казандагы РСДРП членнары, ике йөзгә дә тулмыйбыз бит. Ә Казан кебек шәһәрләрдән саналмый бит. 132 мең кеше яши бирелә. Алафузов һәм Крестовников заводларында гына да биш меңнән артык эшче...

— Мин аны беләм, — диде Трофим. — Бу безгә төшкән җаваплылыкның нинди зур икәнлеге турында гына сөйли, Хөсәен дус.

Май башларында ук «Волга», «Самолет», «Надежда», «Кавказ һәм Меркурий» пароход җәмгыятьләрендәге грузчиклар эш ташлады. Алар арасында еш булырга, стачкаларга оешканлык кертергә, таләпләр куйганда, администрация белән сөйләшүләр алып барганда, эш ташлаучыларга һәртөрле ярдәм күрсәтергә туры килә. Май бәйрәменнән соң эш ташлау яңа бер көчле дулкын булып бөтен Казан һәм аның тирәсен айкый башлады. Казандагы Лок фабрикасы паркетчылары, Морквашпар тегермәне эшчеләре, Шабановның күн-тире заводы, Бондюг химия заводы эшчеләре, Казан трамвайчылары баш күтәрде. Стачкалар өермәсе барысын да үзенә буйсындырырга ашкына кебек иде. Мондый җанлану көннәрендә рульне кулдан ычкындырмаска, боларның барысына да дөрес революцион юнәлеш бирергә кирәк иде.

Хөсәен, шундагы хәлләрне сөйләгәч, бүген булып узган гыйбрәтле дә, көлкеле дә вакыйгаларга кереп китте.

Бөтен өй эчен яңгыратып күрше бүлмәдәге зур сәгать төнге уникене житкәнлеген хәбәр итте. Хөсәен урыныннан торды.

— Ярый, Трофим, — диде ул, дустына хәерле төн теләп, чыгып китте.

Хәдичә ятмаган иде әле, ул, иренең аяк тавышларына сискәнеп, өстәлдән башын калкытты. Йокымсыраган күзләрен кул арты белән ышкып, елмаеп куйды.

— Аш суынып беткәндер инде, бер алдым, бер куйдым, — диде ул.

Хөсәен тәлинкәгә аш салды да борыч сибә башлады.

— Менә нәрсә, Хөсәен, — диде Хәдичә ничектер серләрәк бер тавыш белән. — Бүген иртәнчәк будочник Гайнулла абзый килеп китте.

— Шуннан?

— Ул кемнеңдер чагуы буенча...

Хөсәен Хәдичәнең йөзенә текәлде.

— Ничек «чагуы»?

— Шулай. «Сездә ниндидер ят кеше тора икән, — ди. — Дөресме шул? — ди. — Тикшерергә кушты.лар», — ди.

Хөсәеннең йөзе агарынып китте, кулындагы кашыгын тәлинкә читенә куйды.

— Ә син нәрсә әйттең соң, Хәдичә?

— Мин беркем дә юк, дидем. «Ярый алайса, шулай дип әйтербез , — диде Гайнулла абзый. — Тик инде мине уңайсыз хәлдә калдыра күрмәгез берүк», ди.

Хөсәен:

— Каһәр суккыры! Ничек соң, кем? Әле моңарчы бу яктан тыныч иде бит, — диде. Бераз тынып утыргannan соң, кинәт исенә килгәндәй, кабаланып аш ашарга керешге. Ниһаять, тынычлана төште ул.

— Зарар юк, — дип куйды. — Тик будочникның гына хәтерен калдырмагыз. Бирегез. Бирегез, берни дә кызганмагыз. Ике-өч көн тыныч узса, мин Трофимны авылга алып китәм. Доктор, сезнең урамның һавасы начар, Крестовников заводы бөтен дөньяны сасыта, ничек шундый урында үпкә чире белән интеккән кешенең терелүе мөмкин, ди.

Ул сорау белән Хәдичәгә текәлде.

— Үзенә сиздермәгәнсездер бит?

— Ходай сакласын, — дип куйды Хәдичә, куркынып.

— Шулай да, ничек белүләре мөмкин? — дип кызыксынды Хөсәен, рәнҗү аша елмаеп башын селкеп торды. — Без бит инде барлык саклану чараларын да күрдек, югыйсә.

— Син өй эчендәгеләрдән шикләнми торгансыңдыр бит, — дип сорады Хәдичә, кинәт кырысланып.

Хөсәен елмаеп куйды.

— Андый ахмак сүзләрне икенче әйтмә, Хәдичә. Башыма да кереп чыкканы юк.

Хөсәен ит белән бәрәңге ашарга кереште. Хәдичә аның суырылып калган йөзенә, кызу-кызу хәрәкәтләнгән яңак мускулларына, бер төшеп, бер менеп йөргән тамак төеренә карап утырды.

Хөсәеннең авылга китәм дигән сүзләре хатынның күңеленә сизелерлек тәэсир иткән иде. Ул Хөсәенгә карап шуның турында баш ватты.

— Авылга китәм, дисең син... — диде ул, ниһаять.

— Әйе, Хәдичә, Трофимны тыныч, әйбәт авылга урнаштырырга кирәк дигән фикергә килдек. Казан һавасы ярамый аңа. Мин моны соңрак эшләмәкче идем, ләкин, эш болайга киткәч, тизләтергә туры килә инде.

— Ә кая илтмәкче буласың?

— Мин аны Чистай ягына алып барырга кирәк дип уйлыйм. Анда минем ышанычлы кешеләрем бар.

— Алайса мин дә синең белән китәм, — диде Хәдичә үзсүзләнеп.

— Мин анда Трофимны озату өчен генә бармыйм бит.

— Булсын, — диде Хәдичә.

Хөсәен тагы, тигез ап-ак тешләрен күрсәтеп, дустанә елмайды.

— Син мине, әгәр үзем үтенмәсәм, маевкага да алып бармаган булыр идең әле, — диде Хәдичә.

— Әле дә бәхетең, ул-бу булмады!

— Җитәр, Хөсәен, — диде кинәт катгый рәвештә Хәдичә, — мин синең белән беренче елымны гына яшәмим. Мин барысын да беләм, арыдым мин ялгызлыктан. Минем дә нидер эшлисем килә.

— Ничек, арыганга күрә генәме? — диде Хөсәен ашавыннан туктап.

— Юк, — диде Хәдичә, — аның өчен генә дә түгел. Мин бик күп уйландым, Хөсәен. Минем, я миндәй кешеләрнең сүзенә хатын-кыз мохтаҗ түгелмени? Бигрәк тә безнең халык арасында, татар хатын-кызлары арасында.

Хөсәеннең теш агартуын күреп, Хәдичә рәнҗүле караш ташлады.

— Нигә елмаясың?

— Сөйлә, зинһар, дәвам ит, — диде Хөсәен. — Яратып кына елмаям.

— Менә шул. Сүзем бетте, — диде Хәдичә, — мин дә синең белән китәм.

Дүрт көннән соң алар Кама пароходына билет алдылар.

Трофим өстенә Минһаҗ абзый киемнәрен кигән иде. Ул пароходка керү белән каютага бикләнде.

Хөсәен белән Хәдичә, авыру «абзый»ларын урнаштыргач, күбрәк беренче класс салонында зур корсаклы рус сәүдәгәрләре, фрак кигән бай малайлары һәм хәтсез зур эшләпәләр кигән, нечкә билле, зур күкрәкле мадамнар барган җирдә булдылар. Өске киемнәренә караганда Хөсәен белән Хәдичәне дә салондагылардан артык аерып булмый иде. Хөсәен өстенә шәп трико костюм, башына котелок кигән, муенга модный бант бәйләп җибәргән. Хәдичә дә корсетны булдыра алганча ныграк кыскан, соңгы модадагы эшләпәсен, күпермә иңбашлы, озын итәкле, шулай ук модасы әле кычкырып торган иң яхшы күлмә-

ген кигән. Хөсәеннең кулында трост. Хәдичә кулында матур ташлар белән бизәлгән ридикюль иде.

Кыскасы, аларның тышкы кыяфәте беренче класс пассажирлары арасында ким-хур булырлык түгел иде. Ни әйтсәң дә, бай кияү үзенең яшь кәләше белән Чистайның күренекле сәүдәгәре саналган кайнатасына кунакка кайта. Алар шулай сер сынатмаска тырыштылар. Хөсәен салонда хәтта бераз карта да уйнап алды. Икмәк җыючы Чистай бае белән ул көндезге аш вакытында бер өстәлгә туры килеп, аны сыра белән дә сыйлады. Хәлбуки, юлчылар тыштан никадәр ваемсыз булып күренмәсеннәр, шик чак кына төшә калган хәлдә дә аларның эшләре бик хәтәр иде.

Каютада авыру «кардәш абзый» үзе генә түгел, аның белән тагы ике чемодан яшерен әдәбият бар. Ул авыл өчен, рус һәм татар телендә Саратов РСДРП комитеты төзегән, соңыннан «Пролетарий» газетасы тарафыннан да хупланган авыл түгәрәкләре программасы, крестьян мәсьәләсенә багышланган брошюралар һәм мәкаләләр, төрле прокламацияләр...

Ләкин, бәхеткә каршы, ул-бу булмады. Полиция күрми калды. Кунаклар хәвеф-хәтәрсез барып җиттеләр. Чистай пристанендa ыгы-зыгы. Хәдичәнең әтисе җибәрткән фаэтон һәм бер гади арба кунакларны әллә кайчаннан бирле көтә икән инде. Хөсәеннәрне алырга Хәдичәнең якын туганнары, яшь-җилбәзәк төшкән иде. Алар пароход туктау белән ябырылып каютага ташландылар һәм тиз арада барлык әйберне, шул җөмләдән авыру Завадскийны да фаэтонга урнаштырдылар. Ниһаять, кунаклар Хәдичәнең туып-үскән, аңа һәрбер почмагы, һәрбер тәрәзә төбе, гөлләре, трюмалары кадерле һәм таныш булган бер катлы зур өйгә керделәр.

Әнисе, ишле туган-тумача, асрау кызлары үзләренең кавышу шатлыкларын ачыграк сиздерергә тырышалар. Өй эчен куанычлы авазлар басып китте.

Хәдичәнең әтисе әле кибеттә иде. Күп тә үтмәде, кунаклар юынып, кием алыштырып, табын тирәсенә утырырга җыенганда Зариф Бадамшин да кайтып керде. Ул кеше зур корсаклы, кара тутлы бер сәүдәгәр иде. Күрәсең, аның бик зурдан булмаса да ярыйсы гына байлыгы табигатенә йогынты ясаган, ул үзенең дәрәҗәсен нинди генә хәлләрдә дә онытмый, вәкарь саклый. Ләкин шул ук вакытта бик шук телле, үткен сүзле дә иде.

Ул кияүеннән бик разый иде. Аны беренче күрү белән үк яратты. Барыннан да сәеррәге шул иде тагы: ул Хөсәенне үзенең фикердәше дип исәпли иде. Аныңча, илдә башланган буржуаз-демократик революция Зарифка бик матур кәсеп уңышлары вәгъдә итә. Тик ул дөрес юнәлеш кенә алсын, иң беренче чиратта сәүдә өчен, рус купецлары белән ярышта мөселман агай-энесенең мөмкинлекләре генә ачылсын! Ул бу эштә эшчеләрнең ду кубып йөрүләрен аңламый, ә приказчик халкының нинди дер профсоюзлар, эш сәгатьләре, ял көннәре турындагы әңгәмәсен бөтенләй ахмаклыкка саный, чөнки әгәр аңа һәм аның кебекләргә әйбәт булса, шул ук эшчеләргә, приказчикларга да яхшы булачак бит инде!

Ул шундый караштагы кеше иде. Хөсәеннең кайбер мәсьәләләрдәге дуамаллыгын да ул яшьлеккә сылтап гафу итә. Ә инде аның партияле икәнлеген һәм Казан РСДРП комитеты члены булуын башына китергәне дә юк иде.

Ул әле кызы белән кияүенең кайтып төшүенә бик шат иде. Җилләнеп, авыр сулап, ишеккә чак сыеп кайтып керү белән ул кияүен кочагына алды. Йонтәс кулы белән аның аркасын каккалап, үзенең әлеккечә яратканлыгын белдерде. Аннары ул кызының чәченнән сыйпап, маңгаеннан үпте. Күзләренә тирән креслода утырган хәлсез һәм ябык

Трофим чагылгач, бер мәл аптырап, кияве белән кызына карап алды. Хәдичә беренче булып сүз башлады:

— Безнең бик якын кешебез ул. Ул безнең репетитор, Хөсәенне университетка әзерләүче. Милләте буенча рус ул үзе.

Зариф авыр кара кашларын җәһәт кенә бер җилпеп алды да:

— Нигә, бик әйбәт, урысча да ипи-тозлык беләбез, — диде. Ләкин юкка гына үзен кимсетә иде ул. Сөйләшә башлагач, аның «урысыңны сатып җибәрерлек» шәп сөйләшүе ачылды. Алар ак ашъяулык ябылган, сый-нигъмәт белән тулган табын тирәсенә утырыштылар. Гадәттәге юл мәшәкатьләре, туган-тумача, дус-ишнең исән-саулыгы турындагы сүз беткәннән соң ук, Хөсәен әңгәмәне Трофим мәсьәләсенә күчерде. Чәйдән соң ук юлда тәмам алҗыган Завадскийга бер бүлмәдә ятарга урын әзерләгәннәр һәм ул шунда кереп яткан иде. Хөсәеннәр исә әңгәмә сатып утыра бирделәр. Чистай, Казан хәбәрләре дә сөйләшенде. Рәшит казыйның Казанга килүе, мөселман иттифакы җыелышлары, министрлар комитеты председателе Виттегә һәм эчке эшләр министры Булыгинга иттифак әгъзаларының петиция язуы — барысы турында да сүз булды. Зарифның күңеленә петиция таләпләре бик ятышты. Ул казанлыларны бу эшләре өчен үтереп мактый башлагач, Хәсәен түзмәде, үзләре генә калган бер арада ачы елмаеп:

— Сез юкка куанасыз, эти,— диде.— Әгәр дә чынлабрак уйлансаң, алар куйган таләп бары хаким сыйныфлар өчен генә файдалы.

— Ничек алай?! — диде Зариф күзләрен шарландырып. — Син нык хаталанасың, кияү. Әгәр инде татар белән рус тигез хокуклы булсын дип әйтелә икән, бу хезмәт халкына начармыни? Инде анда мөселманнарга сүз, матбугат иреге бирелсен диелә икән, инде театрлар, көтепханәләр ачылсын, гәзит-журналлар чыгарылсын, мәктәпләрдә дөньяви фәннәр укытылсын диелә икән, болар халык өчен түгелмени?

Зариф ияк очында гына калдырып кыркылган кыска кара сакалын сыпыра-сыпыра Хөсәенгә текәлде. Ул үзенең хаклы булуына әз генә дә шикләнми иде. Ләкин Хөсәеннең йөзеннән әлеге елмаю китмәде.

Бераздан Хөсәен, күрәсе таныш-белешләр бар, дип чыгып китте. Ә калганнар өстәл тирәсеннән әле тиз генә кузгалып китә алмадылар. Туган-тумача бер-бер артлы килә бирде, сүз һаман куерды, чәй өстәлә, самовар яңартыла торды.

Хөсәеннең, чыннан да, күрәсе кешеләре бар иде. Ул үзе белән алып килгән чемоданнарның берсен Казан комитеты кушуы буенча Чистайда калдырырга тиеш. Ул Чистайда китап кибете тоткан укытучы Иван Прокофьевич Конычевка китте. Бу ябык чырайлы, пенсне күзлекле, таушалган сюртуклы блондин аның күптәнге танышы. Хөсәен, кеше юклыгыннан файдаланып, кибеткә керү белән эшнең асылын аңлатып бирде. Конычев, үзенең хәзер күзәтү астында торганлыгын әйтеп, яңа явка бирде.

Хөсәен язылган адрес буенча тузанлы урам буйлап татар ягына таба китте. Алда зәңгәр мәчет, тирә-якта бер катлы соры агач өйләр тезелеп киткән. Кичке күләгәләр озын булып урам уртасына сузылганнар инде хәзер. Капка төпләрендә кешеләр, күпчелеге ир-ат һәм балачага күренә. Май һавасын суларга, гайбәт сатарга, көнбагыш чиртеп утырырга чыкканнар.

Хөсәенгә шәһәр читенә кадәр үк барырга кирәк иде әле. Чистайны ул яхшы белә. Шуңа күрә үзе барасы урамны артык төпченеп сорашырга туры килмәде. Шәһәр читенә җитәрәк аның игътибарын ят, сәер тавышлар җәлеп итте. Кемнәрдер яман акырыша, ухылдап йөгергән кебек иде. Хөсәен капка төбендә таягын күкрәгенә терәп утырган ак сакаллы, хәлсез, ябык бер бабайдан сорамый булдыра алмады:

— Нинди тавыш ул анда?

Карт, көлемсерәп, «зур әйбер түгел» дигәндәй, кул селтәп куйды.

— Сугышалар, безнең мәхәлләнекеләр Бәрнәшкә урысларын тукмыйлар.

«Йодрык сугышлары бер Казанда гына түгел икән», — дип уйланды Хөсәен. Ул бик әйбәт белә. Һәр елны боз каткач, Кабан күле өстендәге Суконный бистәсе руслары белән Иске бистә татарлары да сугышалар. Башта бу ахмак эш бала-чаганың гөнаһсыз уеныннан башланып китә, тимераякта шуып уйнаучы малайлар үзара бәргәләшергә тотыналар. Ләкин тора-бара бу дуамал эшкә олылар да катнаша башлый, ахыр чиктә бу тамаша кемнәрнеңдер башы тишелү, тешләре коелу, я булмаса тагы да хәтәррәге: гарипләнүе, кан коелу, хәтта үлем белән бетә. Тик Хөсәен белгән Кабан күле өстендәге сугышлар бары кыш көннәрендә генә, я көз ахырларында гына була иде. Ә биредә бигрәк тә арттырып җибәргәннәр! Шәһәр белән янәшә торган авыл арасындагы бушлыкта олы-олы агайлар җиңнәрен сызганып, йөрәксенеп, үзләренең көч-куәтләрен кая куярга белмичә сугышалар. Бушлыкка сибелгән халык каты үкерә, бер як икенче якка ташлана.

Урам очындагы калкулыкта йодрык сугышын күзәтеп торучылар да байтак. Алар баскан урыннарында тыныч кына тора алмыйлар, дулкынланалар. Татар агай-энене дәртләндереп кычкырыналар, мактыйлар, я хурлыйлар. Читтәрәк калку урынның иң биек түбәсендә артсыз утыргычта татарлар арасында ук көрәк сакаллы бер рус карты утыра. Картның башында картуз, өстендә биле бөрмәле җиңел бишмәт. Ул, татар арасында утырса да, авыр йодрыгын селти-селти, каршы яктан һөҗүм итеп килгән русларны дәртләндерергә тырыша. «Бей басурманов, не жалей басурманов!» — дип калтыравык ачы тавыш белән кычкыра. Хөсәен шәкерт сымак аксак бер егеттән аның кем икәнлеген сорады.

— Купец Вачигов Макар Яковлевич бит ул, — диде егет, һич исе китмәстән, — әнә күрмисеңмени янында аракысы да бар! Гел шылай кыйлана.

Чыннан да, картның аяклары арасында җирдә авызына стакан каплап куелган бер чирек аракы тора иде.

— Соң шуннан? — диде Хөсәен.

— Шыннан шылай, — диде егет, мишәр акценты белән көйләп, — әгәр дә инде урыслар безнекеләрне бирегә кадәр куып кертәләр икән, купец үзләрен аракы белән сыйлый. Беренче булып кергәнгә стаканны тутырып сала, калганнарына яртышар стакан.

Монысы инде Хөсәеннең тәмам ачуын китерде. Хәлбуки, аның әле бара торган кешесе рус иде...

Хөсәен үзенең бу очракта көчсезлегеннән бөтен күңеле һәм җаны белән сыкранып чаттан борылды.

Ул күрергә тиешле кеше Чистай социал-демократларының тирәюнь авыллар белән иң таныш булганы Степанов дигән карт иде. Казан комитеты кушуы буенча Хөсәен Конычевтан шуңа явка алды. Трофим белән бәйләнеш мәсьәләсен дә шул Степанов җайлаячак. Шул ук вакытта Степанов тирә-яктагы авыллар белән, анда оешкан, я оештырылачак революцион комитетлар белән дә бәйләнеш булдырырга тиеш иде.

Хөсәеннең ишек шакуын ишетеп, ишек алды түрендәге җиргә шактый иңгән тәбәнәк агач өйдән сары сакаллы, житү чәчле Степанов үзе килеп чыкты. Аның өстендә ак күлмәк, жилет, ә муенына тегүчеләргә хас тасма аршын эленгән иде. Ул, ишек ачып, күзлек өстеннән генә, сөзәргә теләгәндәй карап торды да Хөсәенне танып елмаеп җибәрде.

Хөсәен өйгә керү белән үзенең әле генә Иван Прокофьевичта булуын, үзен бирегә ул җибәрүен, житди йомыш белән килүен әйтте. Карт уйланып торды, «Бәлки, чәйләп алырбыз башта, — диде, — андый

житди эш булгач, бәлки, иркенләп утырырбыз, ничек, вакыт тармы?» — диде.

— Хикмәт анда түгел, — диде Хөсәен. — Сезнең заказчикларга бик күренәсем килми.

— Хәзер соң инде, мин барыбер ут яктысында эшли алмыйм, — диде Степанов. — Әгәр кирәк икән, теге бүлмәгә чыгарга була.

— Шулай булса, ярый, — диде Хөсәен, кесәсеннән кәгазьләр алып. Алар өй эченә уздылар. — Бусы сезгә хат. Комитеттан. Монысы «Пролетарий»ның съезд турындагы номеры. Бер генә экземпляр. Бергәләп укырсыз, — диде Хөсәен.

Табын җыеп маташкан олы яшьтәге хатынның Степанов чыгып торуын үтенде. Хөсәен өчен бу сәеррәк иде, чөнки ул аның бик ышанычлы кешесе, үзе белән бергә гомер иткән диярлек туган сеңелесе икәнен белә иде. Кунагының күз карашыннан фикерен аңлагандай, тегүче карт:

— Хафа булма. Кирәкми. Ул барысын да белмәсә яхшырак. Кирәкле эш булса, мин үзем дә әйтәм аңа, — диде.

Хөсәен кинәт Хәдичә белән үзенең арасындагы мөнәсәбәтне хәтерләде. Шулай шул, ул бит үзе дә кайбер нәрсәләрне Хәдичәгә әйтеп бетерми. Һәм аның шулай эшләве бары Хәдичәне кызганудан гына. Никадәр сер күп белсәң, шул кадәр аның җаваплылыгы да арта бит.

Хөсәен Степановка эшнең торышын һәм якындагы бурычларны аңлата башлады. Мәсьәлә Чистайның үзендәге һөнәрчеләр һәм приказчикларга житкәч, карт күңелсезләнеп китте.

— Беләсезме, Хөсәен иптәш, вак һөнәрчеләр белән эш пешми.

— Ни өчен алай? — дип гаҗәпсенде Хөсәен.

— Аерата татарлар арасында эш начар.

— Нигә, кеше юкмыни?

Степанов кулларын җәеп җибәрде.

— Эсерлар, меньшевиклар йогынтысы бик көчле.

Әлбәттә, бу житди нәрсә иде. Хөсәен моны белә дә иде. Татар дөньясында вак һөнәрченең әһәмияте кечкенә түгел. Ләкин нишләргә, ничек итеп алар арасыннан ышанычлы кеше табып, житди эш башларга? Хөсәен Чистайга килгән саен алар белән якыннан танышырга омтыла, ләкин әле бу кадәресе генә житми. Алар белән озаклап аралашырга, күп тапкырлар сөйләшергә, сынарга кирәк. Димәк, вакыт кирәк. Ә бит Хөсәен иртәгә үк Трофимны Талкышка илтеп урнаштырырга тиеш, ул аннан авылларга чыгып китәр, ниһаять, Әлмәткә барачак, аның тирәсендәге авыллар белән бәйләнешне көйләячәк.

Хөсәен Степанов белән бер сәгатькә якын сөйләшеп утырды. Чистайлыларның эшләре турында мәгълүмат алды. Сәгать тугыз тулгач, Хөсәен картка әдәбият тутырылган чемоданны кайдан алырга икәнлеген аңлатты да кайтырга чыкты. Юлда хәзер аңа баягы сугыш чукмарлары да, аларны дәртләндереп торучылар да, аракылы купец та очрамады. Ул юл буена татар һөнәрчеләре арасындагы эшне көйләү турында уйланып кайтты. Шулар арасыннан ышанычлы, юлны башлап йөрүче кеше табарга кирәк. Бәлки, бу эшне Хәдичәгә тапшырыргадыр, дип уйланды ул кинәт. Башкарган беренче житди эше булыр.

Бераздан ул шул план белән яна башлады. Әйе, бу иң реаль план иде. Хәер, аның башка мөмкинлеге юк та. Хөсәен Завадскийны урнаштырырга китә, ә Хәдичә әтиләрендә Чистайда кала. Хөсәен әйләнеп кайтканчы ул барлык эшне башкарып куярга тиеш. Ә булдыра алмаса? Хөсәен тагы бер кабат тикшерде. Ләкин, кызганычка каршы, Чистайда өйләрендә бер караңгыдан икенче караңгыгача эшләп газап чиккән, якты дөньяны күрми яшәгән татар һөнәрчеләрен яхшы белерлек бер генә партия әгъзасы да юк иде. «Булмаса, тәвәккәлләргәдер? Сыныйк. Менә шунда үзенең эшкә сәләтләме, юкмы икәнлеген күрсә-

тер инде Хәдичә», — дип уйланды Хөсәен. Ул, катгый бер фикергә килеп, хатынына бүген үк бурычны аңлатырга булды.

Кайтып кергәч тә, аңа хатыны белән ялгыз калырга мөмкинлек булмады әле. Алар бик озаклап тагы өстәл тирәсендә гөрләшеп утырдылар. Тагы аш ашадылар. Аннары чәйләделәр. Тагы Казан һәм Чистай хәбәрләре, тагы туган-тумача, таныш-белеш турында сүз башланды. Аларның, әлбәттә, иге-чиге булмаячак иде. Сәгать беренче киткәндә генә, ниһаять, барысы да чиратлашып авызны дәү итеп ачып, иснәргә керешкәч кенә көлешеп таралыштылар.

Хәдичә белән Хөсәен аулакта икәүдән икәү калгач, җитди сүз башланды.

— Мин иртәгә Талкышка китәм, — диде Хөсәен.

— Ничек «син» китәсең? Мин дә түгелмени?

— Юк, син дә түгел, Хәдичә, мин генә. Сиңа кайбер эш башкарырга туры килер биредә. Шуңа күрә син каласың.

Хәдичә аптырап кашларын күтәрде.' Чөнки Хөсәеннең моңарчы мондый җитди һәм, әйтергә кирәк, хәтта бераз әмер тонында хатынына йомыш кушканы юк иде.

Хәдичә елмайды, аннан җитдиләнде, ачуы килеп алсуланып китте.

— Аптырама, — диде Хөсәен. — Син бу йомышны партия кушуы буенча дип аңла.

Хәдичәнең йөзе ачыла төште. Алай булса, бер хәер, дия иде аның күз карашы. Хәдичә иренең комитет эшләрен иптәшләренә тапшыргандагы шундый кырыс җитдилеген белә бит. Хәдичә, шактый каушаса да, ире ни генә әйтмәсен, барлык көчен куеп йомышны үтәячәк иде.

— Башка бернинди дә мөмкинлек юк, — диде Хөсәен,— ләкин тиз генә синнән дә муафикъ кеше табып булмый.

— Әйт, эшләрмен, — диде Хәдичә иренә йомшак һәм җылы караш ташлап.

— Ләкин баштан ук үзеңне әзерлә, йомыш җиңел түгел, Хәдичә.

— Ах алла! Әйт соң.

— Беләсеңме, син Чистайдагы чигүче, тегүче, итекче, читекчеләр белән эш итеп, аларга бик күп заказлар биреп йөрергә тиеш буласың.

— Ничек инде?

Хөсәен сынап хатынының матур ак йөзенә текәлеп торды.

— Менә болай, — диде ул. Хатынына ничек бәйләнешкә керергә, ничек итеп ышанычлы берәр кеше табарга кирәклеген аңлата башлады.

Хәдичә, бер сүз дә дәшмәгән хәлдә, бары ризалыгын белдереп, башын гына ия иде.

Иртәгесен Хөсәен пар ат җигелгән фаэтонда Трофимны үзенең ышанычлы дусты, кайчандыр бергә укыган хөр фикерле Талкыш мөгаллименә алып китте.

## Бурлак кызының мәһәре бер бидерә бәрәңге

Хөсәен Трофимны Талкыш авылында урнаштырып, кунакчыл дустында бер көн торгач, Әлмәткә юл тотты. Ерыклыга җитеп, атларны ашаткан арада ул бер яңалык ишетте. Барасы юлының уң ягында калачак бер авылда әле өченче көн генә крестьяннар алпавытның йөз сиксән биш дисәтинә җирен тартып алмакчы булганнар. Өяз исправнигы килгән, крестьяннар белән полиция арасында бәрелеш булган. Хәзергә крестьяннар җиңүгә ирешкәннәр. Ләкин бу эшнең ахыры ни белән бетәчәк? Хөсәен өченче көн булып узган вакыйганы ишетте.

Кичә ни булган, бүгенниләр көтә ул крестьяннарны? Хөсәен өчен бу әһәмиятсез түгел. Ул мондый вакыйганы тыныч кына кичерә алмый. «Тәгаен, бүген булмаса, иртәгә авылга атлы казаклар килер, дип уйланды ул. Рәхим-шәфкатьне белми торган бу ерткычлар кылыч-камчыларын хәтәр уйнатачаклар».

Бөтен тирә-юньдә авыллар хәрәкәткә килә башлаган чак. Хөсәеннең белүенчә генә дә шушы Чистай өязендәге биш-алты авыл крестьяннары алпавыт җирләрен яисә урманын дәгъвалап баш күтәргәннәр. Инде берни дә барып чыкмаган хәлдә дә алар үч итеп алпавытның имениесенә, абзар-курасына, я авыл хуҗалыгы машиналарына ут төртәләр. Кыскасы, авылда да хәзер революция утлары кабынды. Ләкин Хөсәен һәм аның фикердәш партияле дуслары бу стихияле хәрәкәткә бер төзек политик төс бирә алмыйча аптырыйлар. Чөнки кеше житми, чөнки авыл белән элемтә артык чикле. Аерым кешеләр авылларга чыкмый түгел, авылның үзендә дә аңлы крестьяннар күренә башлады, тик шулай да бу хәрәкәт әле тиешле оешкан политик юнәлеш алмаган. Хөсәеннең исә Чистай һәм Әлмәт якларындагы авылларда булып, үз күзләре белән хәлне күрергә ашкынуы нинди булса да берәр файдалы эш башкару теләгеннән килә иде.

Баш күтәргән Ново-Троицк исемле авыл турысына житкәч, Хөсәен түзмәде, кучерга атларны авыл юлына борырга кушты. Әлбәттә, ул нәрсә булса да эшли алуына ышанмый. Бәлки, саклык йөзеннән бу эш бөтенләй кирәкмидер дә. Ләкин Хөсәен алай булдыра алмады. Кучерга әйтүе булды, әле күптән түгел генә ял итеп хәл җыйган юртаклар чирәмле тар юлдан пошкыра-пошкыра авылга таба элдерттеләр. Ново-Троицк дүрт чакрымда гына иде.

Менә, ниһаять, авылның таш чиркәве, салам түбәле фәкыйрь өйләре ап-ачык күренә башлады. Каерылып ташланган басу капкасыннан үттеләр. Күңелне өшетеп җибәргәндәй булды. Ниләр булып узган монда? Халык ни эшли? Авыл чыннан да хәерче иде. Ләкин урамга килеп кергәч, Хөсәенне тагы бер тапкыр аптыраткан нәрсә шул булды: урамнарда бер генә дә кеше заты юк, хәтта берәр эт я мәче дә күренми иде, ичмаса. Бусы инде күңелне бөтенләй шомландырды. Әйтерсең лә, Хөсәеннәр үле авылга керделәр. Күп тә үтмәде, кучерда утырган абзый, Хөсәенгә борылып:

— Ишетәсеңме? — диде. Хөсәеннең дә колагына ерактан килгән ниндидер ят бер тавыш керде. Каршыдагы ачык тәрәзәле өйдән кеше елаган тавыш килә иде. Хөсәен кучерның чабуыннан тартты.

— Туктатып торчы.

Ярсыган атлар көчкә тыелдылар. Тарантас тавышы тынгач, колакка төрле яктан ачык булып елау авазлары керә башлады. Монда бер өйдә генә түгел, берничә өйдә шулай үксеп көйләп елыйлар иде.

— Булган монда хәлләр! — дип куйды абзый, телен шартлатып. Хөсәен арбадан төште дә бер мәл кая барырга белмичә тукталып торды. Ниһаять, ул тәвәккәл адымнар белән якындагы өйгә таба юнәлде.

Юравы дөрес чыккан иде аның. Бу авылда әле генә атлы казаклар взводы булып киткән. Хөсәен тәбәнәк караңгы алачыкка кергәч, агач тапчанда яткан ир уртасы кешене күрде. Йөзе, күзләре канга буялган иде аның, үзе авыр ыңгырашып нидер мыгырдана. Өйдәге хатын-кыз һәм сәләмә киемле бала-чага елый, шаулаша. Хөсәенне күргәч, бөтен өй эче тынып калды. Хатыннар арасыннан яшьрәге, күрәсең, теге яраланган кешенең хатыныдыр, Хөсәенгә таба килә башлады.

— Барин, барин! Сез минем бердәнбер ризык табучымны нишләттегез? Нинди көннәргә калдырдыгыз сез безне өй тулы бала белән?! — диде ул кычкырып.

— Мин барин түгел, — диде Хөсәен саңгырау тавыш белән.— Нигә ирегезнең ярасын юып бәйләмисез?

Хатын шунда ук Хөсәеннең алпавыт кешесе булмаганлыгын аңлады. Аның йөзендәге нәфрәт билгесе гаҗәпсенү белән алмашынды. Хөсәен, кешеләрне үтеп, яралының янына килде дә иелеп аның йөзенә текәлде. Кылыч белән суккаңнар иде. Маңгайдан аккан кан күзләрне каплап оеп каткан. Ләкин кешенең хәле алай үләрлек түгел, күрәсең, кылыч мигә кадәр үк үтмәгән иде.

— Атлы казаклармы? — дип сорады Хөсәен.

— Ә кем булсын тагы?! Ябырылып килеп чыктылар, эт кебек ташландылар...

Хөсәен, дәшмичә, аскы иренен тешләп куйды. Аның йөрәге яна, ачуы бугазына менгән, куллары дерелди иде. Хәзер нинди дә булса чара күрергә кирәк. Бу крестьяннарның беренче чигенүдән соң ук канатлары сынмасын иде. Хөсәен төпченеп сораша башлады. Алпавыт җирләрен тартып алуны оештырып йөрүче кешене әле менә бүген генә төрмәгә алып киткәннәр. Бу яралы кеше исә шул башлыклары Кыштымов дигән крестьянны кулга бирмәскә тырышуы аркасында кылычка эләккән. Хәер, ул гына казак кылычын татымаган иде. Хөсәен байтак өйдә булып чыкты, аларның барысында да суктырылган, кыйналган кешеләр. Хөсәеннең күңелендә халык белән сөйләшү теләге туды. Ләкин бу артык хәвефле эш иде. Ул йөрәге сыкрап авырткан хәлдә фаэтонга утырды. Кучерга кузгалырга кушты. Басу капкасына җиткәч, кесәсеннән бер пачка прокламация алып юлга ташлады. Бу язулар хас крестьянга атап, аларны көрәшкә өндәп төзелгән иде.

.Хөсәеннәр Кичүдә кунып, Әлмәткә икенче көнне генә барып керделәр. Волость үзәге булган авылның алтынга манылган мәчет ае ялтырап күренү белән Хөсәеннең уйлары шунда яшәүче сеңелесе Хәдичә хәлләренә үрелеп ага башлады. Әле ел башында ук, кышкы чиләдә, сеңелесен күрергә теләгән иде бит ул. Хәтта бик, бик күрәсе килгән иде аның. Сөйләшергә, аңлашырга кирәк иде. Шундый ахмаклык ясау мөмкинме соң?!

Хөсәен бу эштә үзен һаман гаепле саный иде. Аныңча, бу гаделсезлекне ничек тә вакытында кисәтеп булыр кебек иде.

Хәзер исә ул Әлмәткә бик тиз барып житеп, шунда ук нәрсәдер эшләргә тиеш. Кара инде, атлары да ничектер акрын юырта башладылар бит!

Ниһаять, менә ул Зәй елгасы буендагы урам, бер катлы зур агач өй. Тәрәзәдән күрделәр, ахры, якынлашу белән, бизәкле сары капка төбенәчә ачылды. Атлар юыртып килгән шәпкә иркен ишек алдына кереп китте. Хөсәенне каршы алырга дип бер төркем кеше шаулашып өйдән чыкты. Хөсәен тарантастан төшкәнче үк күзләре белән сеңелесен эзли башлады. Бер күрү белән Хәдичәнең кичерешләрен аңларга тырышты, арбадан төшүгә башка берәүгә дә игътибар итмәстән, төркем арасыннан сеңелесен йолып алып кочагына кысты.

Хәдичә кечкенә һәм ябык, артыграк кыссаң таркалып-уалып китәрдәй иде. Ул үзе дә әле бала гына бит. Хөсәендә сеңелесенә карата моңарчы беркайчан да булмаган аталарча якын итү тойгылары уянды. Шул ук вакытта, боларның барысына аралашып, ачу китергеч кызгану хисе дә көчәя бара иде. Тамак төбенә төер тыгылып, күзләрне яшь эләпәсе томаларга чамалый иде. Хөсәен сеңелесенең зур, акыллы кара күзләренә карап алды да аның уң битеннән үпте.

Кадерле кунакны каршылау шатлыгын хуҗалар ачыктан-ачык белдерергә ашыгалар.

Хөсәен юаная башлаган кияве Якуп Ильясовның үзенә сузылган кулын тотты. Ишек алдына ишле туган-тумача, дус-иш, асрау хатыннар, ниндидер егетләр, ир-ат чыккан иде. Хөсәен аларның күбесен

танымады, ләкин барысы белән дә күрешеп чыкты. Авыл җире булуына карамастан, Якуп бай тирәсендәге халык үзен иркен тота, европача кыйлана иде. Хөсәен кияүнең шактый шомарган, русчага да оста кеше икәнлеген электән үк белә иде. Ул, ниндидер ханымнар һәм әфәнделәр белән танышып чыккач, кодасын хәтерләп, аны сорады.

— Әти авырып ята, — диде Якуп. — Әйдәгез, рәхим итегез. Юл безнең әйбәт түгел шул, бик изалангансыздыр.

Якуп чын мәгънәсендә либерал һәм тиешенчә кечелекле була белә торган зыялы бер бай иде. Хөсәен ишек алдында салкын чишмә суы белән юынганда, кулына сөлге тотып үзе торды. Гомумән, кияү җирән һәм картрак булса да, сөйкемле кеше иде. Тик аның байлыгыннан файдаланып, яп-яшь бер кызга өйләнүен генә Хөсәен берничек тә кичерә алмады. Һәрхәлдә, бу тигезсезлек, гаделсезлек Хөсәеннең күңелен әле дә ачыттырып-телгәләп торды. Ул Якуп белән сөйләште, аның белән шаяртты, ләкин күңелендәге яраның сыкравын һаман тоеп торды.

Ишек алды түрендә абзар, сарайлар тезелеп киткән. Зур өй белән янәшә генә мунча, аңа өйдән туп-туры керергә дә була. Капканың уң ягында тагын бер бәләкәй генә өй бар. Монысы асраулар, ялчылар тора торган урын. Гомумән, бу ишек алды үзенә күрә бер республика сыман, монда буйсындыручы һәм буйсынучылар яши, монда утаучылар һәм йомыш кушучылар. Хөсәен сеңелесенең хатларыннан укып та, үзе күреп тә белә — Ильясовлардан бер дә кунак өзелми. Кышын-җәен Чистайдан, Чаллыдан яки Казаннан туктаусыз кунаклар килеп тора. Аерата җәйләрен, Әлмәт тирәсендәге урман-кырлар яшәргәч, Зәй буйларының хәтфәдәй тугайлары чәчәккә күмелгәч ишәя алар. Хөсәен юынып, чистарынып, үзенең шул арада кемнәрдер щеткалап, тазартып куйган киемен кигәч, Ильяс бай янына кереп күренеп чыгарга тиеш тапты.

Карт байның менә өч ай инде тамагыннан аш үтми икән. Хөсәен аны күрү белән мәрхүм әтисен хәтерләде. Ул да шулай гомерендә бер генә тапкыр ятып авырды бит, аннары гүр иясе булып китте. Ләкин ул бу кадәр үк бетерешмәгән иде. Ильяс бай исә тире белән сөяккә генә калган иде.

Хөсәен аның янына килеп кергәндә, карт бай түшәмгә карап хәрәкәтсез ята иде. Ул бүлмәгә керүчеләрне күз караларын йөгертеп кенә игътибарыннан кичерде дә шунда ук Хөсәенне танып алды. Юк, шулай да бу кеше Хөсәеннең әтисенә охшамаган иде. Хөсәеннең әтисе беркайчан да мондый байгура булмады. Ә Ильяс бай исә үлем түшәгендә ятканда да үзенең өстенлеген онытмый, һаман тәкәббер һәм горур. Әйтерсең, Иван Грозный үзе ята! Картның бөтенләй чал кермәгән кап-кара сакалын әле яңа гына кемдер тарап куйган, урын җире чип-чиста, күз камаштырырлык. Карт байның башы туңа иде ахры, инде көннәр җылынуына карамастан, башында йомшак кырпулы бүрек. Ул Хөсәенне таныгач, кыяфәтен үзгәртмичә генә сәламен кабул итте.

Якуп белән Хөсәен авыруның караваты янына утырыштылар.

— Казан нихәл? — дип сорап куйды кинәт Ильяс карт. Бу соравы көтелмәгәнчәрәк яңгырады. Чөнки ул Хөсәеннең сәламен дә, тавышын чыгармыйча гына, иреннәрен селкетеп кенә кабул иткән иде.

Хөсәен эченнән: «Әле бирешми икән», — дип уйлап куйды.

— Казан кайный, Ильяс абзый, — диде ул. Хөсәен Казандагы революцион хәрәкәт турында байга сөйләргә микән, юк микән, дип уйланып торды.

— Анысын беләм, — диде кинәт карт, Хөсәеннең уйларын бүлде-

реп, — минә моның кебек кызыл авыз, тар балаклар кайната инде ул тыныч Казанны.

Карт күзләрен акайтып улына карап куйды.

— Алай димәс идем мин, — диде Хөсәен көлемсерн төшеп. Ләкин карт бай, күрәсең, улын чын-чынлап революционер һәм иске, җайлы тәртипләрне бетерергә йөрүче кеше дип исәпли иде. Ул, Хөсәеннең җавабына һич игътибар итмәстән, үз сүзен куәтләде:

— Шулар, шулар! Ходаның биргәненә шөкерана итмәүчеләр. Муеннары асты өскә килгереләр!

Хөсәен өчен бусы яңалык иде. Ул, беркайчан да бу өйдә ата белән ул арасында шундый зур дәгъва-бәхәс бардыр дип уйламый иде.

— Җәдитләр! — дип куйды карт, зәп-зәңгәр кан тамырлары бүртеп торган кипшенгән кулын селкеп. — Син миңа кода урынына калган кеше. Үзең яшь булсаң да, төпле булырга охшыйсың. Анау килгәндә үк яратып калган идем. Әйт син киявеңә, ваз кичсен ул андый көфер эшләрдән. Байлык-мөлкәт җитмиме аңа, игътибар җитмиме? Мин аңа барысын да калдырам, барысын да, ак кәфеннән башка берни дә алып китмим үзем белән. Ә бит, аллага шөкер, тырышлык белән, тир түгеп торгыздым тормышны. Миңа бернинди революция кирәкмәде. Иҗтиһат кылсаң, һәркемгә аллаһы тәгалә бәхет җибәрә. Әйт син аңа!

Хөсәен Якупка күз ташлады. Ул исә, атасының ахмаклыгына оялгандай, чак кына елмаеп, аска карап утыра иде. Ул Хөсәеннең күз карашын тойды һәм, ярар, әйдә, дәшми уздыр, дигәндәй, күз кысты. Тик Хөсәен дәшми кала алмады:

— Нишләде соң ул шул кадәр? — дип сорады.

— Юкны-барны сөйли, кирәкмәс эшләргә тыгыла, җүнсез, тинтәк кешеләр белән аралаша!

— Кемнәр белән?

— Кемнәр белән? Җыен кызыл авыз белән. Анау көнне Гаяз Исхакый килгән, аннан өзлексез Һади Атласов дигәне килеп тора, Фуат Туктаров...

— Шул гынамы? — диде Хөсәен, — мин тагы безнең кияү фәкыйрь крестьяннарны сезгә каршы котырта, итагать итмәгез дип үгетли, байлыкларыгызны тартып алырга өнди, дип уйлаган идем.

Моңарчы түшәмгә карап яткан карт кинәт башын Хөсәенгә таба борды. Аның күзләрендә ачу ялкыннары дөрләп алды.

— Нишләп крәстиән минем байлыгыма тисен?! Мин үзем дә крәстиән, минем этием дә крәстиән булган. Минем крәстиәнгә яхшылыктан башка берни дә эшләгәнем юк. Мин анау елны аларга алпут болынлыгын сатып алып бирдем. Мин, аллага шөкер, моңарчы аларны зәкәттән өлешсез калдырмадым. «Ильяс абзый», — дип кенә торалар. Нигә алар миңа тисен?!

Хөсәен үзенең алдында, гомеремне яхшылык эшләп уздырдым, байлыгым тырышлык аркасында гына дип ышанган кеше ятканлыгын ачык аңлады. Әлбәттә, моның өчен ач-ялангач крестьянның җиргә омтылуы, булдыра алса, басып алырга торуы соң дәрәҗәдәге бер гаделсезлек булып күренә. Һәм бу үлгәнче үз карашында калачак кеше белән бәхәсләшүдә бернинди дә мәгънә юк иде. Хөсәен ата белән ул арасындагы бәхәсне йомшартырга тырышып, берничә сүз әйтте дә урыныннан кузгалды.

— Әниең, җәмәгатең исәнме? — диде карт.

— Шөкер, сәлам әйтеп калдылар, — диде Хөсәен.

— Ярый, бик әйбәт, — диде Ильяс, аннары Хөсәен чыгарга борыла башлагач, өстәде: — Безнең яшь килен дә ярый. Минем аңа начар дип сүз әйтерлегем юк. Ходай гомерен игелекле кылсын. Тик минә Якуп кына... Әйт аңа, ул синең киявең, ат азгыны булып, тайга ияреп йөрмәсен!

Хөсәен Ильяс бай бүлмәсеннән ишекне әйбәтләп ябып чыкты. Ул сеңелесе турында уйлый иде. Либерал буржуа да революционер булып тоелган бер байгуранның килене булсын имеш инде ул!

Хөсәен кунаклар янына чыкты. Анда инде табын әзерләнгән һәм шат, көләч кунаклар күптән Хөсәеннәрне көтәләр иде. Хөсәен сер сынатмаска тырышты, башкалар кебек үк, ял гамьсезлегенә чумып, уенкөлке сүзләр сөйли башлады.

Хәлбуки, аның һаман да сеңелесе белән ялгыз гына калып сөйләшәсе килә иде. Тик хәзергә моның бер дә җае күренми. Хөсәенгә самовар янында кунаклар сыйлап утырган сеңелесенең яшерен тойгыларын күзләреннән укып кына канәгатьләнергә калды. Ниһаять, аш янында шактый озак утырганнан соң, кунаклар һава алырга Зәй буена төштеләр. Хөсәен сеңелесе янындарак булды. Чәчәкле болынлыкка килеп житкәч, алар компаниядән аерылып, икесе генә яр буендагы ап-ак комлы сукмак буйлап киттеләр.

Алар башта тар сукмак буйлап сүзсез генә бардылар. Кешеләр күздән югалгач, Хөсәен, түзмичә, ярсып:

— Нишләдең син, Хәдичә, нишләдең син, сеңелем? — диде. — Син үзеңнең нинди ахмаклык ясавыңны беләсеңме? Мин һич-һич аңлый алмыйм!

Хәдичә җавап кайтармады, аска карап тын гына баруында булды.

— Мин бит күреп торам, — диде Хөсәен, — син аны сөймисең, ул сиңа бөтенләй тиң түгел.

Кинәт Хәдичә телгә килде:

— Хатларымда моңарчы язмадым, абый, — диде ул. — Чөнки болай да барысы ачык дип уйладым.

— Миңа ачык түгел, — диде Хөсәен, күңелсезләнеп. — Мин синең бу эшеңне зур ялгышу дип уйлыйм. Теге вакытны да әйттем. Бу юлы дә дәшми кала алмыйм.

— Шулайдыр, бәлки, — диде Хәдичә, — ләкин хәзер соң инде, абый.

— Соң? — диде Хөсәен коты алынып.

— Соң! — диде Хәдичә.— Хәзер инде, абый, барыннан файдалана белергә кирәк.

— Син өйгә икътисади яктан ярдәм итмәкче булгансың, шулаймы? Ләкин мин партия кассасы биргәнгә канәгать.

— Өйдә син генә түгел ич. Инде әти калдырган мирас күптән беткәндер...

— Бетте ул, — диде Хөсәен. — Ләкин, Хәдичә, эш бөтенләй анда түгел бит. Мин бит сиңа аңлаттым: кеше бәхет өчен көрәшергә тиеш. Әгәр миңа революцион эш бәхет һәм хәтта рәхәтлек бирмәсә, мин ул юлга аяк басар идеммени? Ул минем ихтыяҗым...

— Син шулай уйлагансың, ә мин менә болай уйлыйм, — диде Хәдичә, — бәлки, өйгә ярдәм итә алуым минем өчен җан азыгыдыр?!

— Мин аңлата алмыйм инде алайса сиңа, — диде Хөсәен гаҗиз булып. Ул чыннан да аптырашта иде. Кешенең бәхетле булмавын читтән карап белергә буламы, яки ул үзе генә моны тоямы? Шайтан белсен инде! Хөсәен, ни әйтергә дә базмыйча, кашларын җыергалап уйланып барды. Ләкин тирә-юньдә табигать үзенең язгы уяну бәйрәмен уздыра иде. Тукранбашлар, ут чәчкәләре, күгәрчен күзләре, тагы бик күп төрле матур чәчәкләр белән бизәлгән болын кояшта җәйрәп күз явын ала, күңелләрне рәхәтлек белән тутыра иде. Юл читеннән генә кыр үрдәге пырылдап күтәрелде дә Зәйгә таба очып китте. Хәдичә: «Аһ!» — дип кычкырды. Абыйсының кулыннан тотты. Алар бәләкәй чакларында менә шулай йөриләр иде. Әле күптәнме алар чәчәкләр җыеп, матур киләчәк турында хыялланып Бакалтайда Ишке буенда йөрделәр. Тормыш дигәнең әйтеп бетергесез катлаулы икән шул!

— Абый, мин шулай да бераз акча җыйдым, — диде Хәдичә беравык тынлыктан соң. — мин аны хәзер үк сиңа бирә алам.

Хөсәеннең әле генә гүзәл табигать манзарасыннан туган күңел тынычлыгы секунд эчендә юкка чыкты. Ул, кирәкми, дип авыз ачмакчы иде инде, ләкин, моны сизенгәндәй, Хәдичә, кашларын җыерып:

— Әгәр мине бәхетле итәсең килсә, аласың, — диде.

Хөсәен тиела алмыйча уф орып куйды, сеңелесенең кулын ычкындырды, аннары авырсынып кына авыз эченнән: — Ярар, — дип мыгырдады. — Өлгерермен әле. Әле бүген үк китмим бит мин.

Алар Казан турында, өй турында, әниләре һәм туганнары турында сөйләшә башладылар. Бибифатыйманың соңгы вакытларда еш кына биле сызлаштыргалый иде. Рокыядан хатлар килгәләп тора. Ул үзенең тормышыннан канәгать булса кирәк.

— Минем адаш җиңгәм ничек соң? — дип сорады Хәдичә, абыйсына серле елмаеп күз атты.

Хөсәеннең кинәт ниндидер йөрәк тамырлары тибрәнеп куйгандай булды. Хатынына беренче тапкыр житди эш тапшырганлыгын хәтерләде. Очлап чыга алырмы ул аны? Хөсәен теләгәнчә, Хөсәен өмет иткәнчә булырмы? Ул бераз уйланып барды да:

— Җиңгәң әйбәт, — диде. — Без бик тату, әйбәт яшибез.

— Аллага шөкер алайса, — диде Хәдичә, иркен сулап. — Чыннан да шулаймы?

Ул Хөсәеннең күзләренә туп-туры карады.

— Чын булмаса, мин сиңа болай дияр идеммени?! — диде Хөсәен.

Хәдичәнең күзләрендә ниндидер җылылык чагылды.

— Абый, мин килешә алмассыз дип борчылган идем, — диде ул, көлемсерәп. — Чөнки ул шундый хәлле кешенең иркәлектә үскән кызы бит...

— Юк, алай түгел. Җиңгәң сынатмады, сеңелем.

— Бик әйбәт алайса, аллага шөкер, — диде Хәдичә, тагы кабатлап.

Алар тынып бардылар. Каяндыр бытбылдык тавышы ишетелә иде.

— Абый, беләсеңме, мин сиңа нәрсә әйтмәкче булам?

— Я?

— Мин биредә кешеләр белән, тормыш белән танышып йөрим. Шул кадәр мохтаҗлык, белсәң икән! Шул кадәр авыр яшиләр!

— Шулайдыр, мин аны беләм.

— Тукта, мин сиңа нәрсә әйтмәкче идем соң әле, абый? Менә нәрсә... — Хәдичә, тукталып, арткарак калган абыйсының якынлашуын көтте. — Биредә сине аңлардай бик әйбәт кешеләрне беләм мин, абый. Әгәр аларга берәр юл күрсәтүче, аңлатучы булса...

Хөсәен:

— Кемне беләсең? — дип сорады.

Хәдичә үзе белгән кешенең исемен әйтте. Хөсәен тыела алмыйча көлеп үк җибәрде. Чөнки Степанов нәкъ әнә шул кешегә, Хәдичә әйткән, япон сугышыннан яраланып кайткан Сиражетдинга таянырга киңәш биргән иде.

Хәдичә абыйсының урынсыз көлүенә аптырап һәм рәнҗи төшеп тукталып калды.

— Үпкәләмә, зинһар, сеңелем, — диде Хөсәен күңелле генә елмая бирел. — Синең шул кадәр тырышып миңа ярдәмчеләр эзләвең бик сәер тоелды.

— Мин синең килүеңне дүрт күз белән көттем. Син бит беләсең: мин үзем генә берни дә эшли алмыйм. Миңа бай хатыны дип шикләнеп карыйлар. Мин килеп чыктыммы, барысы да керпе кебек йомарланалар.

— Ә соң бу Сиражетдин абзыеңның шундый кеше икәнлеген ничек белә алдың?

Хәдичә серле генә елмайды да, мактана төшеп:

— Белдем инде, абый, — диде. — Бездә җиде хезмәтче бар. Мине алар бик якын күрәләр...

— Кара син аны, син оста конспиратор да икәнсең әле!

— Менә тагы! Син кем дип белдең мине?!

Хөсәен көлде дә, кинәт җитдиләнеп:

— Моннан соң сиңа шымчыланып йөрергә туры килмәс, Хәдичә, — диде. — Син мине әнә шул Сиражетдинга алып бар. Мин турыдан-туры сөйләшеп, сине аның белән таныштырырмын.

Хәдичә куркынып үк китте.

— Ул сиңа ышанмаячак!

— Бәлки, ышаныр.

Алар шул көнне үк кичке аштан соң Сиражетдиннарга киттеләр. Авыл урамында көтү кайтканнан соң гына була торган бер тынлык урнашкан иде. Бары ара-тирә каяндыр ерактан кызларның такмак әйтүләре һәм киндер тукмаган тавышлар ишетелеп китә. Каз үләне белән өртелгән урамнарда берниндн дә хәрәкәт юк, салам түбәле өйләр генә, барысын да аңлагандай, күздән югалганчы карап озатып калалар. Өйләрнең күбесе янтайган, кайберләренә терәүләр куелган. Читән, коймалар буенда кыргый киндер һәм кычыткан котырып үскән. Кайбер өйләрдә карындык тәрәзәләр аша тонык кына яктылык сирпи. Хөсәен белә: биредә ярлы-ябага бер имана җирдә иген игеп интегүгә караганда, һөнәрчелек белән шөгыльләнүне өстенрәк саный. Җирен сата, үзе чыптадан кап сугарга керешә, я булмаса чабата тукый. Күрәсең, бу ут алынган өйләрдә эш кайный иде хәзер.

Декабрь урталарында Әлмәттә ярминкә башлана. Шунда унар мең пар чабата сатыла. Хөсәен элекке килүендә нәкъ шул ярминкә вакытына тарды. Алар ул чакны Гафур Коләхметов белән бергә булдылар. Ниләр генә юк иде ул ярминкәдә, ат кәмитләре дисеңме, күз буучылармы, курчак театрларымы. Инде товар дигәндә, Мәкәрҗәдән, Богырсланнан кызыл малы да, сбруе, арбасы, чәй-шикәре дә килгән. Ләкин барыннан да күбрәк күзгә ташланганы олау-олау чабата иде.

Ярминкәгә нинди генә яклардан килми халык, урысы да, башкорты да, чувашы-мукшысы да. Әлмәт ун көн буена гөрләп тора. Үзенә бер бәйрәм төсен ала ул көннәр. Кешеләр кирәк-ярак сайлыйлар, акчалары булмаса да, болай тамаша итәр өчен генә дә киләләр. Ир-ат та, хатыннар да җүнлерәк киенә. Мескен бүрекләрнең гает көннәрендә генә киелә торганы, янасы, тула чикмәннәрнең җем-җем каралары, я булмаса манчестер бишмәт, инде хатын-кыз кәҗә мамыгыннан бәйләнгән шәлен, биш билле яңа сатин тышлы бишмәтен кия, яшьләрдә тырнакларга кып-кызыл кына ягылган була, ә олырак хатыннар шомырт җимешедәй тешкара ягалар. Инде көмеш алкалар, беләзекләр, бала итәкле күлмәкләр... Кыз-кыркын, яшь җилкенчәк матуррак киемнәренең барысын да күрсәтеп калырга тырыша. Ә аякта барысының да — ире-хатынының, егете-кызының — шикәрдәй ак тула оек, яңа гына шөшледән төшкән, уенчыктай көлеп торган чабата. Шул чакны инде Әлмәт егетләре сөйгән кызларын кызыл билле прәннек белән сыйлыйлар, шул чакны инде кара мунчаларда, я аулак өйләрдә якын арада очрашу турында вәгъдәләшәләр. Гыйшык хатлары шунда бирелә, шунда инде кызлар үзләренең егетләренә чиккән кулъяулыкларын бүләк итәләр. Хөсәен боларның барысын да белә, шәһәрдә туып үскән кеше булса да, авылның борын-борыннан килгән эчкерсез беркатлылыгына, аның пакьлеккә омтылуына соклана ул.

Ләкин шул ук вакытта авылдагы наданлык, каралык һәм фәкыйрьлекнең котылгысыз иярчене ахмаклык һәм фанатиклыкны да ул ачык күрә.

Каралып-мүкләнеп беткән өй янына килеп житкәч, Хәдичә туктады да арттарак килгән абыйсын көтеп торды.

— Шушында торамы? — дип сорады Хөсәен.

— Әйе, менә шунда керик әле, — диде Хәдичә. Жил капкадан узып, Хөсәен ишек алдына керде. Өйалды ишегенең бавын тартуы булды, эчтән нинди-дер ят бер шакылдау тавышы ишетелә башлады. Ул да булмады, борынга төчкелтем юкә исе килеп бәрелде. Өй ишеге ачык иде. Эчтә чыпта сугалар. Хәдичә алдан керде. Хөсәенгә өй эченә үтү өчен шактый иелергә туры килде. Алай да ишек аның эшләпәсен салдырып алып калды.

Эчтә тынчу һәм караңгы иде. Кешеләрне аерып күрмәсәләр дә, керүчеләр, сәлам биреп, хужалар белән исәнләштеләр.

— Вәгаләйкемәссәлам, рәхим итегез, — диде бер ир тавышы. Ниһаять, күз ияләшә төшкәч, түрдәге сәке, анда кемнәрнеңдер утырганлыгы, йоклап ятканлыгы күренде. Уң якта ян тәрәзәгә каршы чыпта сугу станы тора, аның янында киндер күлмәкле абзый һәм унике-унөч яшьлек малай. Агай чыпта суга, ә малай станның «кылычын» күтәреп тора иде.

Яктылык мич кучкарына куелган чырадан сирпелә иде. Алтыжиде яшьлек, орчыктай бәләкәй кыз шул чыраның утын карап, кирәк чакта күмерен сындырып ала, яңасын кабызып жибәрә иде. Хөсәеннәр килеп керүгә, шул кыз чыра күмерен сындырып учакка ташлады да мич янында идәндә яткан өемнән яңа чыра сайлый башлады.

—Абау, бик тынчу ич өегез, Закир абый, — диде Хәдичә, — Нишләп тәрәзәләрегезне ачмыйсыз?

— Ачып булмый бит, Хәдичә килен, нәнәм, — диде абзый. — Быел елы әллә ниткән, мүр кыргыры сукыр чебен тәкатьсез итә. Әйдә, узыгыз. Нәсимә! Дәш кунакларны түргә, нишләп тик утырасың! Чыпталарны читкәрәк эт. Фәрханә кызым! Абыең белән апаң утырсын.

Кунаклар, өй хужаларының ыгы-зыгысын күреп, һич кузгалырга кирәкмәгәнлеген, бер генә минутка йомыш белән генә килгәнлекләрен әйттеләр. Шулай да чыпталар алынгач, сәкенең бер почмагына утырмый булмады.

— Күтәр, күтәр кылычыңны, авызыңны ачып торма, улым, — диде Закир. Ул бер генә минутка да эшеннән туктамыйча, күнегелгән осталык белән, һич саташмыйча, юкә очларын кулларыннан уздыра иде.

— Йомыш белән килгән идек без. Сиражетдин абый кирәк иде, өйдәме соң ул? — диде Хәдичә.

— Ә, ул күршедә утырадыр. Кулы бер дә жайга килми шул. Менә кайтканына өч ай, ә ярасы һаман бетәшми, — диде Закир. — Бар, улым, кылычны апаң күтәреп торыр, бар, Сиражетдин абыеңа әйт, кунаклар килде, сине сорыйлар, диген.

Малай, бу эштән котылуына шатланган кебек, йөгереп чыгып китте.

— Бу кемең була соң инде, килен? — диде Закир, Хөсәенгә күз атып.

Хәдичә абыйсы икәнлеген әйткәч:

— Әйтәм жирле, бик чибәр, әйбәт киемле, солтанатлы кеше икән! — диде Закир.

— Мин Сиражетдингә Чистайдан әманәт хат алып килгән идем, — диде Хөсәен.

— Шулайдыр, шулайдыр, юкка-барга йөрмәссез. Рәхмәт инде безнең ишеләрне санга суккач.

— Ничек сукмыйсың? — диде Хөсәен. — Ул бит безнең патша хәзрәтләре өчен кан койган, шуның өчен сугышып кулсыз калган кеше!

Закир бу сүзләрнең ниндирәк мәгънәдә әйтелгәнлекләрен аңлап җиткермәде, нәрсә дип әйтергә дә белмичә, нидер мыгырданып кына куйды.

Көннәрен бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләп уздырса да, изелгән басынкы кешегә охшамаган иде ул үзе. Хәтта шаярта да белә икән.

— Безнең тормыш шул инде менә, — диде абзый, — чыпта өстендә туабыз, аннан килеп гомер буе чыпта сугып тормыш итәбез, чыпта исен иснибез, чыпта тузанын ипигә ягып ашыйбыз, чыптага ятып йоклыйбыз, инде тагы кайчак үлгәч тә үзебезне чыптага төреп ләхеткә тыгалар.

Хөсәен сүз дәшмәде, ирексездән көрсенеп куйды.

— Безнең якта «Бурлакларның мәзәге әләмә дә сәләмә, бурлак кызының мәһәре бер биндерә бәрәңге» дип җырлыйлар, — дип сүзен дәвам иттерде хуҗа. Үзе көлеп җибәрде. — Бурлакның кем икәнен белә торгансыздыр?

— Кем соң ул? — диде Хөсәен. — Теге Иделдә баржа...

— Юк, ул түгел. Бездә инде бурлак дип уракка байга ялланучыны әйтәләр. Әйтик, анда син өйләнергә уйладың, ә мәһәрлек рәтең юк, шул чак инде алпавытка барып кышыннан ук уракка ялланасың да мәһәрлек акча аласың. Инде туйларыңны уздыргач, хатының белән тора башлагач, парлашып әйбәтләп кенә мәһәр акчасы өчен урак урырга барасың. Менә шул ул бурлак. Менә без дә Нәсимә апагыз белән шулай өйләнешкән идек. Ник дәшмисең, Нәсимә, шулай бит?

Сәкедә йон эрләп утырган хатын җитез генә борылып иренә карады да, яулык очы белән авызын каплый төшеп:

— И, бытылдап утырма инде кирәкмәгәнне, әллә синең бурлак булып йөргәннәрең берәр кешегә хаҗәтме? — диде.

— Белеп китсеннәр, — диде Закир, акланырга тырышып.

— Шулай, шулай, барысы да кирәк, рәхмәт, абзый,— диде Хөсәен.

Тышкы ишекнең ачылганы ишетелде, ялан аяклы малай ухылдап килеп керде.

— Әйттеңме? — дип сорады Закир.

— Әйттем, — диде малай, «кылычына» яңадан тотынып.

Ул ара да булмады, сәламен биреп, өйгә пәһлуандай таза гәүдәле, иңенә шинель салган чулак Сиражетдин да килеп керде. Ул ни өчен чакыртылуын юрап белә алмаган иде, күрәсең. Ни әйтергә дә белмичә, урталыкта басып калды.

Хөсәен, урыныннан торып, аның янына барды.

— Биредә бик тыгын, булмаса, без ишек алдына чыгыйк, — диде. — Рәхмәт сезгә, — диде ул Закир ягына карап.

— Үзегезгә рәхмәт, — диде Закир.

— Гаеп итеп китмәгез, — дип өстәде хатыны.

Саубуллашып, ишек алдына чыктылар. Арырак киттеләр һәм алгы күчәре сынган, көпчәксез кабык арба янында тукталдылар.

Кинәт шул вакыт һавада йолдыз атылды. Барысы да тынып күккә текәлделәр. Биек өянке артыннан яшь ай карап тора иде. Ахры, болытлар артында булгандыр, моңарчы Хөсәен аны шәйләмәгән дә иде. Борыннарын канат асларына яшереп яткан казлар чак кына каңгылдашып алдылар. Хөсәен Сиражетдинга текәлде. Теге дә, бик игътибар белән танырга һәм эшнең серен аңларга тырышып, Хөсәеннең йөзен күзәтә иде.

Хөсәен арбага утырып папирос кабызды да:

— Мин сезнең белән, Сиражетдин иптәш, Әлмәт волостенда революцион комитетлар оештыру турында сөйләшергә тиеш,— диде.

— Мин андый нәрсәкәйне белмим, сез кем буласыз соң? — диде Сиражетдин куркынып.

— Менә бу кешене беләсезме? — дип сорады Хөсәен, сеңелесенә ишарәләп.

— Әйе, беләм, ул безнең яшь бикә, Якуп Ильясовның җәмәгате.

— Мин аның абыйсы булам, Хөсәен минем исемем. Мин Казан РСДРП комитеты кушуы буенча.

Сиражетдин, берни дә аңламаганлыгын белдереп, тагы башын селкеде. Кара инде син! Хөсәен иң мөһимен әйтергә оныткан иде бит. Ул үкенечле елмаеп кул селтәде дә:

— Степанов Иван Агафонович — Чистай каласында иң оста кием тегүче, сез беләсезме шуны? — дип сорады.

Сиражетдин көлеп җибәрде:

— Менә болай булса аңлашыла бераз. — Ул арбага Хөсәен белән янәшә аякларын салындырып утырды да: — Мин сине тыңлыйм, иптәш, — диде.

Хөсәен сеңелесенә карап алды.

— Моннан соң безнең белән элемтәне яшь бикә аша тотарсыз. — Хөсәен Сиражетдинның сәерсенеп каравын күргәч: — Ул минем сеңелем, — дип өстәде. — Әлбәттә, беркем дә сезнең эшләрне белмәячәк. Ләкин сез аңа тулысынча ышана аласыз. Иң җайлы элемтәче ул. Сез аңа хәбәр итәсез, ә ул миңа яза. Менә бу — беренче. Инде, — диде ул һәм, кинәт тукталып, Хәдичәгә тагы бер карап алды. — Хәдичә, күзколак булчы, зинһар! Безнең сүз ишетелмәсен. Кыз чакларыңны бер хәтерлә.

Хәдичә тирә-юньдә йөреп, карангалап, нидер эзләгән булып һәм нидер тапкан булып маташкан арада, Хөсәен Сиражетдин белән житди сүз алып барды. Алар арбадан төшкәндә алтын урак сыман ай өянкедән шактый ерак киткән иде инде. Хөсәен, Сиражетдинның кулын кысып:

— Ничек тә иртәгәдән дә калмыйча прокламацияләрне алырга киләсез, — диде.

Алар өйгә ашыга-ашыга кайттылар.

— Безнең югалтканнардыр инде, биллаһи, — диде Хәдичә, ут йотып.

— Хәдичә, — диде Хөсәен, кинәт дәртләнеп, — мин үзем белән кирәкле әйберләр алып килдем. Үзебезчә гади, аңлаешлы телдә прокламацияләр басып таратырга кирәк. Моңа син ничек карыйсың, мондый эшкә шартлар табылырмы?

— Минемчә, табылыр, абый, — диде Хәдичә.

«Барлык мөмкинлектән файдаланырга кирәк», — дип уйланды Хөсәен. Ул иртәгә үк Ильяс байның аргамакларын җиктереп күрше авылларга чыгып китәчәк. Аның Казаннан ук алып килгән тагы ике явкасы бар әле. Ул авыл ярлылары белән бәйләнеш урнаштырмый кайтмас!

*(Ахыры бар)*

*Хәсән Туфан*

## Бәйрәмгә килгәндә

(«Лирик хатлар»дан)

Ераклардан, Бөек Октябрьга
Пролог булып калган еллардан,
Илебезнең яңа эрасына
Алып кергән тәүге юллардан,
Хабулларның тавышы килә кебек:
«Ятсак та без
Күптән кабердә,
Безне, энем, бәйрәм җиткәндә хет
Хәтерлә син, бераз хәтерлә...»

Еракларда инде
Ул агайлар,
Октябрьның аргы ягында.
Барактагы «тормыш мәктәбе»н без
Үткән идек шулар янында.

Гренадерлар сыман зур һәм дәүләр,
Юлбарыслар кебек көчлеләр,
«Кузгал!» дигән сигнал булу белән
Ыргылырга әзер эшчеләр
Иде алар.

Сыйнфый серен, йөрәктәге сүзен
Әйтсен генә бары большевик,
Икеләнеп тормас иде алар
«Батыр микән мондый нәрсә!» дип.

Ярлы, ләкин мәгърур иде алар:
«Без, янәсе, гәрчә — йолкышлар,
Ну «прлитар» дигән алтын сүздә
Безнең дә бит, яшьләр, өлеш бар!

Бирешмәгез һич тә капиталга,
Прлитарный яшьләр, янәсе, —
Буржуйларга мать белән дә, димәк,
Мат бирсеннәр Рәсәй яшьләре!

Бусы — сүзнең бисмилласы гына,
Ну бит, яшьләр, аның сере бар:
Малайлар да безнең нише булсын,
«Тешле» булсын бөтен прлитар!

Прлитарның
Ап-ак күгәрченен
Кара козгын чукып алмасын! —
Бәс, янәсе, безнең яшь нәсел дә
Сата алсын буржуй алласын...»

Юк,
Гаепләмим сезне, абыкайларым,
Зимагурлар, «ала канатлар»! —
Чын күңелдән иде, саф йөрәктән
Сез өйрәткән усал «сабак»лар.

Изге иде
Сезнең яралы җан,
Сүзләрегез дорфа булса да.
Эчегездә хәсрәт ялкыннары
Янып, ташып, дулап торса да,
Елмайдыгыз, сыйпадыгыз безне,
Еламаска киңәш бирдегез...
Әй, сез, безнең мәрхүм «прлитар»лар,
Кабатланмас ирләр идегез!

Ах, кайда сез —
Безнең бала чакның,
Малай чакның бөек шефлары,
Бабайлардан калган бай хикмәтнең
Чабаталы «философ»лары!

Ах, кайда сез,
Аю аягыдай
Көчле, ләкин
Ярлы, буш куллар,
Ниндн якын итеп, җылы итеп
Сыйпый белә торган хуш куллар,
Ах, кайда сез...

Ватаныбыз шундый бөек көнгә,
Зур бәйрәмгә килеп җиткәндә,
Мең рәхмәтләр әйтеп эшегезгә,
Исемегезне төреп гөлләргә,
Сагынып сезне, мәрхүм фидакарьләр,
Искә ала туган илегез.
Җиңел булсын сезнең җылы туфрак,
Онытылмаслык ирләр идегез.

## Әхмәт Ерикәй

* * *

Минем өчен Казан — әткәм йорты,
Дуслар ашы, иркәм карашы;
Айкап чыктым бөтен дөньяларын —
Юк бер җирдә аның алмашы.

Минем өчен Казан — җәй җылысы,
Таң сулышы, күңел дәвасы;
Сәлам бирә төсле йолдызлары,
Шифа бирә төсле һавасы.

Минем өчен Казан — эш мәйданы,
Шунда сынаш, ярыш, көрәшләр...
Калдыралсам шунда якты бер эз,
«Гомере зая узган» димәсләр.

Минем өчен Казан — сагыну сүзе,
Үз почмагым, бердәнбер түрем;
Күп гасырлар шунда яшәп килгән
Йөрәк җырым, матур, саф телем.

1967

*Рәшит Гәрәй*

## Яратам мин Ленин районын

Җыр ишетәм гранит ярлар буйлап
Салмак кына атлап килгәндә:
Казанканың талгын дулкыннары
Хисләремә кучеп тирбәлә.

Кичке шәфәкъ уйный су өстендә,
Таллар тибри, әнә, киләнеп.
Дулкын ярып йөзгән ак катерга
Акчарлаклар килә ияреп.

Диварларга сердәш чәчәкләрне
Сулар сибеп кемнәр үстергән!..
Ераkларга карыйм ике ярны
Тоташтырган купер өстеннән.


Төзүчеләр монда алып килгән
Яңа җырның тәүге сүзләрен.
Хәзер инде Кәҗә бистәсенең
Табалмассың иске эзләрен...

Могҗизадай калкып чыккан йортлар
Утырганнар таза нигезгә.
Шул йортлардан төшкән күләгәләр
Тирбәләдер кебек диңгездә.

Балконнарга үрелеп, үрмә гөлләр
Шаулап үсә җилләр иркендә...
Утлар түгел, кичен бүлмәләрдән
Күңелләрнең нуры сирпелә.

Яшьлегемнән синең атлый дуслар —
Яшә — бергә, яшә — аерым.
Яратам мин шуңа безнең якны —
Яратам мин Ленин районын.

———□———




*Нурихан Фәттах*

*Повесть*

*Икенче бүлек*[1]

# САҖИДӘ

## I

Зөһрә белән безнең ара көтмәгәндә бозыла башлады. Минем моңа күңелем тырналды. Төрлечә уйлап карыйм: әллә соң хәтерен калдырдыммы, әллә бик тупас кыланаммы? Алай тупас та кыланмыйм шикелле, хәтер калырдай усаллык та эшләмәдем кебек. Безнең эштә усалланырлык нәрсә дә юк. Бөтенебез өч бөртек кеше. Эш зур түгел, катлаулы түгел. Бер-береңне бер сүздән аңлыйсың. Көн дә бер үк төрле дип әйтерлек нәрсә башкарасың.

Гомумән, Зөһрәгә минем бер генә мәртәбә дә бәйләнгәнем юк. Мин кеше үзенә тиешлесен үзе аңлап эшләргә тиеш дип исәплим. Зөһрә шулай эшли дә. Аның бөтен җире ялт итеп тора. Идәндә беркайчан тузан, пычрак булмый, тәрәзә пәрдәләре, халатлар, сөлгеләр, җәймәләр беркайчан да керле булмый. Үз эшен ул бернинди авырлыксыз башкара. Шулай булгач, аңа ничек бәйләнеп торасың? Аннары, ул үзе дә миңа беркайчан да каршы сүз әйтми.

Шулай да ул үзен әллә ничек тота. Әйтерсең, монда ул мөдир дә, мин аңа буйсынган кеше. Тик ул моны әйтергә генә кыймый сыман. Башта ук ул үзен шулай тотты. Хәзер аның бу сәер кыланышы көчәйгәннән-көчәя бара. Элегрәк ул ике сүзнең берендә: Зина апа шулай итә торган иде дип, миңа үзенчә киңәшләр биргәләде, мине үзенчә тәнкыйтьләп алгалады. Аның киңәшләре еш кына урынсыз була иде,

[1] Дәвамы. Башы 10 санда.

шулай да мин ачуланмадым, берәр файдалы сүз ишетермен бәлки дип, еш кына аның сүзләренә колак салгаладым.

Хәзер ул әнә алай да сөйләнми. Минем белән бөтенләй диярлек сөйләшми. Сораган нәрсәгә бер-ике сүз белән генә җавап бирә дә тынып кала. Кайчагында, матур иреннәрен кысып: синең ишеләрне генә күргәнем бар инде! дигән кебек, җилләнеп минем яннан узып китә.

Аннары, элегрәк ул кичләрен безнең белән утыра, чигү чигә, ләчтит сата иде. Хәзер инде эш сәгате беткәч, пунктта аны бер минут тотып булмый. Шундый төгәл — нәкъ вакытында килә, нәкъ вакытында кайтып китә. Эш сәгате булмаганда берәр эш кушып кара — һич тыңлата алмассың! Турыдан-туры каршы да килми, берәр төрле сәбәп кенә таба: шулай, ди, болай, ди... Ни әйтсә дә әйтә, барыбер үзенекен итә.

Минем өчен бу чүп өстенә чүмәлә булды. Димәк, мине яратмый. Шулай да, ник мине генә яратмыйлар икән болар? Барысы да... Юан булган өчен генәме, әллә холкым өчен дәме? Ниндирәк холыклы икән соң мин? Нинди генә булмасын, мин бит барыбер усал түгел, мәкерле, эчкерле түгел. Мин бик йомшак бугай, тиз ышанучан, авырлыклар алдында тиз бөгелеп төшүчән бугай. Ләкин мин әле барыбер үз дигәнемне итәрмен! Мин әле барыбер үземне яраттырырмын! Институтка керсәм, чын врач булып чыксам, минем алда әле Зөһрә ишеләр биеп кенә торырлар.

Мин шулайрак фикер йөрттем. Мин көлмәс, елмаймас булдым. Хәтта Таня белән дә элеккечә иркенләп сөйләшми башладым. Мин үземне ниндидер кысынкылыкта, ниндидер чик эчендә итеп сиздем. Әгәр дә мәгәр шул чикне үтеп чыктым исә, тагын берәрсенең хәтерен калдырырмын, ачуын китерермен шикелле тоелды.

Озакламый минем тормышта тагын да күңелсезрәк хәлләр килеп чыкты.

## II

Бер көнне кич, гадәттәгечә, бакчыта моңаеп утырам — капка ачылган тавыш ишетелде. Мин дерт итеп киттем. Кемдер килә. Кем икән? Равилме, Тимерҗанмы?

Таня белән киного барган теге кичтән соң Равил тагын бер мәртәбә килде. Безнең белән юк-бар лыгырдап утырды. Ул көнне алар беркая бармадылар. Таняны ул бары татарча өйрәтте. Бәлки, тагын улдыр?

Әйе, ул. Мине күргәч тә елмаеп җибәрде, кычкырып сәлам бирде, үзенчә шаяртып алган булды.

— Бакалар бүген исерешеп беткәннәр, ахрысы — акыралар да бакыралар, — диде.

Ул инде минем бака тавышы тыңларга яратуымны белә. Үзенчә шуңа ишарәли.

— Шаулама әле, — дигән булам мин, кулымны селтәп.

Равил шаркылдап көләргә тотынды.

— Бака тавышын бик яхшы аңлыйсың, әллә үзең дә бака нәселеннән микән? — диде.

Безнең якта юан кешене «бака» дип үртиләр. Равил шулай күзгә карап «бака» дигәч, бик-бик кыен булып китте. Шулай да берни сиздермәдем, эчкә йоттым. Җитмәсә, үземне үзем тәнкыйтьләп алдым.

— Шулай шул, Равил, бака нәселеннән мин, — дигән булдым.

— Сиңа колхоз эшенә чыгарга кирәк, апасы, — ди Равил, киңәш итеп. — Синең эшең җиңел. Көч чыгарып эшли торган түгел. Кара әнә, авылда берәр юан кеше бармы? Барысы да чыра кебек, ха-ха-ха!

«Чынлап та, мин бит бер дә авыр эш эшләмим», дип уйлап алдым мин. Дөрес, мин һәр көнне гимнастика ясыйм. Ләкин нәрсә ул гимнастика? Әти әйтмешли, үлмәс җанга бер сәбәп. Мин аның берниндн

файдасын күрмим. Ягъни ябыгу буенча. Тукта әле, ял көннәрендә Янавылга кайтмаска, колхоз эшенә чыгарга кирәк. Аннары минә бу өелеп яткан утынны да кисәсе бар. Кем киссен аны? Зөһрә барыбер үзе генә кисеп бетерә алмаячак. Иртәдән тотынырга кирәк.

Равил минем каршыда туктады да папирос көйрәтеп җибәрде. Берике суыргач, ишеккә ымлады, тавышын әкренәйтә төшеп:

— Марҗа кызы өйдәме? — диде.

— Өйдә, — дидем мин. — Ул сине көтте. Укытучы шулай соңлап йөрми инде.

— Укытучы шулайдыр да, мин бит профессор! — диде Равил.

Күнеле күтәрелеп ул көләргә тотынды.

— Тизрәк өйрәт, — дидем мин. — Син өйрәткәнне ул ныграк исендә калдыра.

— Үрәтәм мин аны, апасы, үрәтәм! — диде Равил.

Сизелер-сизелмәс кенә аксаклап, кызулап ул өйгә кереп китте. Баскычта мин үзем генә торып калдым. Утырам юк-бар хыялга бирелеп. Искәрмәстән тагын капка шыгырдап куйды. Мин тынып калдым. Сагаеп бер йодрыкка йомарланып калдым. Монысы кем икән?

Тимерҗан! Кепкасын кырын салган. Нәкъ шәһәрдәгечә. Каян өйрәнгән ул аңа? Уфада өйрәнеп кайтты микәнни? Кыска җиңле ак ефәк күлмәк кигән. Кара чалбар. Монысы әле авылча — киң балаклы. Күкрәге киң, күлбашлары сөякчел. Гәүдәсе төз, матур. Биле нечкә. Битемуены, беләкләре кояшта янган. Башы чак-чак кына түбән иелгән. Күзләре, кемнәндер качкан кебек, әледән-әле читкә карый.

Атлар-атламас кына килде дә, минем танкеткаларыма карап:

— Исәнмесез, Саҗидә, — диде.

Мин күлмәк итәген тартыбрак куйдым. Үз-үземне кочаклап утырган көе, чак-чак кына башны калкытып:

— Исәнмесез, — дидем.

Шулай дидек тә икебез дә сүзсез калдык.

## III

Тора торгач ул да, Равил кебек, папирос кабызып җибәрде.

— Тәмәке тарту өчен монда җайлырак, ахрысы? — дидем мин.

— Нәрсә, әллә ярамый? — диде Тимерҗан, папиросын кулына алып.

— Ярый. Сезнең үпкә бит, минеке түгел, — дигән булдым мин.

— Үпкә генә түгел, йөрәк тә минеке! — диде Тимерҗан.

— Башыгыз кемнеке соң? — дидем мин.

Күңелем күтәрелеп, кисәк кенә көлеп җибәрдем. Тимерҗан да көлеп куйды.

— Анысы да әлегә үземнеке, — диде.

Без шулай көлештек тә тынып калдык. Беравык утыргач, мин җитди генә сорап куйдым:

— Әниегезнең хәле ничек? — дидем.

— Йөри, сезнең дәва килеште, — диде Тимерҗан.

Тагын сүзсез калдык. Күреп торам: аның нидер әйтәсе килә, тик әйтә генә алмый. Як-ягына карана, папиросын чәйни, иңбашларын жыера.

— Таня өйдәме? — диде бу бераздан, сүз югында сүз булсын өчен генә.

— Ул кирәкмени? — дидем мин.

— Кирәкми дә... — диде бу, ы-мы итеп.

— Кирәк булса, чакырып чыгарам.

— Болай гына...

— Алай икән.

Тагын сүз бетте.

— Нишләп алай ятим бала кебек басып торасың, утырып тор, — дигән булдым мин бераздан.

— Багана авып китәр дип куркам, — диде бу.

— Әллә үзең авып китүдән куркасыңмы соң?

— Үзең дә аварсың... син әнә нинди усал!

— Бик куркынычмени? — дидем мин, көлеп.

Миңа няреп бу да көлде. Икебезгә дә яңадан күңелле булып китте.

— Медиклар усал була икән дип ишеткәнием, шулай икән, — дигән булды бу.

— Минем бригадирлар турында ишеткәнем бар, — дидем мин.

— Бригадир ярдәмчеләре усал булмый, — диде бу юаш кына.

Шул чакны Равилнең сүзләрен искә төшердем.

— Тимержан, — дидем, — миңа да колхоз эшенә әйт әле?

— Пунктта әллә эш юк? — диде Тимержан, сүзне уенга борып. Күрәсең, мине шаярта дип уйлады.

— Пунктта да эш җитәрлек, — дидем мин. — Ял көнне... Минем дә эшләп карыйсым килә.

— Чынлап әйтәсеңме? — диде бу.

Шундук җанланып китте, сөялгән баганасыннан купты да бер-ике адым миңа таба атлап куйды.

— Хәзер кеше бик кирәк. Чынлап әйтсәң, мин сезнең өчегезгә дә эш табам.

— Әйе, өчебезгә дә!

— Элек сезнекеләр чыга торганые. Кеше тапмадык исә, шушында килә торганыек. Аннан соң — укытучыларга әйтәсең. Алайса, чынлап?

— Чынлап, чынлап! — дидем мин. — Берәр авыррак эшкә... көч чыгарып эшләрдәй эшкә...

«Кара, мин нинди таза!» дип шаяртмакчы булдым мин, шулай да тыелып калдым.

— Мин сезне, алайса, капчык ташырга куярмын, — диде Тимержан, көлеп.

— Була, теләсәң нинди эшкә куй.

— Юк, чынлапмы? — диде бу тагын да. — Амбар алдында таудай бодай өелеп ята. Кыза. Әйләндерергә, җилләтергә кеше кирәк.

— Бүген җомга, иртәгә шимбә, — дидем мин, көннәрне санап.

— Теләсәгез, үз эшегез беткәч, төштән соң да барырга була, — диде бригадир ярдәмчесе, әрсезләнеп.

— Төштән соң булмый. Авылларга чыгарга кирәк. Иртәгә Түбән Чатка барабыз.

— Ник?

Мин «ник» икәнлеген аңлатырга өлгерә алмый калдым. Шул чакны капкадан тагын кемнеңдер килеп кергәне күренде.

## IV

Зөһрә икән. Никтер җилләнеп килә. Җилләнеп кенә дә түгел, тузынып килә! Йөзе җимерелгән, кыска чәчләре тузгыган. Үзе әле генә мунча кереп чыккан шикелле. Кып-кызыл. Әллә чынлап та мунча кергән.

Нишдидер күңелсез сөйләшү буласын сизенеп, шып булдым. Пунктта эшләүче кешенең, үземә буйсынган кешенең шулай тилереп йөрүе өчен Тимержан алдында миңа уңайсыз булып китте.

— Ни булды, Зөһрә? — дидем, тыелып кына.

— Булмады, — диде бу. — Таня кирәк.

Шулай тупас кына җавап кайтарды да йөгереп баскычтан менде, җилләнеп, тузынып чоланга кереп китте. Тимержан да, мин дә сүзсез калдык. Зөһрә чын-чынлап минем котны алды. «Тагын нәрсә булган

инде моңа?» дип уйладым, тынычсызланып. Ник шулай тупас кылана ул? Ярамый болай, ярамый! Нygытып әйтергә кирәк. Кем мин аңа?!

Мин аның артыннан кермәкче булдым, кереп сораштырмакчы иисә, аңлашып булмаса, тиешенчә үзен кыздырып алмакчы булдым. Ләкин аның дәһшәтле кыяфәтен исемә төшердем дә тыелып калдым. Аннан соң, өйдә Равил бар бит! Чит кеше алдында аның тагын да тупасрак сөйләшүе мөмкин.

— Шундыйрак кеше инде ул Зөһрә, — дип куйды Тимерҗан, бер дә юктан көрсенеп.

Ул чакта мин аның бу сүзләрне ничек әйтүенә дә, кыяфәтенә дә игътибар итмәдем. Мин бары үз уйларым белән генә мавыктым. Соңгы көннәрдә Зөһрә белән икебезнең арада барлыкка килгән салкынлык тагын эчне тырнап куйды. «Ничек ярарга да белмәссең боларга!» дидем үз-үземә, ачынып.

Шул вакыт дымлы җил исеп куйды. Һавада инде баядан бирле яңгыр исе килә иде. Көнне караңгылатып җибәрде. Күршеләрнең биек тупыллары сызланып-сыкранып шауларга тотынды. Ашыгып астан гына нилдидер кошлар очты.

Мин аягүрә бастым. Түбә астынарак елыштым.

Без Тимерҗан белән сөйләшмәдек тә, аерылышып та китмәдек. Нидер көткән сыман, бер-беребезгә карашып тик тордык. Минем хәзер Зөһрә янына керәсем килмәде. Тимерҗанның да тиз генә кайтып китү исәбе юк иде, ахрысы.

Шапылдап такта түбәгә берәм-сәрәм яңгыр тамчылары килеп төште.

— Бер дә вакытсыз булды әле бу, — диде Тимерҗан. — Эх, харап итә инде, чылата инде!

— Нәрсәне чылата? — дидем мин.

— Нәрсәне! Ашлыкны. Ындыр табагы тулы бодай!

— Өстен ябып куеп булмыйммени? — дидем мин.

— Кая инде хәзер! — диде Тимерҗан, кулын селтәп.

— Алайса, йөгер тизрәк! — дидем мин, ашыктырып.

Еракта агач яфракларына, өй түбәләренә, киртә-коймаларга каты бәреп, чыбыклап явып килгән яңгыр тавышы ишетелде.

— Юк, булмады инде! — диде Тимерҗан. — Кешеләр бәр да соң анда. Япсалар ярый да...

— Син үзең бар! Йөгер тизрәк! — дидем мин, кыстап. — Өлгерерсең әле, йөгер!

Күреп торам, аның үзенең дә йөгерәсе килә. Тик әйтәсе ниндидер сүзе булгангамы, ничектер тәвәккәлли алмый тора.

— Алайса, кер, чыланасың бит, — дидем мин.

— Юк! — диде Тимерҗан кинәт. — Киттем! Соңыннан... Хуш. Сау бул!

Шулай диде дә капкага йөгерде. Менә шыгырдап капка ачылды, шапылдап ябылды. Шул ук вакытта диярлек бөтен дөньяны томалап яңгыр да килеп житте.

Тимерҗан китеп бер-ике минут узмады, ишекләрне шап-шоп бәреп Зөһрә килеп чыкты. Эндәшмәде-нитмәде, биек үкчәле туфлиләре белән такта басмаларны дөбердәтеп җиргә төште. Төште дә, коя башлаган яңгырга да карамастан, капкага ташланды.

«Аңламассың бу халыкны!» дидем, аптырап. Чолан ишеген бикләдем дә өйгә кердем.

## V

Равил әле китмәгән. Таня белән икесе, көлешеп-шаулашып, ярым русча-украинча, ярым татарча нидер гәпләшеп утыралар.

— Яңгыр ява, — дидем мин.

— Нарся? — диде Таня.

— Яңгыр йа-ва, — диде Равил, минем сүзләрне кабатлап. Аннары

шул ук сүзләрне русчага тәрҗемә итте: — Дож... дож... Ничек әле, апасы?

— Идет, — дидем мин.

— Дож идйот! — диде Равил, сөенеп. — Яле, кабатла татарча: янгыр йа-ва...

— Ян-гр я-ва, — диде Таня, аның артыннан кабатлап.

Үзе никтер күләргә кереште.

— Зөһрә ник килгән? — дидем мин Таняга, русчалап.

— Татарча скажи! — диде Таня, үзенең татарча бик яхшы белгәнлеген күрсәтмәкче булып.

— Зөһ-рә ник кил-гән? — диде Равил, минем сорауны кабатлап.

— Зохра... как?.. зачем?.. приходила? — диде Таня, аңламыйча.

Равил аңа төшендереп бирде.

— Нинди Зөһрә? — диде Таня, миңа карап, гаҗәпләнеп. — Кайчан килде?

— Әле генә.

— Безнең янга беркем кермәде, — диде Таня.

— Кермәде?

— Юк, кермәде, — диде Равил дә.

— Ник кермәсен? Синдә йомышым бар диде ич!

— Кермәде, апасы, кермәде. Ни пришол! — диде Равил, кычкырып.

— Конечно, «ни пришол», — диде Таня, көлә-көлә.

Мин уйга калдым. Димәк, ул мине алдаган! Холыксызлыгы өстенә, аның әле алдаша торган гадәте дә бар икән! Ник килгән соң ул шулай да? Нинди йомыш белән? Теге якта булды микәнни?

Мин кабул итү бүлмәсенә чыктым. Бүлмәдәге әйберләрне караштырдым. Бөтен нәрсә үз урынында. Әллә соң көндез онытып калдырган берәр нәрсәсен алырга килгәнме? Алай дисәң, чыгып киткәндә кулында бер нәрсә дә юк иде шикелле.

Мин янадан үзебезнең бүлмәгә чыктым. Тәрәзә каршысына килдем дә пыяла аша урамга, коеп яуган яңгырга карап тора башладым. Минем әллә ничек эчем пошты. Шулай да көндәлдә эч пошуга караганда да зуррак бер хис бар, җылылык, өмет-куаныч бар.

Ә бит ул килде! Димәк, ярата! Чынлап та... ярата микәнни?..

Минем йөрәк дәртләнеп, ашкынып типте. Соломон Моисеевич онытылды. Ни әйтсәң дә, ул ерак. Күктәге йолдызлар кебек ерак. Аның турында бары хыялланырга гына була. Тимерҗан турында хыялланырга да, ныклап торып уйланырга да була. Ул монда гына, якында гына. Аны күрәсең, тоясың. Аның белән сөйләшәсең. Ул йолдыз да түгел, ай да түгел. Ул кеше. Күптән инде мин теләгән, мин күңелемдә йөрткән кеше...

Чынлап та, миңа әллә нәрсә булды. Әллә ничек җиңеләеп калдым дип әйтимме... кинәт кенә дөнья үзгәрде дип әйтимме... Шундый якты, җиңел, рәхәт!

Шул ук вакытта нидер куркытып, котны алып тора. Нәрсә соң әле бу? Тукта, нәрсә булды әле миңа?

Мин, әйтерсең, бар көчемә чабып барганда искәрмәстән абынып киттем. Абынмадым да, маңгаем белән ташка, баганага... стенага бәрелдем. Күземнән утлар күренде. Йөрәгем жу итеп китте. Мин Зөһрәнең ни өчен тузынып йөрүен аңлап алдым! Ни өчен моңарчы миңа карата салкын булуын, ни өчен мине яратмавын, күралмавын аңлап алдым!

## VI

Иртән безне Зөһрәнең җиңгәсе Рафика апа килеп уятты. Аның безгә элек тә килгәне бар. Ул әле күптән түгел генә баладан котылды. Өйдә бала карап ята. Ул башкорт. Безнең якта әйтелгәнчә, чи башкорт,

ягъни чын башкорт. Зөһрәнең абыйсы Хисам абый аны былтыр каяндыр Учалы ягыннан алып кайткан.

Рафика апа бик матур. Минем аңа караган саен карыйсым килә. Кайчагында мин аңа гашыйк булам шикелле. Чынлап. Анда бернинди усаллык, бернинди эчкерлелек юк кебек. Ул юаш, тыйнак. Шулай да ул җебегән түгел. Ул теләсә кемне үзенә карата ала торган тыйнаклык белән тыйнак. Ул, чын башкортларның күпчелеге төсле, кап-кара. Чәчләре кара, кашлары кара. Кайсыдыр ягы белән ул Зөһрәгә дә охшаган сыман. Ләкин Зөһрә тере, елгыр, житез. Рафика апа — салмак, йомшак һәм бераз гына моңсу-боек. Бәлки, ул тумыштан шулай моңсудыр, бәлки, туган якларыннан читтә-ерakta яшәү аны шундый иткәндер — әйтеп булмый. Ни генә булмасын, моңсулык аңа бик килешеп тора. Ә хәзер ул бераз гына сулыга, ябыга төшкән.

Ишек төбендә Рафика апаны күргәч, мин елмаеп җибәрдем, ишекне ныграк ачтым да:

— Исәнмесез, Рафика апа, керегез, — дидем.

— Исәнме, Сажидә, — диде Рафика апа. — Зөһрә урынына килдем әле. Нәмә әйтерһең тагын.

Зөһрә исемен ишетү белән, чыраем бозылып китте. Күз алдына кичәге кыланышы килеп басты.

— Зөһрәгә ни булган? — дидем, сагаеп.

— Авырып тора. Соланды юасы бар тигәйне ул.

«Авырган, пычагым!» дидем үз алдыма. Шулай да Рафикаападан сораган булдым:

— Нәрсә булган? Кай җире авырта? — дидем.

— Кисә ямгырга эләккән. Башы авырта, — диде Рафика апа.

— Алай икән, — дидем мин.

— Һин борсылма. Сажидә, — диде Рафика апа, юатып. — Бетәр әле. Иртәгә ял. Әйт тә нәмә кәрәген, үз эшендә бул.

— Ярар, алайса, Рафика апа, — дидем мин. — Мичкә ягып, шприцларны кайнатырбыз да, шуның белән эш бетәр. Идәнне юмасаң да ярар.

Мин аңа кайдан нәрсә алырга, шприцларны ничегрәк кайнатырга кирәклеген әйттем дә, сабын, сөлге алып, тышка юынырга чыктым.

«Борчылам! Зөһрә өчен борчылам!» дип уйладым, күңелемнән Рафика апа белән бәхәсләшеп. Бөтенләй килмәсә дә исем китми. Чыннан да, килмәсә нинди шәп булыр иде! Аның урынына Рафика апа калса... Тимерҗан бит аның янына килмәгән, минем янга килгән! Үзе килгән. Мин гаепле түгел. Зөһрә теләсә нишләсен. Минем анда эшем юк. Теләсә нишләсен...

Ә тышта шундый күңелле! Җир әле кичәге яңгырдан соң кибеп тә өлгермәгән. Үләннәр юеш, сукмак юеш. Киртәләр, өй түбәләре юеш. Шатланып кояш елмая, шатланып кошлар сайрый. Чиләкләрен сайратып кемдер тыкрыктан аяк очка суга төшеп бара. Минем турыдан узганда киртә аша миңа карап алды. Ә мин, авыз читләрен акка буяп, тырышып-тырышып щетка белән теш чистартам.

Тимерҗан кичәгенәк амбарга барып җитә алды микән? Юктыр. Кая ул анда барып җиту! Ашлыклары чыланды микән? Бит без иртәгә эшкә чыгачакбыз. Чыланса яхшы булыр иде. Мин бер минут туктамый эшләр идем. Тимерҗан шунда булыр. Минем ничек эшләгәнне күреп, карап торыр. Ул болай да миңа сокланып карый. Чынлап. Валлаһи менә! Кояштыр!

Тукталс, алайса, мин Зөһрәдән дә матуррак булам түгелме соң? Булмас ла! Ник булмас икән соң? Төскә-биткә котсыз түгелмен. Түгәрәк бит, кара кус чәч. Минем күзләр матур, тешләр, иреннәр... Үзем дә беләм, әйткәннәре дә бар. Тик менә шул әлеге дә баягы... юанлык кына...

Һы... бәлки, ул мине яратмый дадыр. Әйе шул... Зөһрәнең көнләшеп йөрүе генә аның мине яратуы була алмый бит әле. Да-а... Менә сина кирәк булса! Мин тиле тагын әллә нәрсәләр уйлаган булам.

## VII

Таня иртән беркая бармады. Икәүләп авыруларны кабул итеп бетердек тә көндезгегә кукәй тәбәсе куырып ашадык. Аннары юлга әзерләнә башладык: кечкенә сумкаларга кирәкле даруларны, коралларны, халатларны салдык. Тик менә бинтны гына бик аз алырга туры килде.

Бинт дигәннән, бинт бик күп бетә. Һәрбер яраны медицина кушканча бәйли башласаң, безнең айлык запас бер атнага да житмәс. Ә җәй көне яралану аеруча күп була.

Юл уңаенда без авыл Советына да кереп чыкмакчы булдык. Акча сорап карарга кирәк. Бинтсыз бернәрсә эшләп булмаячак.

Авыл Советында көндез кеше булмый. Бүген дә шулай. Председатель өйдә юк, каядыр киткән. Үз бүлмәсендә секретарь гына утыра. Кайчан кермә, һәрвакыт бер урында. Нидер язган була, сызган була. Язмаса-сызмаса, газета караштырган була. Дөресен әйткәндә, мин аны яратып житкермим. Алай гына да түгел, бөтенләй яратмыйм! Шулай ук ул да мине яратмый, ахрысы. Ул надан. Нибары жиде класс бетергән, шулай да үзен белдекле итеп, зур кеше итеп тотарга тырыша. Бер кереп утырган да, утыра да утыра. Эшнең жаена төшенеп алган — берничек кузгата алмассың! Күрәсең, шуна күрә дә өйләнә алмый торгандыр, бичара. Урынын ташлап китәргә куркадыр. Кызлар артыннан йөрергә вакыты юктыр. Шулай да аны Зөһрәнең апасы Фәгыйлә апа белән йөри дип сөйлиләр.

Фәгыйлә апа Зөһрәдән дә матуррак. Исең китәр, аларда гына булыр икән бар матурлар! Фәгыйлә апа сыер фермасында эшли. Бозау карый. Алдынгы. Иң алдынгы. Аны инде мин монда эшли башлаганнан бирле генә дә ике мәртәбә район газетасында мактап яздылар. Гажәп, чынлап та йөриләр микәнни? Никтер ышанасы килми.

Без Таня белән килеп кергәч, секретарь өстәленнән башын калкытты да коры гына сәлам алды. Нурсыз күзләрен чекрәйтеп, безгә төбәлеп калды.

— Вәзир абый, бинт бетте, — дидем мин, үпкәләгән сыман.

— Бинт бетте? — диде секретарь. — Бетсә ни, миндә бинт фабригы юк ла!

И, ачуым да килә шулай кыланып сөйләшкән кешегә!

— Акча кирәк бинт алырга, — дидем мин, катырак булырга тырышып.

— Квартал бетми торып, кәпикә дә юк.

— Нишләргә соң, алайса? Бинт бетте бит!

— Саклабрак тотыгыз.

— Саклап тотыйм дисәң дә булмый.

— Юк. Смитада күпме каралган, барысын да алгансыз.

— Сметада минем эшем юк, — дидем мин.

— Сезнең эшегез булмаса, минем эшем бар. Смита минем өчен закун, — диде секретарь коры гына.

— Миңа бинт кирәк — теләсә каян табыгыз, — дидем мин, кирелэнеп. — Инфекция булса, үзегез жавап бирерсез.

— Карале, сеңлекәем, — диде секретарь тыныч кына. Аның бу тынычлыгында миңа карата үтергеч өстенлек сизелде. — Нәрсә, син монда миңа акыл өйрәтергә килдеңмени?

— Теләсәгез нишләгез — инфекция булса, үзегез жавап бирерсез! — дидем мин тагын да.

Шулай дидем дә кызып-кайнарланып ишеккә ташландым. Ләкин болай гына да күңел басылмады. Кырт кына борылып янадан өстәл янына килдем, янадан үземнекен тукырга тотындым: медицина бу, дидем; монда кешенең язмышы хәл ителә, дидем; берничә метр чүпрәк аркасында кешеләр гомергә гарип калырга, уләргә мөмкин, дидем. Секретарь эндәшмәде, ике кулын иягенә таянып, әллә кем булып, сүзсез генә утыруында булды.

— Әйдә инде киттек, — диде Таня, күлмәк итәгеннән тартып.

Ул мине көчләп диярлек ишеккә таба алып китте.

## VIII

— Туктагыз әле! — диде кинәт секретарь, нидер исенә төшеп.

Без туктадык, кире килдек.

— Сез нәрсә анда пунктта җегетләр җыеп ятасыз? — диде бу, нурсыз күзләрен миңа төбәп.

— Нинди егетләр? — дидем мин, берни аңламыйча.

— Нинди җегетләр икәнлеген үзегез беләсездер инде, — диде секретарь, мыскыллы көлемсерәп. — Соңгысы булсын. Беренчелеккә гафу итәм.

Ул шулай диде: «Беренчелеккә гафу итәм», диде. Шундый гарьләндем, шундый хурландым, кинәт бөтен эчем-тышым ургып кайный башлады.

— Кем әйтте, кем әйтте? — дидем.

— Сүз иясе белән йөрми, — диде секретарь.

— Дөрес түгел! — дип кычкырдым мин әллә нинди череллек тавыш белән.

Борылдым да, ярсуымны баса алмыйча, Таняга тәрҗемә итеп бирдем. Таняның да йөзе үзгәреп китте.

— Пунктта кеше җыеп ятарга рөхсәт ителми, — диде секретарь русчалап. — Пункт — медицина учреждениесе. Җегетләр белән йөрисегез килә икән, клубка барыгыз. Аулагөй ясап ятарга анда!

— Кем әйтте, кем әйтте?! — димен мин, бер үк сүзне кабатлап.

— Сез нәрсә, сахрада яшибез дип белдегезме әллә? — диде секретарь. — Кем әйтсә дә барыбер түгелмени? Сезнең тирә-ягыгызда кешеләр. Күршедә дә кешеләр, стена аша да кешеләр...

— Ә-ә! — дидем мин, искәреп. — Стена ашамы? Күршеләрме? Ярый, сорыйбыз хәзер!

— Сорыйсы юк, — диде секретарь. — Әйттем бит: беренчелеккә гафу итәм, икенче кабатланса...

— Юк дип әйттем бит, юк! — дип кычкырам мин, еларга җитешеп.

— Нәрсә, әллә безгә кеше дә килмәсме?! — диде Таня да, сүзгә катышып. — Без төрмәдә түгел.

— Пунктта не положено. Ярамагач — ярамый. Пункт — совет учреждениесе...

— Юк дип әйттем бит, юк! — дип кычкырам мин, борып куелган машина кебек.

«Җегетләр җыеп яту» дигәнне мин бөтенләй начар, әдәпсез мәгънәдә аңлыйм. Равилнең, Тимерҗанның килүен исемә дә кертеп чыгармыйм. Шуңа күрә, миңа монда коточкыч гаделсезлек, мәкер һәм яла бар кебек тоела. Секретарьга минем нәкъ менә шуны аңлатасым килә. Ләкин ул мине тыңламый да. Күрәсең, аның тыңлыйсы да, аңлыйсы да килми. Аның үз сүзе сүз. Ул кире. Кире генә дә түгел, ул агач, таш! Ана әйтсәң ни дә, әйтмәсәң ни. Безне егетләр җыеп ята дип әйткән икән, аның өчен ул закон, смета кебек үк закон.

Мин кычкырындым-кычкырындым да, тыела алмыйча, елап җибәрдем. Ике күздән кайнар яшь атылып чыкты. Борылдым да, борын

суын тарта-тарта, йөгердем урамга. Елый-елый пунктка кайттым. Күнелемнән күршеләрнең тетмәсен тетмәкче булам. Капканы ачу белән, иң әүвәл тәрәзәләренә карадым, аннары сыер абзарлары ягына карадым. Бәләкәй, йомры хатын абзар тирәсендә печән өеп ята. Туп-туры шунда киттем.

Өсте-башы начар гына. Күлмәге арка турысыннан сизрәп, тишелеп чыккан. Башына бәйләгән яулыгы тузган. Бөтен киемендә, бөтен кыяфәтендә ярлылык, мескенлек күзгә ташланып тора. Йөзе ябык, күзләре генә утырып калган. Каршысына барып бастым да, күз яшьләремне йота-йота:

— Нәрсә дигән сүз бу, Заһидә апа?! — дидем. — Бездә ни эшегез бар сезнең? Минем нинди начарлыгым тигәне бар сезгә? Йомшак дигәч тә, басмакчы буласызмы...

Күрше хатыны эшеннән туктады, алъяпкыч итәге белән тирләгән битен сөртте, берни аңлатмый торган күз карашы белән миңа күтәрелеп карады.

— Туктале, тукта, Сажидә, — диде, каушап. — Аңлатып сөйлә: ник алай бер дә юктан тузынасың?

— Тузынмассың! Бер дә аңлатасы юк! Вәзиргә барып безне әләкләп йөрмәсәгез, эчегез күбәме әллә?! Аулагөй ясап яталар дип... Кайчан күрдегез бездә аулагөй?

— Берни әйткәнем юк, Сажидә! — диде күрше хатыны.

— Булмәдән чыгыгыз дигәнмен икән дә, шул ошамаган, — димен мин, аны тыңламыйча. — Әллә мин әйткәнме аны? Секретарь куша ич! Миңа димәгәе!..

— Бөтенесе дә шул корыган бугаз аркасында! — диде күрше хатыны, борынын тартып.

Мин тагын нидер такылдарга тотындым. Ләкин Таня шунда кулдан тотып алды.

— Җитәр! Киттек, соңга калабыз, — диде.

Мин үзебезнең кая барырга җыенганлыгыбызны исемә төшергәндәй иттем, Таняга буйсынып, каядыр китеп бардым.

Түбән Чатка җәяү бардык. Дүрт чакрым араны күз ачып йомганчы үттек.

## IX

Түбән Чатта без көтү кайтканчы булдык. Авылны бөтенләй йөреп чыга алмадык — иллеләп йортка гына сугылдык та кайту ягына борылдык.

Мәсәгуткә караңгы төшкәндә кайтып кердек. Эттәй арып-алҗып кайттык. Шыгырдатып капканы ачтык, ишекне ачтык та, тып-тын чолаңда тавыш ясап, өйгә кердек.

Бүлмәләрдә шомлы тынлык. Тынлык кына да түгел, тарлык, кысынкылык. Давыл инде басылган, тик шулай да күңел әле тулысынча тынычланып җитмәгән. Өйдә дә торасы килми, тышка да чыгасы килми.

Бик нык ашыйсы килә. Ашарга әзерләргә кирәк. Ашыкмыйча гына, теләмичә генә Таня белән икәүләп плитә янында кайнаша башладык.

Шул чакны әкрен генә теге якның ишеге ачылды. Серле генә, мыштым гына атлап, кемдер безгә таба килә. Икебез дә тынып калдык. Тыңлап торабыз. Мин инде андагыларның аяк тавышларын таныйм. Безгә керүче кеше укытучы агай булырга тиеш. Кәрим абый.

Менә ул ишеккә килде, ишек шакыды.

— Керергә буламы? — диде.

— Керегез, — дидем мин.

Керде дә, анда-монда сөрлегеп, түргәрәк узды. Өстәл янына ук барып җитмәде, туктап калды. Кулында тәмәке. Үзе белмәгәч, мин инде:

монда тартырга ярамый дип тормадым. Тешне кысып, аның сүз башлавын көтәм. «Мине сүгәр өчен килгәндер инде», дип уйлыйм.

— Сәңнекәш, — диде бу, миңа эндәшеп. Карлыккан әчке бер тавыш белән, әрнеп, газапланып әйтте. — Заһидә апаңны юкка рәнжеткәнсең, — диде әкрен генә, серле бер тантана белән. — Юкка, сеңнем. Без андый кеше түгел. Син алай янгышма. Вәзирне мин синнән күбрәк беләм. И әйтәм, син әле яшь. Кеше сүзе буенча харап була күрмә. Дөнья иркен — сиңа да җитәр, безгә дә.

— Сез миңа шуны әйтергә кердегезме? — дидем мин, кызарынып. — Рәхмәт киңәшегезгә. Минем инде ишеткәнем бар.

Шулай дидем дә, эре генә атлап, өстәл янына килдем, өстәлдәге китаплар арасыннан нәрсәдер эзләгән, актарган булдым. Күршенең болай да ябык, нурсыз йөзе тагын да агарынып китте. Куллары калтырана башлады.

— Сеңнем, — диде бу. — Рәнжемә. Нахакка... Без андый кеше түгел. Син безгә кысык итмәйсең, без — сиңа... Заһидә апаң белән икенче тавышланасы булма! Ишетсен колагың! Әйтәсе сүзең булса, үземә әйт. Аның нирбы начар... башы... йөрәге...

Алпан-тилпән атлап, калтыранып бу урыныннан кузгалып китте.

— Куркытмагыз, — дидем мин.

— Юк, куркытмыйм, — диде агай. — Әнә... аяктан җыгылды... ята. Өч бала белән торып каласым килми минем.

— Егылды?! — дидем мин, котым алынып.

— Ышанмасаң, кереп кара. Авырсынсаң, иртәгә Нөгәмәштән бырач чакыртам.

Йөрәккә ут салып, шом салып ул чыгып китте. Бүлмәдә әчкелтем тәмәке төтене исе торып калды. Чоланда агаем өстерәлеп атлаган аяк тавышы, тишек комганнан идәндәге чиләккә тамган тамчы тавышы ишетелеп торды.

— Нәрсә булган? — диде Таня, каушап.

Сүзнең нәрсә турында барганлыгын чамаласа да, ул, күрәсең, ныгытып аңлап җитмәгән иде.

— Егылган... күрше хатыны аяктан егылган! — дидем мин, пышылдап.

## X

Кинәт кенә исемә-акылыма килдем дә кабул итү бүлмәсенә йөгереп чыктым. Әлбәттә, керергә кирәк! Нинди авырсыну ди ул! Нинди генә шартларда булсам да, мин — фельдшер, мин — медик. Аяктан егылган. Нервысы начар, башы... йөрәге... Аңа беренче ярдәм кирәк. Күршендәге авыруны кереп карамау ул үзе бер җинаять булыр иде!

Минем арттан шундук Таня килеп керде.

— Сиңа ярамый, Сажидә! — диде, юлыма аркылы төшеп.

— Ник? Дөрес! Бар, син кер. Бар, тизрәк!

Таня тиз генә халатын киде, фонендоскоп алды, кан басымын үлчи торган аппарат алды. Ашыгып кереп тә китте. Мин баскан урынымда тордым да калдым.

Шулай торганда тәрәзәгә күзем төште. Карасам, ак ефәк күлмәген киеп, ашыга-ашыга безгә Тимерҗан килә!

Күрдем дә моны, тиле кебек ярсып, ишеккә ташландым.

Тагын! Кара, нинди шәп егет! Алар аркасында сүз ишетү җитмәгән... тагын килә! Кирәге юк берсенең дә! Мин егетләр белән очрашмый да тора беләм. Аулак өй түгел монда. Йөрсеннәр әнә үзләренең клубларына.

Секунд эчендә күңелдән шундый усал уйлар үтте. Йөгереп чыгып чолан ишеген ачып җибәрдем дә бастым тегенең каршысына.

— Исәнме, Сажидә! — диде бу, авызын ерып.
— Исән булмасам, мин үзем фельдшер, — дидем, коры гына.
— Сажидә!
— Нәрсә? Ник килдегез монда?
— Карале, туктале...

Тавышы да үзгәрде моның, йөзе дә үзгәрде. Беләкләремне күкрәк турысында кушырдым да, ниндидер кинодагы уңай геройны хәтерләткән бер кыяфәттә, башымны горур гына югары күтәреп:

— Безнең пунктка икенче аяк басасы булмагыз! — дидем. — Бетмәгән әнә... клублар... аулак өйләр... Равилгә дә әйтегез, эзе булмасын.

Шәп егетнең борын төбендә генә ишекне шап иттереп яптым да кердем дә киттем. Юк, кереп китмәдем, ишекнең киләсен эләргә азаплана башладым. Нишләптер кул калтырана. Һич кенә дә элә алмыйм. Шул ук вакытта аяк буыннары да хәлсезләнеп китте. Каяндыр курку, шүрләү калкып чыкты.

Киләне каптырып тормадым, өйгә кереп киттем. Аяктан егылмас өчен тәрәзә янагына барып сөялдем. Берни тоймыйм, берни сизмим. Үйламыйм да, кайгырмыйм да. Бары тик хәлсезлек кенә җанга тия. Аннары, иннтер калтырата-дерелдәтә.

Ара-тирә үзем тәрәзәгә карап алам. Китәрме? Киттеме? Ничек китте?

Менә капкадан чыкты. Башын иеп, әкрен генә урам буйлап китеп барды. Туктады, уйга калды. Тагын кузгалды, тагын туктады. Аның шулай китеп баруын күргәч, үземнең тагын бер кирәкмәгән дуамаллык эшләгәнлегемне аңлагандай булдым. Бөтен тәнемне, үткер скальпель булып, үкенү тойгысы ярып үтте.

Кисәк кенә бу кире борылды. Ниндидер кискен, ныклы бер карарга килеп, янадан безнең капкага килә башлады. Ни кирәк аңа? Ни кирәк? Кире килә! Җибәрмәскә кирәк! Керсен! Кеше сүзеннән куркып монда... Кемдә кемнең эше бар?! Миндә беркемнең дә эше юк!

Күп тә үтмәде, бик каты ишек шакыган тавыш ишетелде. Мин янадан чоланга чыктым.

— Кем бар? Нәрсә кирәк? — дидем ишек аша, дер-дер калтыранып.
— Мин бу, мин — бригадир ярдәмчесе! — дип кычкыра бу тиле кеше сыман. — Иртәгә амбарга барасызмы... барасызмы? Ашлык яна, кеше юк. Барасызмы? Икенче килмәм, курыкма! Әйт, барасызмы? Барыгыз... өчәүләп!

Бөтенләй чит кеше булып, бригадир булып кычкыра. Кычкырды-кычкырды да йөгереп баскычтан төште, йөгереп ишек алдыннан чыгып китте.

Ул кычкырганда мин тагын киләгә килеп тотындым, ишекне ачаргамы, бикләргәме азапланам — үзем дә аңламыйм. Килә нишләптер күтәрелмәде. Ишек ачылмады. Ул баскычтан төшеп киткәч кенә мин ишекнең бикләнмәгәнен аңлап алдым. Ишекне тартеп җибәрдем дә шунда бусагага утырдым. Утырмадым да. Егылып төштем. Кинәт җылыйсым килде. Мыштым гына үксергә тотындым.

## XI

Бер заман артымда Таня басып торганлыгын шәйләп алдым.

— Ни булды тагын? — ди бу.
— Булмады, — димен. — Айлы төн, матур...
— Нинди айлы төн?! — ди Таня, исе китеп. — Әйдә, керәбез. Тилереп беттегез инде барыгыз да.
— Хәле ничек? — димен, күршеләр ягын ымлап.

Ул миңа күрше хатын турында сөйләргә тотына. Фәлән төрле дару бармы, ди; тынычланса бетәр, ди; нервы, баш, йөрәк, ди... Без өйгә

керәбез, шкафны ачып, кирәкле даруларны алабыз да, Таня янадан теге якка кереп китә.

Мин үзебезнең якка чыгам. Чыксам, калай капкачын сикерткәләп, дөбер-шатыр чәйнек кайнап утыра.

Таня чыккач, сөйләшми генә чәй эчтек. Ашагач-эчкәч, күңел бераз тынычлангандай булды.

Исең китәр, ашказанының бернинди хисе юк! Аңа бары аш кына булсын, аның бары «буксәсе» генә тулсын. Кайчагында йөрәккә дә, нервыларга да ашказаны баш булып кала. Шундый гамьсез, пошмас ашказаны бөтенесен баса да куя. Нинди көчле ул ашказаны!

Чәй эчеп туйдым да көрсенеп куйдым. «Шул кирәк сиңа! — диде графинга сөяп куелган «Галия», утлы күмердәй күзләрен очкынландырып. — Җебегән кеше син, җебегән, булдыксыз. Сүзеңдә тора белмисең, антыңны бозасың, егетләр турында уйлыйсың. Уйлау гына түгел, очрашасың, сөйләшәсең! Физика, химия дәреслекләрен ай буена кулыңа да алып карамадың. Нинди кеше син? Әйт әле, нинди бәндә син?! Синең белән дуслашкан мин җүләр! Мин сөйләгән сүзләр барысы да бушка китте. Юкка төкрекләремне чәчеп мин сиңа: укырга, укырга! дип өндәгәнмен. Булмый синнән, берни булмый. Әнә тагын, ашады да иреннәрен ялмап куйды. Үзеннән үзе нинди канәгать! Утыра лабаса капчыктай булып. Гамеңдә дә юк».

Мин тагын көрсенеп куйдым. Үзем белән үртәшеп утырган «Галия»не графин янынннан алдым да йөзе белән өстәлгә каплап куйдым. Ләкин алай да күз алдымнан китмәде, мине һаман үчекләвендә булды. Алдым да, ачуланып, «Нервы авырулары» китабы эченә тыгып куйдым.

«Утырса әллә! — дидем, күренмәгән Галия белән бәхәсләшеп. — Бик исем киткән иде! Ашамыйча беркем тора алмый. Синнән куркып монда ач тормам. Барыбер файдасы тими. Баш кына әйләнә. Туберкулез аласым юк. Студент чакларда ач торган да житәр».

Шулай әрепләшеп утырганда күз алдына Уфа килә, мин кайчандыр кызыгып караган шат йөзле студентлар килә. Ә бит Галия бер-ике көннән студентка булачак! Нинди бәхетле ул! Нинди бәхетле!..

Аның сүзен тотканда, бөтенесен анынча эшләгәндә, мин дә аның белән бергә була ала идем бит! Ләкин булмады. Көч житмәде, тырышлык, чыдамлык житмәде. Нинди чыдамлык ди ул? Чыдам булган кеше секретарь белән тиргәшеп йөримени, авыру хатын белән әйтешәмени?! Әллә нинди кеше мин. Алама кеше. Нинди икәнлегемне үзем дә җүнләп аңламыйм.

Галия нинди соң? Галия ул кеше генә дә түгел, — фәрештә! Үзе бәләкәй генә, чандыр гына. Өрсәң жаны чыгарга тора, үзендә никадәр көч, никадәр энергия! Ул төннәр буе укып утыра ала. Тели икән, тәүлекләр буе черем дә итми. Имтиханнарга әзерләнгәндә ул атналар буе киногa бармый, мунчага бармый. Ашавын оныта, эчүен оныта, хәлсезләнеп аяктан егыла, шулай да кулыннан китабын төшерми. Аның белмәгәне юк. Китаптагыны ул биш бармагы кебек белә, кайсы биттә нинди хәрефнең кыек басылганына кадәр белә. Шуңа да ул отличница. Ул баштанаяк укучы. Ул — чын совет студенты.

## XII

— Нәрсә кайгыга баттың, әйдә ятабыз, — диде Таня.

— Ятабыз?! Нинди яту әле бу вакытта?

— Нишләмәкче буласың? Кайгыдан суга ташланырга уйламыйсыңдыр ич?

— Көлмә, — дидем мин ачусыз гына.

— Көлми ни! Синең йөзеңә карасаң, көлү түгел, әллә нишләрсең.

— Син карама!

Шулай бер-ике сүз әйтештек тә тынып калдык.

— Әйдә алайса клубка, — диде Таня.

— Клубка?! — дидем мин, шаккатып. Бераз тынып тордым да, тыныч булырга тырышып: — Син теләсәң нишлә, — дидем. — Мин анда беркайчан да бармаячакмын! Менә шул. Ә син бар. Мин сине тотмыйм.

— Синең белән саргаеп үләрсең, — диде Таня, үпкәләп.

— Синең тормышта максатың юк, шуңа күрә көнләшәсез сиңа, — дидем мин.

— Харап инде, синең генә максатың бар!

Мин аңа каты бәрелгәнлегемне аңлап алдым, телемне тешләп тынып калдым. Ләкин күңел барыбер тыныч түгел, һаман кытыклана, һаман кымырҗып тора.

— Бәхетле кешеләр озакламый укырга барачаклар! — дидем, Галия турындагы уйларымны дәвам итеп. — Ә без утырабыз монда канаты сынган кошлар кебек.

— Барсыннар, минем өчен барыбер! — ди Таня кыты гына.

Бүген ул да минем белән әллә ничек сөйләшә. Бүтән чакта ул бер дә алай түгел. Хәзер әнә бер сүз әйтеп булмый, кытыгына тия. Күрәсең, Равилне күрәсе киләдер.

— Башкача нәрсә дисең... минем өчен барыбер дисең инде, — дидем мин, үз алдыма сөйләнеп. — Галия әнә алай дип уйламый торгандыр әле.

— Ошамый миңа синең Галияң! — ди Таня, тагын да ныграк үртәлеп.

— Ник ошамый? Ник?!

— Отличница андый булмый.

— Нинди була соң?

— Кеше төсле... Китап корты, китап колы ул синең Галияң! Алай кем дә укый ала. Күрерсең әле, бер-ике елдан туберкулез алыр.

— Синең бар курыкканың туберкулез икән. Медицина хәзер туберкулезны тулысынча дәвалый.

Шуннан башка мин аңа бер сүз дә әйтә алмыйм. Галияне никадәр яратсам да, никадәр аңа табынсам да, бу минутта мин аны яклардай берни таба алмыйм. Дөресен әйткәндә, Галиянең күп кенә гадәтләрен мин үзем дә ошатып бетермим, тик шуны танырга гына куркам. Аннары, аның ошамаган якларына караганда ошаган яклары күбрәк тә, көчлерәк тә. Аның менә шул көчле яклары мине үзенә буйсындырып тора да.

— Минем яшисем килә! — ди Таня. — Кешеләрчә, яшьләрчә. Тагын кайчан яшәргә? Миңа унсигез яшь. Сиксән түгел, унсигез! Нәрсә миңа монда уку дип үз-үземне төрмәгә бикләргә?! Үлгәч — мәңгелек төрмә...

«Надан!» дип уйлап алдым. Үлгәч төрмә буламыни? Үлгәч анда төрмә дә юк! Никтер хәзер минем Таня белән сатулашып торасым килми. Мин инде бүген җитәрлек сатулаштым. Кычкырып, кайгырып арып беттем.

— Әйдә, алайса, ятабыз, — дидем.

— Хәзер минем ятасым килми, — ди Таня.

— Теләсәң нишлә, мин ятам.

Шулай дидем дә урын-җир әзерли башладым. «Иртәгә эшкә барасы бар бит әле», дип уйладым үз алдыма. Барыргамы, бармаскамы? Нишләп йөрергә икән соң анда адәм мәсхәрәсе булып? Болай да бөтен авыл көләдер әле. Түзмәдем, эшкә бару турында Таняга да әйттем.

— Барабыз! — диде Таня, берниндн икеләнүсез.

— Әйдә, алайса, тегеләргә барып кайтыйк, — дидем мин. — Баргачбаргач, өчәүләшеп барырга кирәк. Кем ул анда ялкауланып ятырга?!

— Әйдә! — диде Таня, сөенеп.

Тиз-тиз генә җыендык та Зөһрәләргә китеп бардык.

## XIII

Ишекне бикләп, ачкычны үзебез белән алдык. Капкадан чыкканда иплэбрэк, тавышланмыйчарак чыгарга тырыштык.

Урамда инде караңгы. Колхоз идарәсендә ут яна. Клубта да ут күренә, берәм-сәрәм тавышлар ишетелә. Икебез дә шул якка карадык, тавышларга колак салгандай итеп тордык. Аннары чирәм өстеннән әкрен генә китеп бардык.

Зөһрәләрнең өе, авылдагы барлык өйләр кебек, гади генә. Өй эчендә бүлмә-фәлән юк. Ишектән кергәч тә уң якта зур ак мич, каршыда караваг. Караваг өстенә чаршау эленгән. Почмакта мендәр өеме. Аш-су исе, яшь бала исе. Түшәмгә асылган сиртмәле бишек...

Без килеп кергәндә хуҗалар инде ятарга өлгергәннәр иде. Өстәлдә лампа янып утыра. Лампаны кысып куйганнар, шуңа күрә өйдә бик ук якты дип әйтерлек түгел. Күрәсең, яшь балага салкын тимәсен дип, ишекләрен ачмаганнар. Һава бөркү. Түшәмдә, казан тирәсендә чебеннәр безелди. Алар безелдәгәнгә, лампа филтәсе тавыш чыгарып янганга, аннары, бишектәге яшь бала йоклап ятканга, өй эче бик-бик тын булып тоела.

Без кергәч, Хисам абый да, Рафика апа да уянды. Рафика апа, чаршау астыннан чыгып, идәнгә төште дә, эчке күлмәгенең изүләрен тоташтырып, өстәлдәге лампага үрелде, утны күтәрде.

— Кызлар килгәнмени? Исәнмесез, кызлар, — дип кычкырды Хисам абый чаршау артыннан.

Без аңа:

— Исәнмесез, — дип җавап бирдек. Тәрәз янындагы утыргычка парлап утырдык та сүзсез генә хуҗаларны күзәтәбез. Безне ишек ачып керткән Нәсимә апа — Зөһрәнең әнисе — самавыр куярга кереште.

— Мәшәкатьләнмәгез, Нәсимә апа, — дидем мин. — Без ашап кына килдек, рәхмәт.

— Ашасагыз ни... менә... — диде Нәсимә апа. — Аштан олы кеше буламыни? Менә хәзер кайнап чыгар.

Рафика апа бертуктаусыз сөйләнә дә сөйләнә. Чебеннәрне тирги, өйдәге бөркүлекне тирги, аннары малае Азатны мактап ала, Түбән Чатка бардыгызмы, мин кирәк булмадыммы? ди. Мин аңа бер-ике сүз белән генә җавап бирдем дә кулларымны тез өстенә салып шулай утыра бирәм. Нәсимә апаның сүзләренә, кыланышларына карап мин үземчә бер фикергә килдем: күрәсең, минем тиргәшкәнне болар да ишеткәннәрдер, дидем.

— Фәгыйлә апа өйдә юкмени? — дидем тыелып кына.

— Фермада, — диде Нәсимә апа.

— Ул, бахыр, көн-төн шунда, бозаулары менән, — дип куйды Рафика апа.

— Зөһрәләр кая соң?

Зөһрәнең өйдә юклыгын мин кергәч тә сизеп алган идем. Кайда булыр ул? Билгеле, клубындадыр!

— Ул кирәк булдымени? — диде Нәсимә апа, пышылдап, ниндидер яшерен нәрсә турында сөйләшкән сыман.

— Тереллемени? — дигән булдым мин.

— Кайчан чирләде соң әле ул? — диде Хисам абый.

— Чирләп торды бүген, башы авыртты, — диде Нәсимә апа.

— Баш авырту да булдымы чир! — диде Хисам абый чаршау артыннан.

Нәсимә апа эндәшмәде, битләрен сыйпаштырып, чәчләрен яулык астына яшергәләп, чоланга чыгып китте.

— Яшьтәр өйдә ятмай инде. Алар клубта, — диде Рафика апа, моңсу гына елмаеп.

Мин Рафика апага карап утырдым-утырдым да кисәк кенә урынымнан тордым. Таня да кузгалды.

— Сезне юкка борчыдык, — дидем.

— Берәр йомышыгыз барыемени? — диде Нәсимә апа, ишектән керешли.

— Иртәгә амбар алдына эшкә барырга әйттеләр. Ашлык җилгәрергә. Иртән иртүк Зөһрә амбар алдына барсын.

— Ярар, әйтербез, — диде Рафика апа.

— Әйтербез, әйтербез, — диде Хисам абый да.

Рафика апа өтәләнергә тотынды: ник утырмадыгыз әле, диде, хәзер сәй кайнай, диде. Нәсимә апа да, Хисам абый да шул ук сүзләрне кабатладылар.

— Рәхмәт, эчкән чаклар да булыр әле, — дидем мин.

Саубуллаштык та чыгып киттек.

## XIV

Иртән без Зөһрә килгәнне көтеп тормадык. Ашадык-эчтек тә, искерәк киемнәребезне киеп, амбар алдына киттек. Вакыт әле иртәрәк кебек. Көтү яна чыгып килә. Чыннан да, без амбар янына барып җиткәндә, анда беркем дә юк иде әле.

Амбар алдына ашлык китереп өйгәннәр. Таудай булып ята. Өстенә салам ташлаганнар. Түбәсе ябык ындыр табагында да күлдәй булып ашлык җәелеп ята. Анысына салам капланмаган. Бодай. Сап-сары. Карар күзгә күнелле. Шунда ук җилгәргечләр, мичкә, әрҗә ише нәрсәләр. Бер почмакта капчыкка тутырылган ашлык өеп куйганнар. Анысы Янавылга озатыргадыр инде.

Без амбарга якынлашу белән, шул капчыклар арасыннан каравылчы карт килеп чыкты. Озын буйлы, төз, туры гәүдәле. Табак битле, кысыграк күзле. Чал кергән кыска мыегы, сакалы бар. Башында — иске бүрек, өстендә — кыска сырма.

Кулындагы таягын алгарак сузып басты да, бер сүз әйтмичә, безне көтеп алды.

— Исәнме, бабай, — дидем мин.

— Исәнме, кызым. Исәнмесез, — диде карт, безнең икебезне дә күздән кичереп.

Сүзләрне бик үк ачык әйтми, авыз эчендә лыбырдатыбрак сөйли. Шулай да тавышы көр, көчле. Каяндыр тирәннән, күкрәктән чыга.

— Нишләп йөреш? — диде бу. — Янавылгамени?

Кысык күзләрен елтыртып әле мина, әле Таняга карап алды, мыегын сыпыргалады, таягы белән җиргә төрткәләп куйды.

— Янавылга түгел, эшкә, бабай, — дидем мин. — Эшкә килдек. Ашлык җилгәрергә җибәрделәр.

— Эшкә? — диде бабай, ышанмагандай итеп.

Бер сүзне әйтә дә туктап кала, ни әйтерләр болар дигән сыман, көтеп тора. Үзе һаман безгә карый.

— Иртә бит әле. Иртәрәк кузгалгансыз.

— Нишләп иртә булсын? Без инде бу вакытта эшкә башлыйбыз, — дидем мин.

— Кемнәр соң әле сез? — диде бабай. — Үзебезнең авылмы дигәндәй...

— Үзебезнең авыл, — дидем мин, елмаеп. — Әллә танымыйсың?

— Яшьләрне каян танып бетерәсең инде.

— Фельдшер Сажидә бит мин. Сезнең «бырач».

— Ә, бырач! — диде бабай, җанланып.

Шулай дигәч, бу тагын мыегын сыпырып алды, кызулап таягын җиргә төрткәләргә тотынды.

— Ник килдегез соң монда? Мине тикшерергәмени?

— Юк, — дидем мин, көлеп. — Эшкә җибәрделәр, эшкә! Ашлык җилгәрергә. Кешеләр җитми ди...

— Ә-ә, — диде бабай, төшенеп. — Ашлык җилгәрергәмени? Бик хуп. Иртәрәк бит әле, кызларым.

— Утырып торыгыз, алайса, — диде бабай, капчыклар ягына күрсәтеп.

— Әйдә, — дидем мин Таняга.

Әле көн җылынмаган, салкынча. Мин юка киенеп килдем. Таня бәйләгән кофта кигән. Аңа рәхәт. Капчыклар янына килдек тә, бербереберезгә сыенып, тыгыз капчык өстенә утырдык.

Бабай, таягын төрткәләп, бер урындарак басып торды да шулай ук капчыклар янына килде. Килде дә, утырып тормады — читкәрәк басып, безнең каршыда туктап калды.

— Каян килдең соң безгә? — диде, миңа карап.

— Яңавылдан. Яңавылныкы мин.

— Бу кызым каян?

— Ул бик ерактан. Украинадан.

— Булган бар, — диде бабай. — Кәк булмаска! Гирман сугышында... мимечләрне куганда... Хураша хохол!

Соңгы сүзләрен ул Таняга карап әйтте. Без Таня белән көлеп җибәрдек. Бабайның кысык күзләре очкынланып китте. Безгә кушылып ул да елмайды.

— Утыр, бабай, — дидем мин, урын күрсәтеп.

Бабай ялындырып тормады — капчыкның буш башына җайлап кына утырды да шома таягын, тезләре арасына куеп, әйләндерергә тотынды.

— Бырач дисең, алайса? — диде, миңа карап.

— Әйе, бабай, фельдшер Саҗидә. Ә бу — Таня.

— Тәнә?

— Таня!

— Ярар, Тәнәме, Танамы... Безнеңчә беләме?

— Бераз сукалый.

— Сукалагач ярай. Аннан тырмалай башлар, чәчә башлар.

Таня, сүзнең үзе турында барганлыгын шәйләп, миңа карап-карап ала. Мин аңа кайбер сүзләрне әйләндереп бирәм.

— Бырач халкы белән дуслык юк минем, — дип куйды бабай бер дә юктан.

— Әллә яратмыйсың безне? — дигән булдым.

— Яратудан түгел — йомыш төшмәй. Шулай да бер йөрәкне барып тикшертергә дип йөрим. Вакыт юк.

— Йөрәгең нишләгән?

— Эшләмәгән. Болай гына. Тикшерү өчен генә.

— Кил бабай, кил, — дидем мин.

— Вакыт юк шул, — диде бабай, зарлангандай итеп. — Төннә менә каравылда торам. Көндез печән әзерләргә кирәк. Йоклап ята торган чак түгел.

— Әллә бөтенләй йокламыйсың?

— Кайчакта черем итеп аласың инде, — диде бабай тыйнак кына.

— Каравылда торгандамы? — дигән булдым мин, шаяртмакчы булып.

— Каравылда торганда да йокламасаң, кайчан йоклайсың? — диде бабай, бер дә исе китмичә.

Мин аны: юк, йокламыйм, дип әйтер дип уйлаган идем. Аның мондый эчкерсезлеге миңа кызык кына тоелды. Авыл кешесе шулайрак инде ул. Ачыктан-ачык. Ялганлап, күз буяп тормый. Барысы дамы? Юктыр, барысы да түгел. Кайберәүләр генә. Чын авыл кешеләре генә.

— Әллә хәзер генә карайсыңмы соң, кызым? — диде кинәт бабай.

— Нәрсәне?

— Йөрәкне, кызым.

— Йөрәкне?! Ничек карыйсың аны монда? — дидем мин. — Монда булмый. Пунктка кил, бабай. Монда бит бер нәрсә дә юк безнең.

— Торба кирәкмени?

— Кирәк шул.

— Шулайдыр инде, — диде бабай, килешеп. — Барырмын әле бер. Түлке син мине чиратсыз кертерсең, кызым, яме?

— Ярар, — дигән булдым мин. — Исемең ничек соң синең, бабай? Нишләптер мин дә сине белмим.

— Мине дә белмәгән кеше булыр икән! — диде бабай. — Шәйхаттәр мин, Шәйхаттәр карт.

— Ә, шулаймени...

Күңелемнән уйлап куйдым: нәрсәсе белән атаклы икән соң бу Шәйхаттәр карт? — дидем.

— Ничә яшьтә соң син, бабай? — дидем беравык тынып утыргач.

Карт сакал-мыегын сыпырды да тамак кырып куйган булды, таягын биетеп алды.

— Тугызынчы унны куып барабыз, кызым, — диде.

— Туксанны?! — дидем мин, исем китеп.

Таняга да тәрҗемә итеп бирдем. Аның да күзе дүрт булды, гаҗәпләнеп Шәйхаттәр бабайга карап алды.

— Сез күпме дигәнегез? — диде бабай, горур гына.

— Минем әти илле биштә. Сиңа, күп булса, алтмышны бирергә була, — дидем мин.

Шәйхаттәр бабай күңелле генә кеткелдәп алды.

— Менә шул була инде ул Шәйхаттәр бабагыз! — диде аннары, ачыктан-ачык бер масаю белән.

— Шулай да ничә яшьтә соң син, бабай? — дидем мин.

— Быел көз кырпак төшкәч сиксән икене тутырам, балалар, — диде бабай.

— Күз ничек күрә, күз? — дидем мин, Шәйхаттәр бабайның кысык күзләренә җентекләбрәк карап.

— Аллага шөкер, күрә. Көн яктысында хәреф таныйм.

— Колак ничек?

— Аллага шөкер, ишетмәгән нәрсәм юк, — диде карт.

Үзе тагын кеткелдәп көлеп куйды.

— Ашау ничек? Тешләр?

Шәйхаттәр бабай авызын ачты да саргайган эре тешләрен күрсәтте. Аның алгы тешләре, азау тешләре — асты да, өсте дә — барысы да исән иде, тап-таза иде. Минем гаҗәпләнүем соңгы чиккә җитте.

— Шул көе! — дидем мин шаккатып. — Карале, Таня!

Таня да бабайның авызына карады. Исе китте.

— Чирләгәнең булдымы, бабай? — дидем мин.

— Аллага шөкер, булмады. Бала вакытта чирләгәнмен. Әнкәй мәрхүм әйтерие: бик чирләш булганмын. Илла мәгәр үзем белгәндә хәтерләмәймен. Аякка тырма теше казалгач, аксап бераз йөрдем. Анысы да күпкә бармады, бетте.

— Аракы эчтеңме? Яшь чагында...

— Аракы безгә харам, — диде бабай җитди генә, әчке бер тантана белән. — Тәмәке дә харам. Дин кушмай.

— Без дә кушмыйбыз, — дидем мин.

— Дөрес, сез дә кушмайсыз. Бырачлар дин яклы.

— Алай түгел дә инде ул, — дидем мин, аның сүзләрендә политик хата күреп.

— Сез аны икенче төрле аңлаткан буласыз. Динчә булмасын дип...

Шулай диде дә кинәт сүзсез калды. Ана хөрмәт йөзеннән без дә тынып калдык.

## XV

— Эшкә соң чыгалар икән, — дип куйдым мин, яңадан сүзгә башлап.

— Хәзер эшләмәйләр, кызым, — диде Шәйхаттәр бабай тыныч кына. — Хәзер көн уздыралар. Менә никадәр ашлык исраф булып ята. Ярай әле монда кайтып житкән. Эпекәйнең кадере китте. Чүп урынына да күрмәйләр.

— Кем күрми инде аны чүп урынына да? — дидем мин.

— Кем дип... барысы да, кем ашлыкта эшләй. Ныгымас борын, яшел көе урдыралар. Анда үреп ята. Аннары икенче кат жыеп йөриләр. Суктыралар чи көе. Яртысы башакта кала. Калган яртысын илебатырга озаталар. Анда кыза, монда кыза. Коела, түгелә-чәчелә. Кадере юк ашлыкның. Элекке белән исәпләгәндә, нинди уңа хәзер! Бер чүбе юк. Карап торсаң, исең китәр.

Мондый сүзләрне тыңлавы миңа күңелсез. Мин аның дөресме, түгелме икәнлеген бик үк аермыйм. Шулай да сизенәм — сиксән ике яшәр карт юкны сөйләп утырмас. Чынлап сөйлидер, эче пошканга сөйлидер. Картлар алар тынгысыз булалар, хәзергене яратып та житкермиләр, гел элеккене мактау ягын карыйлар. Ләкин Шәйхаттәр бабай элеккене дә мактамый, зарлана, пошына гына.

Таня белән без бер-беребезгә сыенып утырабыз шулай. Бабай, сүзнең ялганып китмәвен күреп, тагын тынып калды, «Йа алла!» дип бер көрсенеп куйды да таягын тукылдатырга тотынды.

— Алайса, сез бырачлар буласыз? — диде кабатлап.

— Шулай, — дидем мин.

— Кичәгенәк нәрсә булештегез соң? — диде бу миңа карап.

Миңа кинәт бик кыен булып китте.

— Булды инде, бабай, — дигән булдым, тыныч күренергә тырышып.

— Ипле йөрегез, балалар, — диде бабай йомшак кына итеп. — Тәүфикълы булыгыз. Әйтүче юк сезгә, үрәтүче юк. Мин менә әйтәм дә малайларга — тыңламайлар. Әркем оста, белекле. Кайчагында олылар сүзен дә тоту кирәк.

— Шулайрак булды инде, бабай, — дигән булдым мин, үз-үземне шелтәләп.

— Ярар, яшь чакта була инде ул, — дип куйды бабай да. — Яңгышып куясың шулай. Сиңа чаклы берсе дә рәтләп карамады, диләр. Барганым булмагач, әйтәлмәймен. Кеше сүләй. Әйбәт эшләргә кирәк, кызым, тел-теш тиярлек булмасын. Хураша рабутайт нады! — Таняга карап алды да кысык күзләре белән генә елмаеп куйды. Таягын шакылдатты, тамак кырды, сакал-мыегын сыпырды.

— Бик чибәр күренәсез, — диде аннары, мактап. — Менә үзегезне кияүгә бирербез. Мәсәгут киленнәре булырсыз.

— Безгә дигән кияүләр мич алдында көл ашый! — дигән булдым мин, остарып.

— Көл ашап туйганнардыр инде, — диде бабай, икебезгә дә мут күзләре белән караштыргалап.

Күз алдына шундук «көл ашап туйган кияү» килде. Бүген бит аның белән очрашасы да бар әле! Нишләргә аны күргәч? Ничек карар ул миңа?

Кыска гына вакыт эчендә күңелне шундыйрак сораулар тынычсызлап алды. Тынычсызлап кына түгел, үзәкләрне өзеп алды.

— Ярар, балалар, — диде Шәйхаттәр бабай, урыныннан торып. — Мин кайтаем. Сез, алайса, эшкә килдегез?

— Эшкә, эшкә!

— Катыннар кузгалып килгәнче төш житәр. Сез яшь кеше. Әнә анда салам астында көрәкләр, сәнәкләр бар. Кул кушырып утырганчы,

тотыныгыз, алайса. Бодайны ачыгыз. Саламын читән буена ташып куегыз. Ындыр табакны себерә торырга да була. Бодайны шул якка тараталар.

Ул безгә кайдан себерергә кирәклеген күрсәтте. Саубуллашты да, гәүдәсен төз тотып, әкрен генә авылга таба китеп барды.

Таня белән без саламны актарып ташладык. Кочаклап күтәреп читән буена ташырга тотындык.

Бодай өемен ачып бетергәндә, авылдан амбарга таба килүче берничә җан иясе күренде.

## XVI

Болар бер ир кеше белән ике хатын-кыз булып чыкты. Хатыннарның икесе дә миңа таныш. Берсе шофер Мәгъсүм абый хатыны, икенчесе — тол хатын Камилә. Иңбашына калын сумка аскан, юан гына, таза гына абзый таныш түгел. Аның пунктта булганы юк. Минем танышларның барысы да диярлек чирле-мырлы кешеләр. Шулай булгач, аның миңа таныш булмавы бер дә гаҗәп түгел.

Килделәр болар, исәнләштеләр дә төрле якка таралдылар. Сумкалы агай үлчәү янына килде. Сумкасыннан вак-төяк таш шикелле кечкенә герләр алып куйды, үлчәүгә сөяп калдырылган сәнәкне бер читкә ташлады. Мин аның монда нииндидер баш кеше икәнлеген аңлап алдым.

Хатыннарның берсе әйтте: «Килдегезме?» диде, икенчесе: «Кызлар бездән иртәрәк кузгалганнар», диде.

— Килдек, — дидем мин. — Иртә торып өйрәнгәч, ашыгыбрак килгәнбез.

— Зарар юк, — дип куйды тол хатын.

— Әндәр бичәсен көтеп торабызмы, тотынабызмы, Камиләттәй? — диде шофер хатыны.

— Ниндәй көтү ул? — диде сумкалы агай. — Ашлыкның Әндәр бичәсендә эше юк. Тиз кыланыгыз.

— Безнең Зөһрә дә килмәгән әле, — дип куйдым мин.

— Зөһрә койрыкны тоттырмас! — диде Камиләттәй.

Сумкалы агай безнең янга килде.

— Сеңелләр барында тырышып эшләгез, — диде хатыннарга. — Сынатмагыз.

— Әйдә, сынатса-сынатмаса, алар яшь кеше — эшләй торган чаклары, — диде Камиләттәй.

— Саламны үзегез ачтыгызмы? — диде агай безгә. — Шәйхаттәр карт әйттеме? Әйбәт булган. Әнә шул төшне себереп ташлагыз да таратыгыз. Көн явымга китте. Кичкә кадәр яхшы гына җилләй әле ул.

Сумкалы агай безгә шулай тегесен-монысын әйткәләде дә каядыр амбар ягына китеп барды.

— Тотындык, алайса, кызлар, — диде Камиләттәй.

Башта без себерке белән киң генә такыр урынны себереп куйдык. Аннары кулларга агач көрәкләр алдык та өелгән бодайны шул такыр җиргә сибәргә тотындык.

Башта ук мин чын күңелдән бирелеп эшләдем, хатыннар алдында оятка калмаска тырышып эшләдем. Мондый эш миңа таныш. Агач көрәк белән мин элегрәк кар көри торган идем. Аннары, Уфада укыганда безне ике ел колхозга алып бардылар. Анда да шундыйрак эшләр эшләргә туры килде.

Берничә минут чамасы без баш та калкытмадык. Бераздан хәл алмакчы булып, барыбыз да билләрне турайттык, берьюлы бер-беребезгә карап алдык, елмаешып куйдык. Һәркемнең йөзе алсуланган һәркем еш-еш тын ала. Бары Камиләттәй генә шул көе диярлек — йөзендә әз генә дә кан әсәре юк.

Авыл ягыннан тузан туздырып килүче бер машина күренде. Машинаның килеп житүен көтеп тормастан, янадан эшкә тотындык.

Машина килеп житте, түбә алдында туктап калды. Шаулашып, жиргә малай-шалайлар төште. Шап-шоп кабина ишеге ачып-япкан тавышлар ишетелде. Иелгән башны күтәрмичә генә шул якка күз төшереп алдым.

Юк, беркем күренми. Ягъни мин күрергә теләгән кеше күренми. Башымны калкыткандай иттем дә машина ягына озаклабрак карарга тотындым. Юк, килмәгән. Әллә кемнәр шунда. Янавылга алып китәргә ашлык төйиләр бугай.

Күреп торам, Таня да астыртын гына шул якны күзәтә.

— Беркем юк, — дидем русча.

— Юк шул, — дигән булды Таня.

Икебез дә көлешеп куйдык.

— Әнә, шытты! — диде шофер хатыны, авыл ягына ымлап.

Барыбыз да күтәрелеп шул якка карадык. Болай таба ашыгып ниндидер хатын-кыз килә. Күрәсең, Әндәр бичәсе дигәннәре шулдыр.

Кабаланып килеп житте дә тиз генә кулына көрәк алды. Шуннан соң исәнләште, артык сөйләнеп тормастан, эшкә керește.

Хатын бик таза күренә. Эре сөякле, юан гына гәүдәле. Жилләнеп, пыр тузып эшли. Сибеп жибәргән бодае ындыр табакның икенче башына барып төшә. «Менә көч монда!» дип уйлап алдым мин, кызыгып.

Ярар, болар барысы да килеп беттеләр, ахрысы. Безнең Зөһрә нишләп килми соң һаман да? Әллә бөтенләй килмәскә итәме? Мин чынчынлап тынычсызлана башладым. Баштарак: килсә ярый, килмәсә ярый, диебрәк уйлаган идем. Ләкин мөдирлек тойгысы көнләшү, яратмау тойгысыннан шулай да өскә чыкты. Ни әйтсәң дә, ул бит минем кеше! Аның өчен мин җаваплы!

## XVII

Бер заман мин онытылып киттем. Эшнең җаена яттым да эшлим дә эшлим. Килеп тотынгач та шундый авыр булып тоелган эш җиңеләеп китте. Тыным озайды, кулларым ныгыды, агач көрәк җиңел, ышанычлы йөри башлады. Без тездән бодайга батып эшлибез. Аста бодай җылы, аякка рәхәт. Үзеңнән-үзең онытылырсың.

Кемдер колак төбендә генә:

— Исәнмесез, — дип кычкырып җибәрде.

Бәлки ул алай кычкырмагандыр да, миңа гына шулай тоелгандыр. Мин сискәнеп киттем, билемне яздым. Карасам, Тимерҗан басып тора! Безнең эшне күзәтә. Йөзе житди, иреннәре кысылган, күзләре каядыр каш астына кереп яшеренгән. Өстендә эш киеме — иске генә кыска бишмәт, тапланган яшел фуражка. Минем этинеке кебек. Аның да сугыштан алып кайткан шундый ук яшел фуражкасы ишек башында чөйдә эленеп тора.

Хатын-кызлар бер-бер артлы аңа җавап кайтардылар: исәнме, Тимерҗан, диделәр, бик исән әле, диделәр. Мин бер нәрсә дә әйтмәдем. Телем тотлыкты. Уңайсызлануымны сиздермәс өчен янадан көрәгемә тотынган булдым.

Безнең янда бу озак тормады, кызулап машина янына китеп барды.

— Зөһрә юк бит, Зөһрә! — диде аның артыннан шофер хатыны.

Тимерҗан җавап кайтармады. Хатыннар үзара мәгънәле генә елмаешып алдылар.

— Чирләп тора бугай ул, — дидем мин, никтер Зөһрәне якларга чамалап.

Нәкъ шул чакта, бөтенләй көтмәгәндә, Зөһрә күренде.

Килеп житте. Башкалар кебек исәнләште дә, безнең эшләгәнне карап, туктап калды. Барыннан да элек өс-башы күзгә ташланды. Клубка баргандагы кебек киенгән! Мин беренче мәртәбә күргәндәге кебек. Ал кофта, тар кара юбка, биек үкчәле туфли. Чәче матур итеп таралган. Битенә, житмәсә, кершән яккан.

Бүтән киеме беткәндер! Авыл кызы, имеш. Фу, тора лабаса кыланып, кулларын биленә таянып. Үзенә карамаска әллә ни бирерсең.

— Әйдә, көрәк ал, Зөһрә, эшкә тотын, — дидем мин.

Кузгалмады бу. Шунда безнең янга башлык агай килеп житте.

— Эшкә болай соңлап йөрмиләр, сеңелем, — диде усал гына. — Үзеңнән олы кешеләрдән оялырга кирәк. Әнә алар күпме эшләделәр, син әле яңа күзеңне жырткансың. Мин бит сиңа аерым язмам!

Зөһрә каршы сүз әйтмәде — жирдә яткан көрәкләр янына килде дә үзенә яраклысын сайлап алды, бодай өеменә керде.

Ул болай каефле генә күренә. Теге янгыр яуган кичтәге шикелле түгел. Аңлашканнар, ахрысы. Әйе шул, Тимержан миңа күтәрелеп тә карамады ич!

## XVIII

Бөтенләй кирәкмәгәндә күңел кырылды. Эш тә әлләни мавыктырмый башлады.

Тимержан һаман машина тирәсендә булаша. Ә бит ул дөрес эшләмәде! Без аңа ярдәмгә килдек. Без монда чит кешеләр. Безгә килмәсәк тә булыр иде. Шулай булгач, ул безгә алай ук караңгы чырай күрсәтергә тиеш түгел. Миннән башка монда бит Таня да бар әле. Мине күрәсе килмәсә, аның белән сөйләшергә була. Унны бетергән, имеш. Унны түгел, әллә нәрсә бетерсә дә, барыбер шул Тимержан булып калыр.

Калса әллә! Минем өчен барыбер түгелмени?!

Төрлесен уйлангалап мин әкрен генә кыймылдыйм шулай. Беркем белән сөйләшмим. Хатыннар да, Таня да сөйләшми. Төшкә кадәр беребез дә ачылып китмәдек. Баш калкытмый эшлибез. Бодай өемен бөтен ындыр табагына җәеп ташладык. Шуннан соң беркадәр ял итеп алдык. Ял иткәч, тагын бодай актарырга керештек. Бер үк бодайны әвештүеш китерәбез, жилләтәбез, киптерәбез.

Сәгать унике тулу белән өйгә кайтып киттек. Таня белән бәрәнге пешереп ашадык. Ашадык та амбар янына киттек. Тагын беренче булып килгәнбез. Бераздан хатыннар да күренде. Эшкә тотынганчы гәпләшеп утырдык. Хатыннар үзләренең авырулары турында сөйлиләр, миннән киңәш-мазар көтәләр. Үземне бирелеп тыңлаганнарын күрдемме, шундук минем психологиям үзгәрә. Мин үземне ышанычлы итеп, тыныч итеп тота башлыйм. Үз сүзләремә карата жаваплылык тойгысы арта. Тыңлаучыга файда итәсем, аның ышанычын аклыйсым килә башлый.

Хәзер дә шулай булды. Мин сөйлим, алар тыңлый. Миңа рәхәт, күңелле. Шулай сөйләнеп утырганда, башлык агайның килгәнен күреп алдык. Өсләрне каккалап аягүрә бастык та иренеп кенә көрәкләргә тотындык.

Кояш кыздыра. Дымсу бодай чыннан да жилләгән сыман. Көрәккә дә жиңелрәк, аякка да артык кызу түгел. Җәелеп ташланган бодайны бер кат әйләндердек тә комбайннан килгән икенче өемне таратырга керештек. Аннан соң җилләгән, җилгәрелгән бодайны капчыкларга тутырыштык.

Капчык тутырып ятканда, искәрмәстән Равил килеп чыкты. Атка утырган, арбасына мичкә салган. Өстендәге киеме майга, тузанга буялып беткән. Кайдадыр амбар ягында «ягулык склады» бар икән. Бензин, керосин ише нәрсәләр саклый торган урын. Шунда китеп бара. Безне күреп алды да ерактан ук кычкырып исәнләште. Балкып-елмаеп

безнең янга килде. Апалары, дигән булды, кулларыгыз кабара күрмәсен, шприц тота алмассыз, дигән булды. Кычкырып сөйләнә-сөйләнә яңадан арбасына утырды да сабуллашып китеп тә барды. Комбайннарга «гәрүчи» илтәсем бар, диде. Складтан борылып кайтканда да безгә нәрсәдер кычкырып китте. Без аңа кул болгадык, елмайган булдык. Таняны инде әйтәсе дә түгел — кояштай балкый.

Равил китеп күп тә үтмәде, басу ягыннан Тимерҗан килеп чыкты. Мин тагын сискәнеп киттем. Ул икәнен белдем дә артыма борылып карадым. Авызымны ачып тик торам! Мине хатыннар күреп алдылар. Зөһрә дә, Таня да күрде. Кып-кызыл булдым. Башымны иеп, яңадан кулыма көрәк алган булдым.

Тимерҗан эндәшмәде, сумкалы агай янына китеп барды.

Һай аллам, егылып үләрсең кешеләрнең кылынышына!

## XIX

Дүшәмбе көн бик күңелсез башланды. Күңелсез башланды, күңелсез бетте. Көне генә түгел, атнасы да авыр, күңелсез узды. Ул атнада бер-бер артлы көтелмәгән хәлләр булып алды.

Шулай бервакыт кабул итү бүлмәсенә олы гына яшьтәге бер хатын килеп керде. Күреп торам, Мәсәгутнеке түгел. Шулай ук тирә-як авыллардан да түгел. Ник дисәң — удмурт хатыны. Минем авылларда удмуртлар юк. Кара күлмәгенең итәгенә буй-буй итеп ал, сары, яшел тасмалар тегеп чыккан. Күлмәк изүендә төрле төстәге чигүләр. Аягында ялт итеп торган резин итекләр. Кулында — кечкенә төенчек.

Килде дә бу, исәнләште, күрсәтелгән урынга утырды.

— Юаны син буласыңмы, апа-ай? — диде.

Татарча бозып сөйли. Сүзләрнең соңгы иҗекләрен сузып әйтә.

— Нинди «юаны», нәрсәнең? — димен, берни аңламыйча.

— Юаны баш тиганнарые, — ди бу. — Миңа юаны кирагые.

Әллә минем сорауны аңламый, әллә колагы ишетми. Чынлап та, ишетми, ахрысы.

— Нинди «юаны»? Аңлатып сөйләгез, — димен кычкырып.

— Ничкасына куренма, юанына курен тиганнарые, — ди хатын, бер үк сүзләрне кабатлап.

Безне тыңлап торган Зөһрә шунда пырхылдап җибәрде. Аның шундый әдәпсезлегенә, оятсызлыгына ачуым килеп куйды. Шундук мин моңа мәгънәле генә күз карашы ташлап алдым. Бу минем ачуланганны күрмәмешкә салынды, каядыр читкә карап, көлгәләгән булып:

— Сине халыкта Юаны дип, Таняны Нечкәсе дип йөртәләр, — диде.

Әһә, менә нәрсәдә икән хикмәт! Ярсудан агарынып киттем. Кемгә ачуланырга да белмим — авызын ерып, мыскыллап торган Зөһрәгәме, үчекләшкән шикелле сөйләнеп утырган удмурт хатынынамы.

— Сөйләгез — кай җирегез авырта? — димен, бар тавышыма кычкырып.

— Кулак ишытмай бит але минем, апаем, — ди хатын.

Бармагы белән үзе колагына күрсәтә.

— Куптәнме? — димен, колагына кычкырып.

— Нарса?

— Кайчаннан бирле авырта?

— Ученчы кон мунча кырдем. Тумаланды. Бырни ишытмай, апаем.

— Аңа кадәр яхшы ишеттеңме?

— Мунчада су кыргәндер димын шул. Бырни ишытмаем, бутынләй тумаланды.

— Акмыймы?

— Калтасу раюныннан мин апаем. Сине мунда якшы карай тиганнарые.

— Акмыймы дим!

— Биграк яман икан ул кулагың ишытмагач, апаем.

Моңа кадәр әле миңа чит районнан килгәннәре юк иде. Бу хатынның күрше районнан булуы күңелне җилкетеп куйды. Мин моны бик әйбәтләп, җентекләп карамакчы булдым. Карасам, колагы тулы сагыз!

Такта стенага шакып, теге якта утырган Таняны чакырдым. Ул да карады. Шуннан без икәүләп киңәштек тә колакны юарга булдык. Зөһрәгә күп итеп җылы су әзерләргә куштым. Су әзер булгач, Таня белән икәүләп удмурт хатынының колагын махсус шприц ярдәмендә юдыра башладык. Шактый озак азапландык. Алмаш-тилмәш юдык. Су түгеп хатынның күлмәкләрен чылатып бетердек. Колакларның икесе дә юылып беткән кебек булгач:

— Хәзер ишетәме? — дидем.

— Тунды. Бутынлай тунды, — ди бу.

— Су кергәнгә тонган, — дидем мин. — Бетәр әле. Иртәгә әйбәтрәк ишетә башларсың.

Шулай юатып моны чыгарып җибәрдем.

Икенче көнне бу тагын иртән иртүк килеп житкән. Ишекне иплэп кенә ачты да килеп керде кабул итү бүлмәсенә. Өстендә шул ук киемнәр, кулында — кара сумка.

— Колак ничек, апа, ишетәме? — дип кычкырам мин моңа, килеп утырмас борын.

— Ишыта, апаем, айбат буген! — ди бу шатланып, елмаеп.

Никтер бу өстәл янына ук килми, идән уртасындарак туктап тора. Күзләрен мәгънәле генә җемелдәтеп, кил әле диген сыман, үзе миңа нәрсәдер ымлап ала. Нәрсә булган тагын? Зөһрәдән шикләнә микәнни? Ник шикләнә?

Моның ымлавына буйсынып, шулай урынымнан тордым. Янына барып житкәнемне көтмичә, хатын икенче якка ук чыгып китте. Көтеп тору бүлмәсенә. Анда өч-дүрт кеше моңаеп, чират житкәнне көтеп утыра. Чыктым мин моның артыннан.

— Нәрсә бар? — димен.

— Ишыта, апаем, ишыта! — ди бу кычкырып.

— Нәрсә бар, әйтегез шушында гына, — димен.

Хатын эндәшми. Чоланга ук чыгып китте бу. Як-ягына күз төшереп алды да кулындагы сумканы ачып җибәрде. Карасам, ак дәфтәр битенә төрелгән ике йомарлам май. Берсе-берсе берәр кадак булыр.

— Сиңа бу, апаем, сыңныкаш. Кучтанач, — ди бу. — Кулагым бик якшы ишыта. Рахмат яусын, апаем. Халал ризык, шикланма. Кича гына яздым.

— Юк, юк! Үзеңә булсын, апа! — дидем, кул селтәп.

Без шулай сатулашып ятканда, чоланга Зөһрә килеп чыкты. Чиләк күтәреп суга китте. Мине шунда ямьсез бер сизенү өтеп алды. Күңелгә шундук: «Кара, исәнәеп, каранып йөри!» дигән бер уй килде. Көтеп тору бүлмәсенең ишеге ябылып бетми калган иде. Авырулар ишетеп торсын дигән кебек, юри ныграк кычкырып:

— Юк, апа, — дидем хатынга. — Безгә күчтәнәч кирәкми. Ярамый. Зурлавың өчен рәхмәт. Сезне дәвалаган өчен безгә акча түлиләр.

Шулай дидем дә, хатынны аптырашта калдырып, кердем дә киттем. Өстәл янында язып утырганда күреп торам: хатын, сумкасын кул очына тотып, әкрен генә урам буйлап китеп бара.

## XX

Зөһрәнең иртән мыскыллап көлүен дә, минем арттан шымчыланып йөрүен дә нишләптер бик тиз оныттым. Көне буе мин сөенечле бер уй белән йөрдем. «Миңа хәзер чит районнардан да киләләр!» дип уйла-

дым, масаеп. Бәлки, ул масаю да булмагандыр. Эчкерсез бер шатлык кына булгандыр. Үз эшенең нәтиҗәсен күреп кем генә шатланмас икән?! Әнә... колагым ишетә, ди. Мин дәваладым бит аны. Мин!

Шулай да миңа озак шатланырга туры килмәде. Икенче көнне үк минем кикрик шинде. Канат сынды. Дөнья ямьсез булып, кара булып калды. Ул көнне Таня өйдә юк иде. Авыруларны мин үзем генә кабул иттем.

Икенчеме, өченчеме кеше булып, кабул итү бүлмәсенә бер агай килеп керде. Озын буйлы, киң күкрәкле. Таза. Бик таза. Мондый кеше турында: басса бакыр изәрлек, типсә тимер өзәрлек, диләр. Кырык яшьләр чамасы. Битен сакал-мыек баскан. Күрәсең, кырыныр чамасы юк — кулы бәйләүле.

Утырды. Урындык шыгырдап, ыңгырашып куйды. Исемен-фамилиясен, кайсы авылдан булуын сорадым. Алдар авылыннан икән.

— Ни булды, кай җирегез авырта? — дидем.

— Менә, сеңлекәш, үтерә шушы бармак, — ди агай. — Бәйләп кенә җибәрче.

Шулай сөйләнгәләп ул бәйне чиште, кулын миңа табарак сузды. Баш бармагы кып-кызыл булып шешкән, юанайган. Шешү, кызгылт юл булып, беләккә таба сузылган. Шешкән бармакның тиресе юкарган, ялтырап тора.

Шешкән бармакка иплэп кенә кулымны тидереп карамакчы булдым. Минем кагылуым булды, агай, коты алынып: «ай!» дип кычкырып җибәрде. Шундук кулын тартып алды.

— Сез бик әбәләк икәнсез, — дидем, шелтә белән.

— Булмассың әбәләк! — ди агай. — Җылан карагы диләр аны! Бер атна күземә йокы кергәне юк. Дошманыңа күрсәтмәсен мондый чирне.

— Ник соң баштарак килмәдегез? — димен.

— И сеңелем, — ди агай гаепле төс белән. — Әйтми булмый инде, карчыклардан имнәткәнием. Файдасы тимәде. Имсез китми дигәннәрие.

— Әнә шулай карчыкларга ышанасыз да, атналар буе йоклый алмый җәфаланасыз, — димен ачуланып. — Ник утыртып куйганнар безне монда?! Ник пункт ачканнар?! Сез имче карчыкларга йөрсеннәр өченмени?

— И сеңлекәем, әйтмә инде. Наданлык, томаналык, — ди агай, үз-үзен гаепләп.

Диагноз мәсьәләсендә баш ватып торасы булмады. Халык телендә бу — «җылан карагы», фән телендә — панариций. Укыган чакта аны безгә берничә мәртәбә күрсәткәннәр иде.

— Ярырга туры килер, — дидем шундук бер карарга килеп.

— Юк, юк, ярдырмыйм! Дару гына сөрт, — ди агай, чыраен сытып.

— Сез инде бала түгел. Шуннан да куркып торгач! — димен җиңелчә мыскыл белән.

Шул арада үзем тиз генә кулны юдым, тырнакка, бармак битләренә йод сөрттем. Шул эшләрне бетергәч, агайның авырткан кулын нык кына итеп тотып алдым да, аның ай-ваена да карамыйча, шешкән бармакны дезинфекцияли башладым.

— Имче янына барырга курыкмаган, фельдшер янында курка! Әзрәк оялырга кирәк, — дип сөйләнәм үзем, бала-чаганы юаткан сыман. — Курыксагыз — карамагыз. Берни булмас, черки тешләгән кебек кенә... Черкидән дә куркып торгач...

Тиз-тиз генә эшемне бетердем дә күз ачып йомган арада скальпельне алдым. Агай исенә-акылына килергә өлгергәнче, шешне буйга ярып та җибәрдем. Минем ярып җибәрүем булды, яшелле-зәңгәрле тавышлар белән агай дөнья бетереп акырып та җибәрде. Кычкырмады — акырып, чинап җибәрде!

Зөһрә көтеп тору бүлмәсендә иде. Аның анда кем беләндер пыш-пыш суган сатканы ишетелә иде. Шундук ишектән атылып килеп керде. Ачык ишектә куркынган йөзләр чалынып калды. Башкасын күрә алмадым. Шул ук секундта бармактан шыбырдап кан агарга тотынды. Кан күргәч агайның, күрәсең, башы әйләнеп китте. Искәрмәстән капчыктай идәнгә ауды да төште.

Тотып кала алмадым. Көчем житмәде. Аннан соң мин аны һуштан язар дип башыма да китермәгән идем. Минем өчен бу аяз көнне яшен суккан кебек булды.

Зөһрәгә шкафтан нашатырлы спирт алырга куштым. Ул агайның борын төбенә нашатырлы спиртка манчылган мамык тидерде. Идәндә хәрәкәтсез яткан агай бераздан әкрен генә тын алды, төчкереп жибәрде, кыймылдап куйды, күзләрен ачты. Бичараның маңгаеннан салкын тирләр бәреп чыкты.

Мин тиз генә тәрәзәне барып ачтым, барлык ишекләрне ачып җибәрдем. Бүлмәгә саф һава бөркелеп керде. Агай торырга азаплана башлады. Зөһрә белән без аңа ярдәм итмәкче булдык. Ләкин ул бик авыр булып чыкты. Шунда безгә көтеп тору бүлмәсеннән бер егет кереп булышты. Өчәүләп моны яңадан урындыкка утырттык. Тиз-тиз кыланып, мин ярылган бармакны бәйләп куйдым, агайның кулындагы кан тапларын сөртеп алдым.

— Менә бүген инде рәхәтләнеп йокларсыз, — дигән булдым, юатып. — Иртәгә бәйләтергә килерсез.

— Ярма дип әйттем мин сиңа, — диде агай, ыңгырашып.

— Ярмыйча ярамый, — дидем мин. — Ярмасаң, азуы мөмкин.

Минем сүзләремә агай ышангандырмы, юктырмы — әйтә алмыйм. Шулай да аның ачуы, кәефсезлеге миңа да тәэсир итте. Үземнең дөрес эшләгән булуыма никадәр ышанган булмыйм, барыбер күңел тиешенчә тынычлана алмады. Мин үземне гаепле итеп сизә башладым. Агайдан соң кергән авырулар хәзер миңа шикләнеп карыйлар шикелле тоелды.

Кикрик шиңү менә шуннан башланды.

Авыруларны карап бетергәч, үзебезнең якка чыктым. Кулыма «Хирургия» китабын алып, «панариций» темасын укыган идем, телсезөнсез калдым. «Ах, туң баш!» дидем үземә-үзем. Үкенүдән, йөрәк әрнүдән күзгә яшьләр килде.

Бармакны мин иртә ярганмын. Шеш тулып җитмәгән, бармак авырткан чакта, бик нык авырткан чакта ярганмын!

Икенче көнне агай килмәде. Минем хәсрәтне көчәйтеп җибәрергә бу тагын бер сәбәп булды. Эштән соң мин аның өенә дә бармакчы булдым. Ләкин икеләндем. Ни булса да булыр дидем дә бармадым. Соңыннан мин аны шулай да очраттым. Бармагы инде төзәлгән иде. Ул миңа берничди шелтә белдермәде. Көлеп кенә куйды. Җитмәсә, рәхмәт тә әйтте. Сүзең дөрес булды, сеңлекәш — ул көнне тынычлап йокладым, диде.

Безнең очрашу бер-ике айдан соң гына булды. Ә ул чакта чыбыксыз телефон аша миңа бик үк күңелле булмаган сүзләр ишетелде. Үземә генә дә ишетелеп калмады. Түгәрәк дулкыннар булып, минем турыдагы имеш-мимеш бөтен авылга таралды. Көннәрдән бер көнне мине авыл Советына чакыртып алдылар.

## XXI

Авыл Советында Галим абый белән Вәзирдән башка кеше юк иде. Мин Галим абый кабинетына кердем. Галим абый утырырга кушты. Утыргач, кырыс кына бер карап алды.

— Беләсеңме, нәрсәгә чакырттым мин сине, сеңлем? — диде.

— Белмим шул, Галим абый, — дидем мин.

Ни өчен чакыртканлыгын белмәсәм дә, яхшыга түгеллеген алдан ук сизенеп алдым. Нинди гаебем бар икән дип, шундук үткән көннәрне күз алдына китердем, тегенди-мондый нәрсәләрне искә төшердем. «Күрәсең, Вәзир әләкләшкәндер, пунктта аулак өй ясап яталар дип әйткәндер», дип уйладым. Үземә калса, минем иң зур «гаебем» бары шул гына иде. Күңелгә тиз арада әзер сораулар, җаваплар килде. Ләкин сөйләшә башлагач, минем бу сорау-җавапларның бернигә кирәге калмады.

— Белмәсәң, менә шул, сеңлем: синең турыда начар сөйлиләр,— диде Галим абый.— Күңелеңә авыр алма. Сөйләшми ярамый.

Мин дерт итеп киттем. Кая инде ул авыр алмаган! Йөзеңә карап: син начар! дип әйтсеннәр әле! Кем генә монда тыныч карый алыр икән? Мин кып-кызыл булдым. Күзләремне түбән идем. Галим абый, җанын-ны суырып алырдай булып, бертуктаусыз күзгә карап тора. Күрәсең, йөзгә карап дөресен белмәкче була.

— Нинди начар сүз, Галим абый? — дидем иплән кенә, юаш кына.

— Ниндиме? Бәлки, син үзең дә беләсеңдер — сөйләп бир... нинди гөнаһларың бар?

— Ишеттем... — дидем мин.

— Нәрсәне ишеттең?

— Нәрсәне дип... Бармак ярганны сөйлиләр. Аннары юлда бала таптырганны...

— Нинди бала тагын?

— Теге Тау-авылыныкы соң. Беренче көнне. Рәмзия исемле хатын... Баласы әйбәт үсә. Берни булмаган.

— Ярар, анысы да булды. Тагын?

— Тагын дип... Тагын шул инде: бер картның тешен суырганда сынып калганые. Анысы да беренче көннәрдә. Безне теш суырырга өйрәтмәделәр. Мин инде үзлегемнән. Китаптан карап. Үзе сорады бит, авыртса да түзәрмен, теләсә ничек суырып ал, диде. Мин әле аның сынып калган тешен дә алдым.

— Ярар, монысы да булды,— диде Галим абый тыныч кына.— Тагын?

— Тагын дип... тагын шул, әнә Вәзир абый белән әйткәләштек. Бинт юк. Акча бирми. Хәзер әнә тәрәзәгә элгән марляларны кисеп бинт ясадык. Минем өстә лә алар барысы да, Галим абый! Мин бит яраны бәйләми җибәрә алмыйм. Инфекция булырга мөмкин, азарга... Аннары кем җавап бирә?

— Ярый... Тагын! — диде Галим абый, сабырлыгын җуя башлап.

— Тагын... ни... шул... Заһидә апа белән әйткәләштек. Үзе әнә әләк-ләшеп йөргән юк-барны... Вәзир абыйга. Авыргач без аның баш очын-нан да китмәдек. Таня гел кереп торды. Хәзер әнә йөри. Берни юк. Безгә әллә кеше дә керми торырмы?

Шул чакны үз бүлмәсенең ачык ишегеннән секретарь кычкырды:

— Мин сезгә кеше кермәскә тиеш дип әйтмәдем,— диде.

Мин аның Галим абый алдында ялагайлануын сизеп алдым да, батыраеп:

— Вәзир абый — олы кеше, үзе әнә төрле гайбәт сүзләргә колак сала,— дидем.— Безнең сүзгә ышанмый. Нәрсә... кем дип җибәргәннәр безне монда? Ышанмасалар җибәрмәсләрие. Минем әле беркемгә дә ялган сөйләгәнем юк.

— Ярар, сеңлекәем,— диде Галим абый.— Вәзир абыең белән нәрсә турында сөйләшкәнсездер — анысы миңа караңгы. Бинт турында ул дөрес әйткән. Сметадан узып без бернәрсә дә эшли алмыйбыз. Киләчәк-тә бинтларыңны саклабрак тотарга тырышырсың.

— Шулай итәрмен, Галим абый,— дидем мин, тиз генә килешеп.

— Заһидә апаң белән тиргәшүең әйбәт булмаган, сеңлем. Бик ямьсез булган.

— Шулай шул, — дидем мин.

— Дөрес, алар пункт йортында торырга тиеш түгелләр. Аларга инде яхшылап әйтелде. Шулай да без аларны урамга куалап чыгара алмыйбыз. Шуның өчен аларны кыерсыту... фельдшер кешегә килешеп бетми. Син бит интеллигенция! Ярамый, икенче кабатланмасын! Колагыңа киртеп куй моны.

— Ярар, Галим абый, киртеп куярмын, — дидем мин.

Шуннан Галим абый эндәшмичәрәк торды, минем йөзгә тагын бер төбәлебрәк карады да:

— Удмурт хатыныннан май алдыңмы? — диде.

— Юк, алмадым, — дидем мин, каушап, аптырап.

— Чынмы?

— Чын, Галим абый.

— Ник халык сөйли соң? Миңа килеп әйтәләр... фельдшер Сажидә авырулардан май, күкәй алып ята, диләр, үзен майлаган-җайлаган кешене генә яхшы карый, шундыйларга гына яхшы дару бирә, диләр. Дөресме шул?

— Дөрес түгел, Галим абый! — дидем мин, калтырана башлап. — Мин беркемнән дә май да, күкәй дә алмадым. Майны мин үзебездән алып килдем, Яңавылдан. Күкәйне дә. Ышанмасагыз әнә Таңядан сорагыз.

— Мин сиңа ышанам, сеңлем, — диде Галим абый, көттереп, әкрен генә. — Ләкин мин ышану гына җитми. Җилсез агач шауламый, диләр. Димәк, шулай да нидер булган? Ни булды?

Ни булганын мин сөйләп бирдем.

— Мин сиңа ышанам, — диде Галим абый, кабатлап. — Ярар, сүзне шуның белән бетерик. Борчылма... Күңелеңә авыр алма. Кыен булса, андый-мондый йомышың булса, икенче туп-туры үземә кил — ничек тә уртак тел табарбыз.

— Килермен, Галим абый, — дидем мин, җиңеләеп.

Авыл Советы председателе бүлмәсендә шундыйрак сөйләшү булды. Галим абый янынннан мин тынычланып, яңарып, үз-үземә тулы ышаныч белән чыгып киттем. Мин нишләптер беркемгә дә ачуланмадым. Бары гаҗәпләндем генә: кем сөйли алыр икән шундый чеп-чи ялганны? Удмурт хатыны булмас. Ул әйтер иде, күчтәнәчкә май алып килгән идем, алмады, дияр иде. Алмады дигәч, алмаган дип сөйләрләр иде. Кем соң алайса? Шул көнне минем кабул итүне көтеп утырган авыруларның берәрсеме? Әллә соң Зөһрәме?

Мөгаен, шулдыр! Нишләтергә аны? Нишләргә аның белән? Әллә кайтып пыр туздырып ташларгамы? Куалап чыгарырга?! Ничек эшләргә, ничек яшәргә киләчәктә аның белән? Каян килеп чыкты соң бу Тимерҗаны да?

Минем күңелдә төрле уйлар буталды. Мин әлегә нишләргә дә белмәдем. Тик шулай да минем өчен бер нәрсә ачык: моннан соң миңа ничек тә акыллы, сабыр булырга кирәк. Түзәргә кирәк, барысын да уйлап эшләргә кирәк. Мин бит сүз бирдем!

Ләкин күп тә үтмәде, минем барлык уйларны, барлык хис-тойгыны икенче якка борып җибәргән кайбер вакыйгалар булып алды.

*(Ахыры бар.)*

# Диңгез ярында

Электә таврлар
Яшәгән бу ярда...
Мин — дәрвиш сокланып
Чиксез киң суларга,
Хыялга өртелеп,
Күземне йомам да
Бирелэм онытылып
Уйларга, уйларга...

Түбәсе болытта
Мондагы тауларның,
Исәбе булмаган
Мондагы яуларның,
Кем көчле — шул килгән.
Кем җиңгән — шул кергән
Куенына кермәндәй[1]
Таш-кыя ярларның.

Бу илгә килгәннәр:
Юнаннар, җинвәләр,
Хазарлар, төрекләр...
Басмаган кем аяк!..
Диңгездә акчарлак,
Тауларда бөркетләр
Шаһитләр — күргәннәр:
Кыйналган гел бу як...
Таврия илендә —
Дөньяның читендә,
Яшәүгә юл ярып
Кылычлар уйнаган!..
Баскыннар тынмаган:
Кызганып тормаган
Көчсезне көчлеләр...
Җир сыкрап елаган...
Кан коеп, яшь түгеп,
Сугарып ташларны
Йөргәннәр кешеләр;
Аннан үз башлары
Шул ташлар астына
Мәңгегә күмелгән...
Янгыннан, сөремнән,
Кермәннәр көленнән,
Тузаннан болытлар
Ашканнар һавага...
Син кайда карама:
Хәрабә, хәрабә...

Ташларга язылган
Елъязма күк алар
Сөйлиләр бүген дә,
Узса да заманнар.

Күпме ир — җиһангир[2]
Исемсез югалган!
Ә халык юлында
Мәңгелек эз калган.

Кипарис, чинарлар
Эчендә Ялта — яр[3];
Узыша пальмалар,
Кәстәнә, анарлар...
Яртылаш чумган да
Ял итә Аю-даг,
Очан-су, Җилкән-тау...
Кайда бар мондый як?!
Таш таулар өелгән
Диңгездән читенеп:
Иң өстә Ай-Петри,
Күкрәген киереп,
Мәһабәт түбәсен
Күтәргән айларга!
Ә диңгез тын ята,
Калгандай хәйранга.

Тын ята. Ул менә
Кузгалыр бер заман,
Күтәрер чал башын
Һәм шашар ул тәмам,
Тузгыр ак яллары,
Ташланыр таш ярга,
Мәңгелек тауларны
Аударып ташларга.
Кыялар ватканчы,
Күбеккә батканчы
Ул кайнар, сикерер!
Күкләргә атылып,
Алмаздай ватылып,
Тамчылар сибелер.
...Һәм тынар зур диңгез
Көзгедәй тип-тигез,
Ятар ул ялтырап,
Тауларга төбәлеп.
Чарасыз аптырап,
Баш тартып ярсудан,
Кыйналган тән сыман
Ятар ул күгәреп.
Ник Кара дигәннәр
Күм-күк бу диңгезне?
Җәгърафи төшенчә,
Алдама син безне!
Курикче дөньяны

---

[1] Кермән — крепость.

[2] Җиһангир — дөньяны яулап алучы.

[3] Ялос, ялита, ялта — грекча яр (диңгез яры).

Шигырьдә бер сизсез.
Күрдем мин күп диңгез,
Күрмәдем тик Кара
Диңгездән зәңгәрен.
Ник Кара? Белмәссең
Дөньяның хәлләрен!..

Шул диңгез, шул таулар
Сулышында узганнар
Тоела, ишетелә
Тузанга тузганнар...
Хыялда бер ерак
Үткәнгә юнәлсәң,
Ни гаҗәп! уеңда
Шуларны күрәлсәң.
Ханнар һәм каганнар
Килгәннәр, киткәннәр,
Гомерләр үткәннәр
Ничәмә-ничә йөз...
Тик ташта да кала
Халыклар салган эз!
Без генә, кай вакыт,
Яд итә белмибез:
Әйләнә-тирәбез
Бик тыныч булганда
Онытабыз, тетрәүсез,
Тын тормыш куганга.

Сора син диңгездән,
Ул шаһит, ул күргән:
Күпме яу корабы
Суларга күмелгән.
Сора син ташлардан:
Ничәмә кермәннәр
Җимерелеп, хәрабә
Хәленә килгәннәр.
Дәһшәтле давыллар
Күргән бу урманнар...
Карт тарих еракта:
Томаннар, томаннар...

Сарайлар, сарайлар...
Берсеннән берсе шәп!
Патшалар һәм ханнар,
Калырга бер яшәп,
Бу мәрмәр йортларда
Гыйш-гашрәт иткәннәр.
Сарайлар калганнар,
Тираннар беткәннәр.
Халыкның тирләре,
Күз яше, каныннан
Шул гүзәл сарайлар
Безгә алынган...
Калмаган патшалар,
Ханнарның үзе дә.

Тик калган сарайлар
Халыкның үзенә.
Халыкның үзенә
Кояшның җылысы,
Диңгезнең сулышы,
Тауларның һавасы...
Бик килә минем дә
Иркенләп бу җирдә
Сулыйсым, җаныма
Бер дәва аласым.

Уйласаң, күпме дау
Булган бу Кырымда!
Яшәү дип күпме ил,
Күпме җан кырылган:
Малахов курганы,
Перекоп, Сапун-тау...
Мин менә шул җирдә,
Мин менә исән-сау.

Без менә исән-сау.
Ә аяк астында
Тетри җир — тетри тау...
Ул җанлы, ул сулый,
Бар аның тавышы,
Бар аның сагышы...
Сакла, — дип, — исеңдә,
Корбаннар исеменнән
Сауларга ул сөйли
Зур, авыр язмышны.

Корбаннар ядына
Тын тора таш таулар.
Ә диңгез үзенчә:
Бер тынар, бер шаулар,
Ул зәңгәр суларын
Күкләргә ашырып
Һәм төшеп түбәнгә,
Ташларга баш орып.
Тауларга килешә
Мәңгелек тантана.
Диңгезгә гомергә
Тынычлык юк аңа!

Ул менә бүген дә
Көчәйтә сулавын,
Ватылган бәллүрдәй[1],
Чәчрәтеп суларын,
Ярдагы коймага
Килә дә түртелә...
Өстендә акчарлак,
Бер елый, бер көлә.

1967

[1] Бәллүр — хрусталь.

*Гомәр Бәширов*

# Туган ягым — яшел бишек



*Автобиографик повесть*[1]

## Давыл алдыннан

### I

Көн урталарында төшлектән рәхимсез эссе җил исәргә тотынды. Ул, кызу мич алдында торгандагы кебек, кайнар сулышы белән кырда эшләүчеләрнең битләрен ялап үтте, тамакларны киптерде. Кырдагы хайваннар һаваның кыздыруына һәм исәпсез-сансыз чебен-кигәвенгә түзә алмыйча, көтүчеләрен басуда калдырып, тибенә-тибенә, койрыклары белән ярсып селтәнә-селтәнә яр буйларына, өянкеләр күләгәсенә чабыштылар. Инеш буена әлсерәшеп томшыкларын ачкан кош-корт килеп ябырылды.

Без басуда идек. Мин арба астына кердем. Әни эсседән башы чатнаган, иреннәре кипкән, теле аңкауларына ябышырлык булган хәлдә, кызгылт-сары төскә кергән тузанлы, эссе күккә үпкәләгән сыман:

— Бу ни хәл инде бу? — диде. — Яндыра да көйдерә! Кичкә хәтле шулай кыздырса, икмәксез калабыз бит! Нәрсә ашарбыз? Малларны нәрсә белән туйдырырбыз?

Атларны түздереп булмый башлады. Без тоташ тузан эченнән авылга чаптык.

Тыкрыктан Бикә түти күренде. Ул яулыгын татарча ябып, мәчетнең аена карап тезләнде дә, әлеге дә баягы шул бисмилласын әйтә-әйтә, мөселман алласына ялварырга кереште.

— Ходаем, кавеф-катәрдән сакла, боз җаудыра күрмә. Болытларың тегендә дә монда мәнесезгә айкалып йөри. Җибәр шуларны җангыр итеп, җаусын бер рәкатьләндереп!

---

[1] Ахыры. Башы 5—8 саннарда.

Әмма күкнең беркемдә дә эше юк, ул һаман кыздыра, эссе җилләрен һаман дулата иде.

Менә урман өстендәге аклы-каралы калын болытлар үзара болганырга, кайнашырга тотындылар. Бик яман давыл кузгалды, өермәләр куптьы. Агачлар иелә-бөгелә шаулый башлады. Авыл өстенә болытларның салкын сулышы килеп бәрелде. Бикә түти битен сыйпарга да онытып, кычкыра-кычкыра керәшен ягына йөгерде:

— Кодайларым, карәп булдык! Боз килә! Боз, боз!

Бөтен тирә-якны томалап, түбәләргә чатыр да чотыр таш кисәкләре сипкән тавыш чыгарып, эреле-ваклы боз яварга тотынды. Югары өйнең тәрәзәләре чылтырап ватылды. Ишек алдыннан кереп житми калган кечкенә сеңел ачыргаланып җылап җибәрде. Чикләвек хәтле, тавык йомыркасы хәтле боз кисәкләре дөмбәсләүгә түзә алмыйча, басу капкасыннан атлар чабышып кайтты. Кешеләр әле борыннарына, әле колакларына ябышалар иде.

Озак та үтмәде, «Менә болай да итә беләм әле мин!» дип юри үчекләгәндәй, шул арада ялт итеп тагын кояш чыкты.

Боз туктады. Урамдагы гөрләвекләр тынарга да өлгермәде, кайсы җәяү, кайсы атка атланып, басуларга ашыктылар. Әле менә күптән түгел генә, без кайтканда гына гөрләп үсеп яткан иген кырларында шул арада ниләр генә булмаган! Кайсының бер башагын да исән калдырмыйча буйдан-буйга арышын сугып киткән, кайсының бодаен, солысын, арпасын.

Безнең игеннәрнең байтак өлеше көтү таптап узганга охшап изелеп, чәбәләнеп беткән иде. Мин шул турыда кайтып әйткәч, әти, минем ни әйткәнемне аңламагандай, күзләремә сәер генә текәлеп торды-торды да, бу хәлгә бик гаҗәпләнгән сыман:

— Шулаймыни? — диде. — Һем. Нишләп алай яртысын гына калдырды икән? Бер тотынгач, бөтенләй сугып бетерәсе калган, чистый кара туфракка калдырып.

Бу сүзләрне ул шундый салкын кан белән, шул ук вакытта шундый рәнжеп әйтте, хәтта минем аркам чытаеп китте. Әллә чынлап та бөтен игенне боз сугып бетерүен телиме?

Җирләр кибеп житәр-житмәс халык арыш басуына чыкты. Җиргә сыланып аркылы-торкылы сынып яткан игенне хәллерәкләр чабарга маташалар, ярлылар бала-чагаларын алып чыгып, бөтен өй эче белән берәмлекләп җирдән башак чүпли иде.

Иске бетеп, яңа өлгергәнче ел саен авылны соранучы баса иде. Бу елны алар бигрәк тә күп йөрделәр. Иртәдән керә башлыйлар, кичкә кадәр ишек ябылмый. Кайсы ялгыз, кайберләре кечкенә балаларын иярткәннәр. Никадәр күп йөрсәләр дә, әни аларның берсен дә буш кул белән чыгармады. Тик күңелне сыкратып торган авыр борчу анда да үзеннән-үзе бәреп чыга иде.

— Мәгез, сынык кечкенә дип гаеп итмәгез. Сезнең өлешегезне әнә ходай алды.

Соранучылар юка гына икмәк телемен бишмәтләре шикелле ук төрле төстәге кырык ямаулы иске капчыкларына салгач, битләрен сыйпагандай иттеләр.

— Беләбез, — диделәр. — Ил өстенә бәла килде, бәла. Ходай артын хәерле итсен инде.

Әмма бәланең иң зурысы ул түгел икән әле. Анысы — иң куркынычы, бөтен дөньяны кайгыга салганы — атка атланып волостьтан няреп кайтты. Ул, йөрәкләргә ут салып, тирән кайгы салып, минут эчендә бөтен авылга таралды:

— Сугыш!

— Герман сугышы башланган!

## II

Бу шомлы хәбәрне ишетүгә башта, берни аңламагандай, каушап калдылар:

— Ничек соң әле бу? Кызу урак өсте ләбаса! Игеннәрне җыймаган. Бөтен ашлык басуда. Кем урыр, кем сугар. Көзге чәчүне кем чәчәр?

Староста, дисәтникләр белән чыгып, китәсе кешеләрне өй борынча кисәтеп йөрде.

— Кызыл билетлеләр кырык яшькә чаклы берсе-бер калмыйча иртәгә көтү куган вакытта Казанга чыгып китә! Штобы, сохари алсын, кашык белән кружка алсын! Патша хәзрәтләренең фәрманы шулай!

Авылда җылау-сыктау башланды. Иртәгә солдатка булып каласы киленнәр, ирен соңгы мәртәбә юындырып җибәрү өчен, җылый-җылый мунча ягарга, чишмәдән су ташырга кереште. Карчыклар күз яшен сөртә-сөртә сохари киптерергә, капчык әзерләргә тотынды. Яшь кияүләрне ашыгыч кына чәйгә алдылар.

Безнең әти, үзен-үзе кая куярга белми, ишек алдында арлы-бирле сугылып йөрде дә капкадан Мөхәммәтҗан җизни күренгәч, туктап бот чабып куйды.

— Кара әле син, ә? Ниярсә җитми бу йөзе караларга? — диде. — Җирме? Малмы?

— Патша сугышмыйча тора алмый, бабай. Сугышмагач, нинди патша ул?

— Соң кан коела бит, халык кырыла!

Мөхәммәтҗан солдатның иреннәре бөрешеп, күзләре елтырап китте:

— Кем каны коела? Аның үз каны түгел бит. Нәрсә ул аңа синең белән минем каным! Безнең балаларыбызның каны!

— Хәмзәне күрми калабыз. Ул хезмәт иткән җиреннән генә сугышка китәр. Вәли китә, ике кияү китә. Бөтен авыл баласы ятим кала. Кемгә төшәр аларның күз яше, ә?

Яшьрәкләр шул арада Мәнәтәдән чирекле «кызылбаш»ны кайтарып та өлгергәннәр икән, авылның берничә җирендә кычкырып җырлаган тавышлар ишетелә башлады. Аргы якның бер төркем кызып алган егетләре, җырлый-җырлый, Фазулланың тау астындагы кечкенә өе янына килеп чыктылар. (Тазару өмете беткәннән соң, тау астында бер генә тәрәзәле кечкенә өй салып, Фазулланы шунда күчергәннәр иде.) Бикбулат Мәрдәне һәм Сәлим йодрыклары белән Фазулла өенең стенасын төяргә керештеләр.

— Әй, Фазулла! Әйдә, гармун уйнап урам әйләндер әле!

Мин Вәли абыйны саубуллашу чәенә дәшәргә дип алар тирәсенә төшкән идем. Мондый хәлне күргәч, Фазулла өе янына бармыйча булмады.

Бер генә өлгеле кечкенә тәрәзәдән Фазулланың ыңгырашканы ишетелде. Ләкин аңа карамастан, егетләр һаман кычкыралар, ишеккә, стеналарга тибәләр иде.

Теге вакытта кунак кызга хат язганнан соң мин Фазулланы болай да бик кызгана башлаган идем. Хәзер егетләрнең аны болай азаплаулары мине бик рәнҗетте.

— Күрәсез ич, урыныннан да тора алмый! — дидем. Ләкин егетләр тагын да бәйләнәрәк төштеләр:

— Гомергә авырый ул! Кайчан аның авырмаган чагы бар?

— Ул авырый гына әле, ә без менә үләргә барабыз. Чык, давай!

Күрәсең, Фазулланың хәле бик авыр булгандыр, ул һаман да чыга алмады.

Шунда егетләрнең берсе:

— Без хәзер патша кешеләре! — дип кычкырып җибәрде. — Ничми безне саннамаска! Тотыгыз өенең почмакларыннан! Өе-ние белән инешкә аударып ташлыйбыз.

Чыннан да, шау-гөр килеп, кызган баштан якланып, өйнең дүрт почмагыннан күтәрә үк башладылар. Нәрсәдер шартлады, чытырдады, өй бер якка кыйшая башлады. Шул вакыт бусагада кәфен төсле ак чырае, бераз бөкрәя төшкән озын-ябык гәүдәсе белән муенына ак сөлге ураган Фазулла күренде. Егетләр айкала-чайкала килеп аның аркасыннан, иңбашыннан кагарга тотындылар.

— Менә, маладис, күптән шулай кирәк!

— Син дә үләсе, Фазулла туган, без дә үләсе! Давай, агай-эне, бармакларың кыймылдаганда, ичмасам, бер әйттереп кал әле!

Фазулланың зәңгәрсу төскә кергән озын бармаклары гармун телләре өстендә уйнаклый башлауга, бөкресе языла төшеп, гәүдәсе тураеп киткән кебек күренде.

Куе зәңгәр бożра эчендә калган куркыныч зур күзләре нәрсәдер эзләнәләр, кемнәндер үч алырга җыенгандай ашыгып, ярсып ялт та йолт як-якка айкалалар иде. Ул шулай гармунын бөтен көченә тартып, ашкынып-ашкынып уйнады да бераздан тагын юашланды. Бөкресе яңадан калкып чыкты. Ул хәзер йөрәкне сыкрата торган кайгы көйләре уйнарга тотынды.

«Кызылбаш» та мәлҗерәткәндер, аерылу хәсрәте дә, олы урамга күтәрелгәндә егетләр;

Я кайтырбыз, я кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар! —

дип сузып җибәрделәр.

## III

Ирләр артыннан сугышка байтак кына атларны да кудылар. Кайбер солдат хатыннарына, сугышның беренче көненнән үк, йортның терәге булган бердәнбер атларыннан да аерылырга туры килде. Староста белән дисәтник солдатка алынган атларны арба артларына тагып авылдан алып киткәндә, солдатларны озаткандагы кебек үк, җылаусыктау купты. Солдат балалары аталарыннан калган малкайларын, сөекле җирәннәрен, кара турыларын авыл башына кадәр җылый-җылый озата бардылар. Чит кеше кулына килеп эләгүгә борчылыпмы, әллә үзләре туып-үскән, хуш исле үләнен ашап үскән шушы болын-кырлардан, алан-урманнардан бөтенләйгә аерылуларын сизенепме, атлар борчылышып пошкырыналар, артларына борылып карыйлар, бара торгач, күзләрен утландырып, борыннарын киңәйтеп кешнәп куялар иде.

Бөтен авыл, мәет чыккан йорт кебек, хәсрәткә чумды. Кичләрен өйләргә ут алмый башладылар. Һәркем көн буе йөрәген талаган авыр кайгысыннан аз гына булса да аерылып торырга теләп, караңгы төшүгә тизрәк күзен йомарга ашыга иде.

Сабан урагы бетәр-бетмәстә сугыштан беренче хатлар килде, көзгә таба беренче яралылар кайта башлады. Ул көннәрдә халык телендә гел шулар гына булды. Беренче булып яраланып кайткан Мәдьяр солдат аз гына аксый, таякка таянып йөри иде. Ул яшел погонлы соры шинелен егетләрчә иңенә салып, аксый-туксый әле каравыл лапасына барып чыга, әле берәрсенең ындырына, кибән куйган җиргә килә. Кайда гына тукталмасын, ул кадерле кунак. Аннан һаман со-

раштыралар. Ул сөйли. Сугыш җирендәге гыйбрәтле хәлләр дә калмый, «гушпитальдә» ятулар да. Аның авызыннан әледән-әле Галичия, Аршау, Минскн, Пински дигән ят сүзләр яңгырап китә.

— Безнең бик батыр бер янарал бер мәлне нимечнең янтавына шәп кенә итеп берне тондырган иде, нимечең гупчи астына ук җибәрде. Шундый кырдык тегене! Белдеңме шуны! Аю шикелле без. Безнең ачу чыгып җиткәндә чыдап кына тор!

Сарник Галимҗан үртәнүдән ботына ук сугып куйды.

— Син, аллагыз бар иткерләре! Нишләп туктадыгыз? Шул чагында әлеп алып, мин сиңа әйтим, селкеп салып, үз җиренә тикле куасыгы калган швапны [1].

— Һе! Ансат кына сиңа! — ди Мәдьяр. — Мич башыннан торып гайрәт чәчәргә без барыбыз да мачтыр. Әнә, мылтыксыз атакага барып кара әле син!

Тыңлаучылар, шаккатып, берьюлы кычкырып куялар.

— Китсәнә аннан?! Нишләп мылтыксыз? Янараллар нәрсә караган? Мылтыксыз сугышып булмаганны мәнди анасы да белә бит!

Мәдьяр, сүзенә ышанып җитмәүләренә үпкәләгән сыман, читкә борылып, таягы белән бераз җирне тукылдатып торды.

— Син анысын әнә Миколашканың үзеннән сора! Белдеңме шуны? Ул бит главный янарал! Миңа ничу алдап маташырга! Безгә нәрсә? Әфисәрләр куса, барасың, кайт дисә, кайтасың. Сугышның артына сарык шикелле куып китерәләр дә ятасың көтеп. Күп тә үтми, дисвительни берәрсе үлә, я ранный була. Ә син винтовкалы буласың.

Ир-ат юклыгы кайбер хуҗалыкларны беренче елда ук какшатып ташлады. Мал-туарны кимётергә, ягарга җитмәгәнлектән, икешәрөчәр хуҗалыкка бер йортта кыш чыгарга туры килде. Сугышның икенче елында ук әйбер бәяләре бик яман өскә сикерде. Керосин бөтенләй бетте, бабайлар заманыннан бирле чормаларда кугәреп яткан шәмдәлләрне табып алып, халык чыра яндырырга тотынды. Кичләрен чаршауларга, пәрдәләргә, сөлге-тастымалларга кара сөрем утыра. Төн чыкканчы кешеләрнең борын аслары кап-кара сөрем була. Иртә торсаң, кар өстендәге сукмакларда кап-кара булып чабата эзләре ярылып ята.

Кайбер солдат хатыннарына беренче елны ук кара пичәтле кәҗүнни кәгазь килде. Бөтен бала-чагасы, нәсел-ыруы, күрше-күләне белән җылашып кайгырышып арганнан соң, чама белән генә булса да вакытын билгеләп, я кырыгын, я еллыгын уздыралар, васыятьләрен үтиләр. Әле сугыш алдыннан гына кая басарын белмичә дертләнеп торган таза япь-яшь киленнең бер ай эчендә йөзенә сары йөгерә. Ул бернечә ай эчендә әлеп киптергән төсле була. Баласызлары атасына кайтып китә. Ике-өч баласы булса, ир-атлы, җиткелекле тормыштан бөтенләй өмет өзеп, мал-туарны кимётергә, бөтен хуҗалыгын кысарга тотына, бөтен гомеренә михнәт чигәр өчен тол хатын булып кала.

## IV

Арча Иванның безнең келәттә кибет ачуы хәлебезне җиңеләйтмәде. Күрәсең, безнең йорттагы бөлгенлек чокырын кибетче биргән фатир хакы белән генә тутырып булмагандыр.

Мөхәммәтҗан солдат шул уңайдан, безгә килгән саен, гадәтенчә, каты гына итеп тешләп ала торган булды:

— Мин әйтәм, сезгә бу кибетнең файдасы бихисап инде, ә! Бөте-

[1] Швап — немец дигәне.

несе бушлай! Иван алма сатканда черек алма исе дә, сасыган балык исе дә...

Әти үртәгәнне яратмый торган иде. Шулай да ул бу юлы Мөхәммәтжан солдатка ачуланмады. Буыннары бирчәеп бөгелмәс булган коңгырт бармаклары белән чалара башлаган сакалын кашып тыныч җавап бирде:

— Башыңа төшкәч түзәсең инде, солдат, — диде. — Мин мөгезеннән тотып торам. Иван сава. Шулай да иске бишмәткә бер ямаулык. Староста тамагына бер сөяк. Мин ул акча белән имана түлим.

Ләкин ул ямаулык та тиз кубып төште. Иван, кибетенең калдык-постыгын Чистай ягыннан килгән бер исерек башка сатып, озакламыйча чыгып тайды.

Әни белән без үзебезнең арыш урагын бераз җиңеләйткәч, чәйшикәргә булса да ярап куяр дип, күршедәге Цызгановка күнлеклап уракка йөри башладык.

Менә бүген дә, гадәттәгечә, таң белән торып, аннан-моннан сөтле чәй эчтек тә мәчет янына чыктык. Безнең ишеләр, җенсәгә төрелгән урагын инбашына салып, теләр-теләмәс, атлар-атламас шунда ук җыела башлаганнар иде. Ир-ат бөтенләй юк, үсмерләрдән бер Минзай гына күренә. Ул ни турындадыр хыялланып, күзен йомган килеш мәчет баганасына сөялгән дә уйга калган. Кыз-кыркын битен кояш ашамасын дип, яулыгын каш өстенә үк төшереп бәйләгән дә тар ярыктан күзләре генә елтырап күренә.

Күп тә үтмәде, бер генә кешелек сыгылмалы биек пролеткага зур күк ат җиккән Цызганов үзе килеп чыкты. Битләре чөгендер төсле, чал сакалы, мендәр хәтле булып, күкрәгенә җәелгән.

Цызганов пролеткасыннан төшеп кенә торганда, тыкрыктан йөгерә-атлый, сулышы кабынган Кируш килеп менде. Судебный дигән алпавыт көнлекчеләр җыярга аны җибәргән икән.

— Нигә монда җыелдыгыз? Әйткән бит сезгә каравыл өе янына дип!

Кайберәүләр кузгалырга омтылса да, бүтәннәр аларны җиңнәреннән тотып калдылар.

— Кабаланма, бәясен әйтсеннәр! Кайсы күбрәк бирә, шунысына барырбыз!

Кируш:

— Илдә ничек — анда шул. Бай егерме тиен түләргә кушты, — диде.

Төркем эченнән иң беренче булып Сәхипҗамал кычкырды:

— Очсыз! Нәрсә аласың хәзер егерме тиенгә? Өч кап шырпымы? Бармыйбыз!

Цызганов дисәтник итеп Гыйбаш абзыйны яллаган икән. Ул аны янына чакырып нидер әйтте. Гыйбаш абзый халыкка борылып:

— Егерме биш тиен! — диде.

Без, ялланырга килүче көнлекчеләр, шау-шу килеп, этешә-төртешә, бөтенебез бердәй аның ягына чыгып беттек. Гыйбаш абзый озын дәү борыны белән пошкырып, үзенең алашасы кешнәгәндәй калын тавыш белән көлеп җибәрде:

— Ха-ха-ха! Синең эшләр, Кируш, малай, кәкәй бит!

Кируш ярылырга җитеп арлы-бирле сугылды.

— Аса мине бай, аса! Аягымнан тотып аса!

Ул шулай ике арада бәрелеп-сугылып йөрде дә, Гыйбаш абзый көнлекчеләрне алып китә башлагач, «беткән баш беткән!» дигәндәй кулын селтәп үз бәясен кычкырды:

— Чәнчелеп китегез! Утыз тиен!

Моны ишетүгә без, көлешә-көлешә, бөтен өеребез белән яңадан

Кируш ягына авыштык. Безгә нәрсә? Кем күбрәк бирә, без шунда!

Хәзер инде Цызганов беләч бирүзе торып калган Гыйбаш абзыйдан, кара сакалын сыйпаштыргалап, Кируш кәләргә тотынды.

— Менәтерәк! Калдынмы берүзең янган капка баганасыдай турсаеп!

Ул үз янына җыелучыларга кул болгады:

— Әйдәгез, киттек! Әле дә никадәр вакыт юкка уздың!

Ләкин Цызгановның сакалы селкенеп куюы булды, Гыйбаш абзый тагын аваз салды:

— Әйдәгез миңа! Күп тә кырмассыз, тик тә тормассыз! Җил-янгыр тидермәм! Кырык тиен!

Без янадан Гыйбаш ягына авышып, Цызганов басуына чыгып киттек. Кайсыдыр:

— Дуңгыздан бер кыл! — дип өстәде.

## V

Мине сугышның беренче елыннан ук солдатларга хат язарга дәшкәли башладылар. Дөрес, яшьләрнең күбесе язу таный иде. Чөнки авылда мәдрәсә ачылганнан соң кызларның абыстайга йөреп укымыйча надан калуы гаеп санала башлады. Ник дисәң, яучы хатыннар үзләре димли торган кызларның уңганлыгын, кулы эш белүен мактап сөйләгәндә «теләсә нинди китапны су күк эчә» дип тә ычкындыралар иде.

Тик абыстай кызларны укырга гына өйрәтә, язу яздырмый иде. Янәсе, язу язарга өйрәтсәң, егетләргә хат язып азып китмәгәе!..

Болай хат язарга йөрүләр минем үземә дә ошап китте. Кеше яраткач, нигә язмаска? Апа-җиңгиләрнең мин язган хатларны мактап сөйләүләре иптәшләрем арасында мине күтәреп җибәрде. Кимсенеп күңел төшкәндә дә ул миңа бер юаныч була иде.

Әмма бу изге эшнең кыен яклары да килеп чыккалады. Хәллерәк кешедә тагын бер хәл. Әмма ярлы йортларда кайчакны үзенне кая куярга белми башлыйсың. Өйләре салкын, караңгы, балаларның өсте сәләмә. Җитмәсә, хатны язып бетерүенә, сине хөрмәт итеп, чәй хәзерлиләр, табынга бер-ике сынык икмәк белән фәкать кунак-төшем булса дип кенә саклаңган, хәзер инде өсте зәңгәрләнә башлаган акмай, я сары май китереп куялар. Шул сый-хөрмәтне алдыңа этәрә-этәрә, синә авыз ачарга ирек бирмичә, чын күңелдән кыстарга тотыналар:

— Хәзинәдә бары инде, гаеп итмәсәнә! Бик үк тәмле булмаса да, тәмле генә итеп ашап-эчеп утырсана! — диләр.

Май дигән нәрсә үз өендә дә бик еш эләкми, ашыйсы да бик килә. Сыпырып кына саласы да бит, булмый! Табындагы ризыкка чаршау кырыеннан ач балалар күзе текәлүен күргә, тамактан бер нәрсә үтмәс була. Хәтерләрен калдырмас өчен, бер-ике генә кабып, берәр чынаяк кына эчкән буласың да тизрәк чыгып киту ягын карыйсың.

Бүген барган йортым андый ярлылардан түгел иде түгелен. Картларының җомга намазына киткән чагы икән, карчык каядыр биләмгә киткән, өй аулак. Сәҗидә җиңги мин барып керүгә бишмәтем белән бүрегемне чөйгә элдерде, түр сәкегә минем өчен көрпә салды. Үзе почмак якка чыгып җитез генә самовар куярга керешге. Ни әйттем: «Язам да китәм, чәй эчеп тормыйм!» дидем. Кая ул, колагына да элмәде:

— Юк, юк! Әллә нидә бер килеп чәй дә эчми китәләрмени? Килешмәгәнне! — дип кистереп кенә салды.

Мин хат язасы кәгаземне китап өстенә куеп, шул хат язган өчен биргән биш тиенлекләргә Казанның үзеннән алдырган көмеш саплы каләмемне кулыма тотып язарга җыендым. Сәҗидә җиңги сапны якка салам кыстырудан башлады:

— Хатны мин үзем дә яза беләм дә болай. Тик сине бик тә җирәнә җиткереп яза дип ишеттем. — Ул миңа иренең хатын биргәндә тагын

бер озын кәгазь күрсәтте. — Аннары Нәбиулла абыең бу юлы никтер зерә дә моңлы хат язган. Әллә күңеле берәр нәрсә сизә инде моның, әллә болай гына. Бик кызганыч көйле нәрсәләр дә җибәргән.

Анысы солдатларның окопта чыгарган бәетләре икән. Сажидә җиңги, мина җаны белән борылып, аның бер-ике юлын укып та бирде:

— Тыңлап кына кара әле син. Ходаем, шул тикле дә кызганыч:

Курмидер синең күзең,
Каплый мылтык төтене;
Туп ярылгач, яннарында
Калмый кешенең бөтене.

Кайсысының кулы юк,
Кайсы ята аяксыз,
Монда кеше меңләп кырыла
Үлем безгә аяусыз.

— Җитмәсә тагын германнар газ җибәрә башлаганнар. Безнекеләр шуңа тыннары буылып күп үләләр икән...

Сажидә җиңги, борынын тарткалап, почмак якка кереп китте.

Шунда бәеттә язылган әлеге коточкыч хәл күз алдына килеп тетрәнеп киттем. Кибәхуҗадагы шушылай ук ялгыз калган үз апам, тау асты җиңги, авылга килгән кара пичәтле язулар искә төште. Кем белә соң? Менә бу хат та ул исән чагында әллә барып җитә, әллә юк...

Өйдә тып-тын. Почмак якта ишетелер-ишетелмәс моңсу гына бер көйгә самовар шаулап утыра. Ара-тирә урамнан я бозау кычкырган, я тавыклар кытаклаган тавыш ишетелеп куя.

Башта чукдин-чук, күпдин-күп сәламнәр тезелеп китте. Аннан соң йорт-җирнең иминлеге, мал-туарның саулыгы язылды. Арчага кайтып тулган сугыш качаклары, алпавытка җибәрелгән пленниләр дә телгә алынды.

Әмма тора-бара минем каләмем ничектер үзеннән-үзе, бер генә сүз дә өстәмичә, арттырмыйча, киметмичә Сажидә җиңги сүзләрен тезеп бара башлады. Ул кечкенә як ишегендәге чаршау кырыеннан, моңсу күзләрен мөлдерәтеп, миңа түгел, минем алдагы кәгазьгә текәлгән, иренә барып җитәчәк газиз сүзләрен шыпыртка якын акрын тавыш белән миңа түгел, ак кәгазьгә сөйли иде.

— ... Гөрләшеп кенә гомер итә башлаган чагында сак белән сок шикелле безне дә аердылар. Бер күрергә җан атып, монда мин ут йотам, анда ул — әллә кайлардагы чит-ят җирләрдә. Өченче елга китте бит инде! Ничекләр түзмәк кирәк? Көне ай күк, ае ел күк, елы бер кеше гомере. Өзелеп-өзелеп күрәселәрем, сүзләрен ишетәселәрем килә. Хаты килгән көннәрне куанычыннан күзләремне йокы алмый, төннәр буе керфек какмыйча якты таңнар аттырам. И ходаем! Кавышулар насыйп булырмы икән? Тагын шулай бергә-бергә торып калырбызмы икән? Бу каһәр төшкән сугышлары безнең бәхетебезне дә харап итмәгәеме икән?!

Мин аларның егет белән кыз чакларын, яшьләр уенында, балалар сыман бер-берсенең кулларыннан тотышып озак-озак серләшеп йөрүләрен хәтерлим. Өйләнешкәч, шаярыша-көлешә янәшә торып урак урулары, печән җыюлары, җомга көннәрне киенеп-ясанып, яшьлекләре белән бөтен урамны балкытып, Сажидә җиңгинең чыккан йортына кичке чәйгә барулары әле дә күз алдында.

Үзем дә сизмәстән, ничектер, Сажидә җиңгигә күз салдым. Аның хәзер ирен кырыйларына эчкә йотылган авыр хәсрәтнең караңгы бизәге җыелып тора, бит алмалары да элекке шикелле алсу түгел, йөзе дә шиңгән, саргая төшкән төсле. Шулай да кемнең теле барыр икән аны сулган, шиңгән дияргә? Юк, юк! Аның күзләре, ерактагы, әллә кайдагы бәхетен хәзер үк күз алдына китергәндәй, үз алдына очкынланып тора, йөзендә моңсу бер матурлык балкый.

Минем Сәҗидә җиңгине шул тикле бәхетле итәсем килде, чын күңелдән кайгыртып:

— Син, җиңги, бик нимә... — дидем. — Сугышны озакламый туктый дип язалар бит. Кайта безнең абыйлар, билләһи кайта, менә әйткән иде диярсең!

Җиңгәм яшанырга да, ышанмаска да белмичәрәк елмаеп куйды.

— Шулай дисеңме? Нинәр генә әйтер идең дә бит! — Аннары, нидер исенә төшеп, янадан ачылып китте. — Әле узган атна кич кенә бик тә матур, бик тә өметле итеп төшемә дә керде югыйсә. Үзе белән икәү янәшә утырып болынга төшкәнбез икән, дим. Ул янымда булгач, миңа шултикле дә рәхәт, шундый да күңелле икән, дим. Уянып киткәч өнем булмаганга җылыйсыларым килде. Төяп менгән йөгебез дә бик зур икән, дим, хәвеф-хәтәрсез аударымыенча гына кайтып та життек. Дөньялар тынычлануга, хәере белән исән-сау әйләнеп кайтуга булсын инде... Менә, Гомәр энем, килмәгән җирләрен китереп, сүзләргә сүзләр тезеп, җаен җайга сөреп кенә шуларны яз инде алай булгачын-нан...

«Сүзләргә сүзләр тезә» торгач, минем хатым ике-өч кәгазь ук булып китте.

Бу йорттан чыкканда миңа болын буендагы әрәмәлектә сандугачлар сайравын тыңлагандагы кебек ук бераз моңсу да, шул ук вакытта рәхәт тә иде.

## VI

Вәли абыйны күптән ук көтә башлаган булсак та, ул һич көтмәгәндә кайтып керде.

Шул көнне иртәнге чәйне эчеп утырганда, безгә тау асты җиңги менгән иде. Бу вакытта эти җылытудан гаҗиз калып, аякларын кайнар самоварга терәгән хәлдә сәке түрендә утыра иде. Ул, килене менүгә куанып, идәнгә төште.

— Әйдүк, килен, әйдүк! Балалар ничек? Исән-саулармы?

Җиңги, этидән тел яшергәнлектән, әйтәсе сүзен почмак якка чыгып әни колагына пышылдарга тотынды. Тик ул куанычлы хәбәр алып менмәгән икән. Староста белән дисәтник кергәннәр. Ике сарыгының берсен, я кәҗәсен казнага сорыйлар икән. Балаларның аякларына итеге, кулларына бияләе тузган. Берсен алсалар, ул бер сарык белән генә нишләрсең? Кәҗәне бирсәң, балалар сөтсез кала. Эткәй шуңа нинди киңәш бирә дип менгән икән.

Авызын каплый төшеп, аңа яңы беләнрәк почмак якта торучы җиңгигә карар-карамас эти:

— Ун йорттан бер сыер биргәндә килен өлеш кертте бугай? — дип сорады.

Керткән икән, акчалата биргән.

— Әле күптән түгел тагын бер тапкыр җиде йорттан бер сыер бирдек. Анысы ничек?

Анысына сарыгын сатып түләгән.

— Җитәр, балалар хакына керергә ярамас, — диде эти. — Әле дә кара җаяу калып барабыз. Ул нинди закун? Солдатны да без бир, бөтен чирүен дә без туйдыр, атың белән әллә кайларга тикле олауларга да йөр. Биргәне җиткән! Әнә анда, Вәли мескен, сарык кына түгел, кулын да...

Эти сүзен әйтеп бетерә алмыйча, күңеле тулып, верстагына борылды. Аның кинәт ничектер бик кызганыч булып калуын, күз яшьләрен тыя алмыйча күзен чылт-чылт йомуын күреп торуы бик авыр иде.

Әни аңа мич башыннан киез итеген алып бирде, песи баласын иркәләгәндәй, өстен сыпыргалап, алдына җылы оекбашын китереп куйды.

— И, алай дигән белән дә Вәлинең исән-сау кайтуы бик тә зур куаныч әле ул, — диде. Кара пичәтле кәҗүнни язулар алсаң, нихәлләр генә итәр идең? Андыйлар да аз түгел бит. Инде болай булганга мең шөкер!

Әти үзенең әле генә күренеп алган йомшаклыгы өчен хәзер үзенә-үзе ачулана, хатын-кыз юатыр көнгә калуына үртәнә иде шикелле.

— Шул гына җитмәгән! — диде. Шак та шок рам почмакларын беркетеп маташты. Бераздан, почмак якка борылыр-борылмас, кисәтеп куйды. — Бернәрсә бирәсе булма, сыңар тавык та!

Өйалдына чыккач, җинги ишеккә сөялеп җылап җибәрде.

— Агач аяклы, сыңар куллы кешеләр күргән саен имәнеп китәм. Ходаем, ничек көн итәрбез? Сыңар кул белән ничек эшләр? Ничек ат җигәр дә ничек иттереп печән чабар? Чулак бит инде ул, чулак!..

Мин абыйны берничек тә гарип итеп күз алдына китерә алмый идем. Баларак чагымда мин аның урам сугышында үзе шикеле баһадир гәүдәле дүрт-биш кешегә берүзе каршы чыгып, җиңеп кайтуын хәтерлим.

Бу башсызлыгы өчен әти аны «олы тиле» дип орышкан иде. Әмма шул ук вакытта аның шушы кыюлыгын хуплап әтинең мыек астыннан елмаюы да күзгә чалынып калды.

Бөтен ишекне тутырып зур булып килеп керүенә ин элек абыйның көяз калын мыекларына, шул мыек астыннан ялтырап күренгән ап-ак тешләренә күз төшерде. Аннары әтинең шушы мыеклы олы кешегә, кечкенәләргә дәшкәндәй иркәләп, әллә ничек, йөрәкләргә үткәреп: «Улым!» дип дәшүе, шунда абыйның бер генә сулышка ирен кырыйлары бозылып куюы күзгә яшь китерде. Әни үзенең ике кулына каршы абыйның бер генә кул сузуына әллә онытып, әллә каушавыннан аптырап калды. Аннары, уң кул урынына кара пирчәткә кигән җансыз нәрсә асылынып торуын күреп, җылап җибәрде.

— Я, раббым! Кайсы каһәр сукканнары шулай харап итте!

Моңа каршы Вәли абыйның тагын ак тешләре күренеп китте.

— Ә, урыс арасында озак йөргәнлектән, хәзер менә шулай, аларча гына күрешә торган иттем инде, — диде.

Минем үземә хәзерге абый элеккесенә караганда да ошыйрак төште. Ник дисәң, сугышка киткәнче ул бик кырыс холыклы, усал телле иде. Бәлки яшь хатын малае булгангадыр, берәр нәрсә ошамаса, «Әй, малай!» дип кенә кычкырыр иде, кая ул исемең белән дәшү! Сугыштан бераз ачылыбрак кайткан димме, йомшабрак димме. Әни белән җинги аның гарип кулына күз салгалап пышык-пышык җылап утыралар, ә аның өчен, әйтерсең, бер кәмит кенә. Күн пирчәткәле җансыз кулы белән дөп иттереп верстакка сукты да хәтта шаярырга тотынды.

— Нигә шул тикле исегез китте ана? — диде. — Мин үзем шылт та итмим. Беләсегез килсә, болай җиллерәк тә әле. Печән чаба, урак ура, балта тотарга да өйрәнмәсе бар. Тагын сезгә ни кирәк? Шуның өстенә, суыкта туңмый, эсседә пешми, авыртмый, сызламый. Менә бу искесен никадәр шәп булса да яңадан ясап булмый бит, ә менә бусысын, ватылса яңадан да эшләп бирербез, диделәр.

Мин абыйга якынрак барып утырдым. Бөтен эшне булдыра ала торган шундый үнган кулга бармак тидереп карыйсы килә башлады. Тән шикелле җылымы икән? Бармаклары бөгелеп язылamы икән?..

Әни, әстәгъфирулласын әйтеп, абыйның үзенә, аннары яңа кулына карап башын чайкады.

— Тфү, тфү, үлмәсәң, әллә ниләр ишетерсең! Ялган дисәң, чын шикеле. Хак сүз дисәң, ышаныр җире юк.

Күрше-күлән, туган-тумача җыелып сугыш хәлләрен сораштырып утырганда да абый гел шулай шаярткалап алды. Әйтерсең, елдан артык окопта үлем күтеп ятмаган, кулсыз калмаган!

— Ашау-эчү ничек дисезме? Шәп! Иртә дә, кич тә тозлы кәбестә белән сасы балык шулпасы. Ипинең дә бик тазасын бирәләр. Балта белән ватып ашыйсың.

Инде окопның үзеннән кайткан икән, минем абыйдан сугышның иң хәтәр, иң куркыныч мажаралары, аның үзенең ничә немецны үтерүе турында ишетәсем килә башлады. Шунда келт итеп күптән түгел генә Арчаның Лавәнти кибетендә күргән Кузьма Крючков сурәте күз алдына килде. Инде дә башсыз казак икән! Ничек кенә кырмый ул немецны! Берсен кадап, берсен чәнчеп, берсен атып үтерә. Сурәт астында шулай язылган. Менә бит нинди батырлар да бар икән сугышта!

Мин шул турыда сүз ачуга, абый мыек астыннан гына елмаеп куйды.

— Әле ул монда да сасытып өлгердемени? — диде, тагын нидер әйтмәкче иде, Зифа тәтәй, күзен ачалак-йомалак китереп, бәтләр хакында сорарга тотынды.

— Менә тагын, сугыш бетсез буламыни? — диде абый. — Россия булсын да, бетләми калсын!

Өйдәге халык солдатның һәр сүзен йотып алырдай булып, тынназрын да алмыйча тыңлыйлар. Алар бит аннан искә төшкән саен тәнгә салкын су булып коела, ачык яра булып сызлап тора торган иң-иң авыр сорауга җавап көтәләр. Ул бит сугышның эченнән, Газраилнең үлем чалгысы астыннан, үлем авызыннан ычкынып кайткан. Ул һәммәсен белергә тиеш, һәммәсен!

Тик солдат абый, бөтенесен бәйнә-бәйнә сөйләп бирәсе урында, үзе авыл хәлләрен сораштырырга тотынды.

Әти солдат улының сугыш хәлләрен сөйләмәвен ошатмаган сыман, теләр-теләмәс кенә:

— Монда нәрсә булсын? Күз алдында ич! — диде. — Тәндә чыкмаган җан бар. Менә шул! Чын ипине хәллерәкләр генә ашый. Онга бәрәңге кушабыз. Элек ярлы кешенең сые турында: «Якты чырай — такта чәй», ди торганнар иде. Һи! Кая ул! Такта чәй зур сый булган икән. Хәзер кишер чәе эчәргә калдык.

Зифа тәтәй алъяпкыч итәген бөгәрләп:

— Я черегән алма яфрагы! — дип өстәде. — Бүтәнне ни әйтәсең, мәет күмәргә кәфенлек тә таба алмыйлар.

Мөхәммәтҗан солдат, әтигә карый-карый:

— Менә патша да патша дидер идегез. Җомга саен, муллага ияреп, патша әгъзәм хәзрәтләренә озын гомер теләп дога кыла башлаган идегез. Курсәттеме үзен патша әгъзәмегез? — диде.

— Авыл мужигы арбага таккан дегет лагоны, — диде әти. — Мулла ни әйтсә, шул дөрес.

Вәли абый пошынып телен чартлатты.

— Урамда ник бер генә ир заты очрасын! Беткән икән авыл!

— Бетмичә, чабаталыга[1] хәтле алдылар!

— Кая чабаталы гына? Ак билетне[2] дә чүпләп бетерәләр инде. Аягы-кулы булса, шул ярый.

Сарник абзый, тыңкыш борынын тарткалап:

— Җыен дурак китә инде шул, — диде. — Акыллыраклар рәхәтләнеп хатыннары янында яталар.

Мөхәммәтҗан солдат таягын тукылдатты.

— Шуны егетлек дисеңме? Шкурник ул, куркак, дезертир!

Абый да андыйларны ошатмыйча башын селекте.

— Алайга калгач, эш түгел инде ул! — диде. — Юк, сугыштан алай гына котылып булмый.

[1] Чабаталы — солдат хезмәтенә алынмыйча запаска калучы

[2] Ак билет — солдат хезмәтенә яраксыз.

Ләкин ничек котылып була икәнлеген әйтмәде.

Тагын берничә көннән тегермәнгә барганда Вәли абый старостаны туктатып аягүрә генә сөйләшеп алды.

— Солдаткалардан тагын да мал-туар ала башласагыз, безгә әчелешле булырга туры килер бит, — диде.

— Соң казна бит, казна бугаздан буа!

— Ә син хатын-кыз бугазына ябышасыңмы?

— Закон бит, закон бар бит әле. Ә без закон кешесе.

— Хәзер закон солдатның үз кесәсендә. Чыгарып «шарт» итте, менә сиңа закон. Сөйләштекме? Килештекме?

Староста солдатның бер кара пирчәткәле кулына, бер мыек астыннан елмаеп торган ап-ак тешләренә текәлеп, баскан урыныннан кузгала алмыйча калды.

## VII

Безнең йортны авыр кайгы басты. Җәй башында әтине җирләдек.

Мәет чыккан йорт... Һәр почмактан шомлы ялгызлык, күңел өшеткеч бушлык бәреп тора. Өйгә кайтып керүеңә, ничектер үзеннән-үзе күзләрең түргә карыйлар. Анда әти, верстагындагы эшен туктатып, хәл жыеп ятадыр шикелле. Шунда ук китек күңел үкенә дә башлый. Нигә шулкадәр авыру килеш тыны буыла-буыла эшләде икән? Ул әнә шунда, түрдә өйрәтеп кенә утырсын иде...

Иртә белән уянып китүеңә ишек янындагы чөйдә эленеп торган бишмәтенә күзең төшә дә тагын эчең «жу» итеп китә. Юк бит инде әти, юк, бөтенләйгә, мәңгегә юк.

Мәет чыккан йорт... Хәзер әтәчләр дә элекке кебек шатланып кычкырмыйлар, тавыклар да бөтен ишек алдын тутырып жырлап йөрми. Кичләрен безнең турыдан узганда егетләр жырлавыннан, гармунчы гармун тартуыннан туктый, иһаһайлап кычкырып көлгән кешеләр шыпырт кына узалар.

Һәр көн иртә белән бик иртә, кояш чыкмас борын ук, без бия белән каты сукага китәбез. Һәр көнне тавышсыз-тынсыз гына әти каберенә карап үтәбез. Аның кабере зиратның иң калку урынында. Безнең басуга һәммә кешедән дә иртәрәк чыгуыбызны әти ничек тә булса белеп каладыр кебек. Беләме ул, әллә белмиме, ничек кенә булмасын, миңа аның янынннан узу, күңелдә шундый жылы уй йөртү үзенә күрә бер юаныч иде.

Бер көнне көндезге чәйгә кайткач, атның ашарына салып йөргәндә, сәлам-фәлән бирмичә, ишек алдына Бикбулат килеп керде. Күтәрелеп карар-карамас:

— Нихәл? — диде.

Мин авыз эченнән нидер мыгырданып кынауздырдым. Әнә мине малайсытып сәлам бирмәсен дә, ди. Шулай да яхшымы, яманмы, минем исемем бар бит!

Бикбулат аны-моны әйтмәстән, койма буенда гына торган бер төрәнле тимер сабан янына китте. Шунда ук минем исемә дә төште: мөгаен, алачагын сорарга килгәндер! Шулай булып чыкты да. Бикбулат сабанны арлы-бирле тәгәрәтеп тә, нигәдер чылтыр-чылтыр селкетеп тә карады.

— Сабаннан үндыгызмы соң? — диде.

— Үз эшенә ярый. Ат тартса сабан сукалый.

— Атаң, мәрхүм, хакын түләп бетермәде бит. Кайчан бирәсең?

— Бу арада аның кайгысы булмады бит, Бикбулат абзый, үзеңнең күз алдында.

— Озак бит, былтырдан бирле сөйрәлеп йөри.

Бикбулат, уң кулының баш бармагын кәмит кенә тырпайтып, сакал астын кашырга тотынды.Ул түбәсенең яртысы кабык белән ябыл-

ган, аскы каты яртылаш җиргә иңеп, арт ягын, койрыксыз тавык кебек, урамга таба турсайтып торган шыксыз өйгә, сәлам түбәле каралтыларга карап уйланып торды да тагын сорап куйды:

— Кызыл кар яугач дисеңмени?

Бу кешенең шундый кайгылы көннәрдә биш сум бирәчәк өчен шушылай бугазга ябышуы җенемне чыгарды.

— Тулим дим бит инде.

— Кайчан? Ничек итеп?

Әни үзеннән олы ирләрдән тел яшерә иде. Мине өй алдына чакырып алды.

— Алып китсә, нихәл итәрбез? — диде. — Каты сука бетмәгән, күзгә чәчүеңне ничек чәчәрсең? Бар, әйт: «Ничек тә булса, түләрбез я ашлыгыңны урып бирербез», диген. Бар инде! Ник торасың киреләнеп?

Минем чыннан да кирелегем килә башлаган иде. Әни сүзләрен әйтергә телем бармады. Староста самоварны алырга кергәндә әти ничек басып торган булса, шул кыяфәттә, кулларымны аркама куеп, сабан янына барып бастым.

Бикбулат сабанның тоткасыннан килеп тотты. Ул әнинең ниләр әйтүен ишетеп торган булса кирәк, сүз көтеп минем күзләремә текәлде.

— Әйт, яшь этәч! Синнән нинди кикрикүк чыгар икән?

Минем бик усал сүзләр әйтәсем, әти старостаның авызын томалагандай, моның да бер-ике сүз белән сынын катырасым килде. Ләкин андый сүзләрне таба алмыйча гаҗиз калып җылыйсым килә башлады. Ниндидер явыз шатлык белән ярсып капкага таба киттем.

— Алып кит!

Минем шулкадәр каным каткан иде, сабансыз калсак та, тешне кысып булса да түзәргә, бер генә сүз белән дә ялынмаска, хәтта борылып та карамаска булдым.

Мин тыкрыкка борылганда, безнең капка төбендә чылтыраган тавыш ишетелде. Күз кырыем белән генә карасам, Бикбулат, сабанны сөйрәп чыкса да, тибеп аударган да сүгенеп китеп бара иде.

Билгеле, әти әйткәнчә, кеше хакы безнең өстә калмады. Мин ул бурычны, озак көттермичә, пыяла куеп түләдем.

## Җир, хөррият!

### I

Югары очтан кайтып барганда Сәлимәләр ишек алдыннан көшкелләнеп кенә кызлар тамак кырганы ишетелде. Минем йөрәк дуылдап алды, авызым колакка кадәр ерылып китте. Тәгаен, миңа иде бу, миңа! Әллә туктарга, әллә юк. Әнисе өйдә булса!

Шулай икеләнеп барган өстеннән җилкәмә бер йомарлам кар килеп төште. Икеләнеп баруым өчен үземне-үзем шелтәләп ташладым. Безнең яшьтәгеләрне ул елларда телдәр солдаткалар «көзге этәчләр» дип, «кикрикләре кызарып килә» дип үрти башлаганнар иде. Минем яшьтәшләрем, бигрәк тә Ахун белән Минзай шикелле үсмер егет булып килүче зурраклар, кайчакны үзләренең кызлар белән булган маҗаралары турында шундый нәрсәләр сөйлиләр, мин моңа ышанмыйча, кызларның абруен яклап сугышырга җитәм. Ә ул юньсезләр тешләрен ыржайтып көләләр генә. Үзем этәчләнәм, әмма күңел төбендә кыбырсып торган шикне берничек тә бастыра алмыйм: болар янында мин бөтен нәрсә китапта язылганча бик тәти, бик дөрес кенә була дип алданып йөрүче сабый түгелме соң?

Бу юлы мин үземне-үзем батырландырырга тырыштым. «Җитте сиңа! Булма юаш, булма сабый!» дип капкадан кереп киттем.

Сәлимә белән аларга туган тиешле Сәхипҗамал киледә сүс тәяләр икән. Сәхипҗамал миңа да бер килсап тоттырды.

— Әйдә, писер булып гел язулар гына язып йөрмә әле, менә безнең белән әзрәк селкенгәләп тә ал, — диде.

Сәлимә миңа шундый ягымлы, шундый үз итеп карады, шуның рәхәтеннән минем хәтта сулышым буыла язды, башым әйләнеп киткәндәй булды. Мин аның яз кояшында конгырт төс ина башлаган сөйкемле йөзеннән күземне ала алмыйча, сихерләнеп калдым. Сәлимә оялчанланып башын иде, аннары миндәге килсапка сузылды.

— Әем лә, Сәхипҗамал апай. Кунак егеткә эш кушмыйлар инде, — диде. Бу сүзләрне ул шундый ихлас күңелдән, шундый иркәләп әйтте, мин, мөгаен, кызарганмын.

Сәхипҗамал шаккатып авызын ачты.

— Әнекәй генәм! Кара әле син моны! — дип башын чайкарга тотынды. — Син нәрсә? Гумәреңнең кулы кабарыр дисеңме? Ай, һай, һай! Харап икән бу заманның яшь әтәче белән яшь тавыклары!

Яшьлекнең бу исерткеч тойгысыннан бәлки без тиз генә айный да алмаган булыр идек, безне шул ук Сәхипҗамал уятты.

— Әллә бер-берегезне күрүгә һушыгыз китеп, телегезне йоттыгыз инде! — дип шаркылдап көлде дә икебезне ике якка төртеп җибәрде. — Я, егет кыйпылчыгы, әйт тизрәк! Кайларда булдың? Нәмәрсәләр ишеттең? Сугыш бетәме? Миңа дигән кияү кайчан кайта? Гәҗит укыйсың икән, диләр. Я, тизрәк бул!

Һи, ялындырып торыр чакмы соң? Бигрәк тә Сәлимә барында, бигрәк тә ул мине күзләренең нуры белән коендырып торганда. Киттем сөйләп!

Нинди генә тамашалар юк хәзер дөньяда! Сугыш җирендә пулә тишми, туплар алмый торган ут машиналары эшли башлаган. Алар, Яэҗүҗ-мәэҗүҗ шикелле, бөтен тирә-ягын җимереп, яндырып, кырып килә, ди. Шуның өстенә, куктә аэроплан оча икән.

— И аллам, кырып бетермәсәләр ярый инде безнекеләрне.

— Тик яңалыкның иң зурысы, иң кызыгы беләсезме нинди? Патша сараеннан чыкканы. Николайның Себердән килгән бер әшнәсе бар икән...

— Теге элек ат карагымы, попмы булган озын чәчлеме?

— Нәкъ үзе! Менә шуны Йосыф дигән бер кенәз алтатардан атып еккан да бәкедән боз астына тондырган.

Сәхипҗамалның күзләре шакмак булды, ул чытырдатып минем иңбашыма ябышты.

— Китсәнә аннан, чынмы? Тфү, тфү! Акка кара белән шулай дип язганмы?

Без кызып сөйләшкәндә Сәлимә сагаеп нидер тыңлый башлаган иде. Урамда ниндидер сәер тавышлар ишетелеп, һәммәбез дә капка төбенә атылдык.

II

Чыксак, урамда — мәхшәр! Түбән очтан урам тутырып әллә никадәр халык менеп килә. Бөтенесе, давыл вакытындагы урман шикелле, айкала да чайкала. Берәүләре кулларын болгый, кайберләре нидер кычкыра.

Иң алдан, скрипкәсен уйнап, керәшен ягының Кирүш менә. Безгә якынайган саен скрипкә сыздыруы да, бүтән тавышлар да ачыграк ишетелә башлады. Менә Кирүш, керәшен туендагы кебек, үзе уйнап, үзе биеп, бер карга батып, яңадан юлга чыгып, кырын-кырын сикергәләп килде-килде дә, скрипкәсен баш очында айкап, ачы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Микулайны бәргәннәр! Дөмектергәннәр! Әйттер-сиптер, юк патша!

Урамның ике ягыннан шыгырдап та, чылтырап та капкалар ачылды. Яшь-җилбәзәк көлмәкчән килеш кенә йөгерешеп урамга ташланды.

Скрипкәче ике-өч йорт узганчы яңадан шулай уйный-бии сикергәләп барды да скрипкәсен айкап тагын җан-фәрманга аваз салды.

— Патшаны төшергәннәр! Кайта, алла боерса, Анныем! Бетте ак патша, юк патша, кәнис!

Мөхәммәтҗан солдат кызыл чуар итеген киеп, тунын җилбәләй җибәргән. Ул халык өстеннән калкып чыккан озын муенын күккә сузып Кирушка йодрык янады.

— Менә тондырырмын берне авызыңа! Нинди ак булсын ул сиңа? Кара йөрәк, кара бит! Мәтәлде-төште кара йөз, анасының арт саны! Слабода чыкты Рәсәйгә, слобода, хөррият! Ишетәсезме?!!

Тагын кемнәрдер бөтен урамга кычкырды.

— Бетте сәмәрәү кош! Муенын борып аттылар!

Оялчанрак солдаткалар бер-берсенең капка төпләренә җыйналышып, куанычларын уртаклашырга тотындылар. Алар йомшап киткән борыннарын тарткалыйлар, яулык почмаклары, алъяпкыч итәкләре белән күз яшьләрен сөрткәлиләр иде.

— Һай, шул слобода дигәне тизрәк сугышны бетерсәче!

— Яхшыга гына булсачы!

— Болай булгачыннан солдатлар да кайта диләрме соң, ничек диләр?

— Ник бетмәсен? Бетә сугыш! Патша төшкәч, аның янараллары да төшә бит инде. Янаралсыз ничек сугышсыннар?

Кайберәүләр ышанырга да, ышанмаска да белмичә аптырап торалар да, бәладән башаяк дигәндәй, бүрекләрен басып, өйләренә кереп китәләр.

Керәшен ягыннан, башын тавык шикелле бер якка кыңгырайтып, Бикә түти килеп менде. Патша төшү хәбәрен ишетүгә, аның кулы ничектер үзеннән-үзе җитез уйнаклап чебен куарга[1] кереште. Ләкин әллә бу як кешеләре бик текәлеп һәм нигәдер көлемсерәп карап торганга, кыенсынып, әллә бу яңалыкны яхшыга юрарга мы, әллә начаргамы икәнлеген аныкларга өлгермәгәнлектәнме, кулы ярты юлда асылынып калды. Ул, куркынып, сыңар күзе белән Кирушка текәлде.

— И аллакайларым, әллә башым түнгән, әллә замана акыры җиткән, һич нәстә аңнамыйм. Патшасыз ничек булсын инде? Күктә — алла, җирдә — патша. Әнә бит көтүгә дә көтүче кирәк. Ансыз буламыни?!.

Сәхипҗамал аны шаяртып алды.

— Синең әле дә бер үзеңә ике аллаң бар бит, Бикәби. Шулар җитмәгәнмени?

Бикә түти моңа бик ачуланды.

— Бер дә айгыр булып кешнисе түгел югыйсә, — диде. — Башында тавык мие булмаса, аңнарга бакыт. Олы эшләр турында сүз бара, патшалар турысында.

Ул арада халык ташкыны югары очка менеп киткән иде инде. Бераздан скрипкә тавышы аргы яктан ишетелә башлады, аннары түбән очка килеп төште. Көннен-көн буе авыл гөрләп торды. Сугыш башланганнан бирле беренче мәртәбә кешеләрнең чырайлары ярылып, телләре ачыла башлады.

Шуннан соң каравыл өеннән халык өзелми торган булып китте. Анда иртәдән алып кичкә кадәр яңалыклар сөйлиләр, старостаның Ар-

[1] Чебен куу — чукыну.

чадан ниндидер үзгәрешләр, жинелләкләр турында хәбәр алып кайтуын көтәләр.

Әмма көн артыннан көн, ай артыннан ай уза, берни үзгәрми, кара пичәтле кәгазьләр килүдән туктамый, мал-туар белән ашлыкны һаман алып кына торалар иде.

Яз көне чәчүгә чыгар алдыннан жәмәгать жыеннары көннәр буена сузыла башлады. Сугыштан яраланып кайтучылар белән ярлы-ябагай жыен саен тавыш күтәрә иде.

— Сугыш бетә диделәр, бетмәде, солдатлар кайтмады. Жан башыннан жир бүленә диделәр, бүленмәде. Ни пычагыма безгә андый слабода? Жир кирәк безгә, жир!

Тавыш бик зурая киткәндә жәмәгать жыенында Бикбулат та сүз әйтә торган иде.

— Соң, рәхмәт төшкән нәрсәләр, сезгә тагын ни житми? — диде. — Тагын нинди слабода кирәк? Көне-төне шаулыйсыз, минем тәрәзәм каршысына килеп, тамагыгыз ертылганчы влачны сүгәсез. Менә шул инде сезгә слобода!

Мәдьяр солдат белән Вәли абый ана икесе ике яктан ташланып, элеп алып, селкеп салалар.

— Нәрсә син монда тегеләй дә болай койрык болгыйсың?

— Ярый ла синең ике малаеңның берсе сугышта кан түкми, Шубиннарның[1] тунын бөркәнеп шыпырт кына посып яталар.

— Иске кибәннәреңне дә әле быел гына суктырдың. Ашарына беткәннәргә нишләргә? Солдат балаларын ничек туйдырырга?

— Жирне жан башыннан бүләргә кирәк!

— Хәзер чәчеп калдырмасак, каян өмет итәбез?

Олы гәүдәле бу кеше, баш бармагын кәмит кенә кәкрәйтеп, тыныч кына сакал астын кашый бирә.

— Менә син, Вәли, — ди ул. — Сугышта да йөреп кайттың. Язусызуга да кешегә чыкмыйсың. Беләсең бит, закунсыз бер карыш атлый алмыйсың! Малымы шту сиңа жир кирәк! Менә минем теге Березовканың юан сыйраклы Марусәгә бик күзем кызып йөри дә соң, бирми бит Әүдәким, үзем кочаклыйм, ди.

### III

Хәзер инде Арча базарына да әйбер алырга дип түгел, эчтә кайнап торган ризасызлык белән борчуга жавап табарга, арбага менеп сөйләүчеләрне тыңлап, дөньяданиләр барын, жилләрнең кайсы яктан исүен белеп кайтырга дип баралар иде.

Хәер, алыйм дисәң, анын әйбере дә юк, сугышка кадәрге гөрләп торган базарлар хәзер төшкә дә керми инде. Кибетләр күбесенчә буш була, сирәк-мирәк әйбер чыкканда да акча житә торган түгел. Терлек базарында аягына чак кына басып бер-ике корчаңгы ат, берәр сыер белән өч-дүрт баш сарык, я кәжә сөмсере коелып мәлжерәп тора. Бер-ике урында чабата белән мунчала, себерке белән сүс өемнәре күзгә чалына. Бөтен базары менә шул.

Төрле яклардан жыелган картузлы һәм түбәтәйле бабайлар кая барырга, нишләргә икәнен белмичә, арлы да бирле сугыла, кибет төпләрендә, урам чатларында төркем-төркем булып сөйләшеп торучыларга колак салгалый, тагын кузгалып китә, тагын туктый.

Менә базар уртасында берәү арбага менеп баса да кычкыра-кычкыра нидер сөйләргә тотына. Шуны гына көтеп торгандай, һәммәсе шул тирәгә ябырылалар.

Көзгә таба сөйләүчеләр базар саен күбәя генә барды. Берсе сөйләп бетерүгә, арбага икенчесе менеп баса. Анысы я сөйләп бетерә, я аны

---

[1] Шубин — патша армиясена тун тектереп торучы фабрикант.

сөйрәп төшерәләр дә бүтәннәре сөйләргә тотына. Арбадан халык өстенә анархист, монархист, большевик, меньшевик, эсэр, эс-дек, хөррият дигән яңа, сәер сүзләр сибелә башлый. Сөйләүчеләрнең һәркайсының үз сүзе, үз иманы бар, һәрберсе авызын ачып тыңлап торган агайларны үз ягына аударырга чамалый.

Хәкимҗан белән без дә бөтен иске дөньяны сүгеп, эшче-крестьянны яратып сөйләүче, җирне хәзер үк җан башыннан бүләргә өндәүчеләр тирәсенә туктый идек.

Кайвакыт ул сөйләүчеләр бер-берсе белән якага яка килеп ызгышып та алалар. Әмма күбесе менеп басканнан төшкәнче яңа хөкүмәтне мактап сөйли. Аларча, бөтенесенә Николай патша гаепле. Шул харап иткән Рәсәйне. Сугышта да шул җиңдерткән, халыкны да шул йөзе кара ач-ялангач калдырган. Аның каравы, менә хәзерге хөкүмәт бөтенләй башка икән инде. Кая ул! Җир белән күк арасы! Яна хөкүмәт зерә дә башлы икән. Монысы инде немецны да себереп түгәсе, халыкның да тамагын туйдырасы, өстен дә бөтенәйтәсе. Агайларга тик нишләргә генә кирәк? Большевиклар коткысына ышанмаска, хөкүмәт ни әйтә, шуны гына тыңларга кирәк...

Менә арбага кара җиләненең чабуларын җыештырып, күкрәгенә дәү көмеш тәре аскан зур сакаллы поп менеп басты. Халык арасында шау-шу купты. Кайсыдыр бер агай, ачуын баса алмыйча, хатын-кыз тавышы белән чырайлап кычкырды.

— Нәрсә житмәгән тагын ул яллы бүрегә? Әнә, чиркәвендә лыкылдасын!

Ләкин поп сөйли башлауга һәммәсе тынып калдылар. Батюшка тавышының ягымлы гөрелтесе белән генә түгел, бигрәк тә соңгы елларда өметсезлеккә бирелеп кырысланган, юньле, йомшак сүзләргә сусаган агайларның күңел кылларын чиертә белүе белән алдырды.

— Дөньялар чуалды, ыгы-зыгы, шау-шу купты, — дип башлады поп. — Болар бөтенесе фани, бөтенесе мәгънәсез нәрсәләр. Ә жанны кайгыртучы юк. Рус кешесе ансыз яши аламыни? Православный халыкның патшасыз да булмый. Николаймы ул, Алексеймы, бүтәнме, анысы барыбер, өстә патша утыра икән, аның җаны тыныч! Беләсегез килсә, патшаны безгә алла үзе җибәргән. Әгәр патшаны яңадан тәхеткә утыртмасак, бөтен Россия зир-зебәр тамтарарайга дөмегәчәк...

Тик шунда житкәч, аның янына саргылт сакал-мыеклы бер урыс агай сикереп менде дә кинәт изүен ачты. Өстендәге күлмәген биш бармагы белән умырып алып, шуның сәләмәләрен баш өстендә болгарга тотынды.

— Кем утыра анда, өстә, власть башында? — дип кычкырып җибәрде. — Күрәсезме менә моны? Срам, оят, хурлык! Сугышны туктатмыйлар, халыкның тамагын туйдыра алмыйлар, хәерчегә калдык! Күлыннан эш килмәгәч, какой чорт утыра ул анда, эш башында?! Нәрсәгә кирәк безгә андый власть? Җир кирәк безгә, икмәк кирәк, сугышны бетерергә кирәк!

Мине шаккатырганы шуннан соң арбага менеп баскан кеше булды. Ямаширмәнең теге Гыймай абый иде ул. Тик хәзер аның өстендә иске пальто да, без тегеп биргән бишмәт тә түгел, соры солдат шинеле иде. Ул яшел фуражкасының козерогын, намаз укыгандагы шикелле, артка таба каратып куйды да бик хәтәр татарча сөйләп китте. Кулларын тегеләй дә болай айкый, күзләре елтырап китә, авызыннан утлар чәчә. Бөтенебез авызны ачып шуңа текәлдек. Нәрсә ди? Власть башында утыручы хәзерге хөкүмәт, сугышны бетермибез, немецны җиңгәнчегә кадәр сугышабыз ди. Тик халыкның чыдар хәле бармы соң? Юк, халыкның чыдар әмәле калмады.

— Җитте, туйдык, бугаздан! — ди Гыймай абый. — Бу хөкүмәттән җир булу дә буласы юк, ул сугышны да бетерә алмый, солдатлар да

кайтмый. Бөтенесе ялган, юк сүз, буш сүз! Нишләргә соң, туганнар? Бер нәрсә дә көтмичә, алпавытлардан җирне тартып алырга! Бетерсә, сугышны большевиклар гына бетерә ала. Шулар ук авыл кешесен җирле дә итә ала. Менә кемгә ышанырга кирәк хезмәт иясе кешесенә — большевикларга!

Гыймай куеныннан зур гына газит чыгарып аннан да укып күрсәтте.

— Менә Мулланур иптәш монда нәрсә яза! Ул яза: Байларның көче нәрсәдә? Акчада. Хезмәт иясенең көче нәрсәдә? Бердәмлектә, бер сүздә булучылыкта. Яшәсен бердәмлек, бетсен алпавытлар белән буржуйлар!

Гыймай абый сөйләп бетер-бетермәстә базар халкы, дәррәү килеп, мәйданның югарыгы ягындагы кибетләргә таба йөгерде. Малайлар шундый урынга бармыйча ничек түзсен? Без дә шунда йөгердек.

Барсак, зур гына таш кибет каршысына бик күп халык җыелган. Яулыклары иңнәренә төшеп чәчләре тузгыган, йөзләре кызарынган бик күп марҗа түтиләр, кычкыра-кычкыра, кибетнең яшел ишегенә тибәләр, йодрыклары белән дөң-дөң тәрәзә капкачына сугалар, берсеннән-берсе ачырак, усалрак тавышлар белән төрле сүзләр кычкыралар.

— Хлеб давай!

— Карачин давай!

— Соль давай!

Шул тирәдә зур төркем булып бергәрәк җыелышып торган татар хатын-кызлары да төрлечә аваз салып, аларга куәт биреп торалар.

— Шулай кирәк, шулай!

— Укытыгыз арт сабакларын!

— Сугыш бетә дип алдыйлар гына! Кайчаннан бирле азап чигәбез! Җитте! Туйдык!

— Ирләребезне кайтарсыннар!

— Ашарыбызга бирсеннәр!

Марҗа түтиләр һаман кычкыралар, тибәләр, дөбердәтәләр, ләкин кибет һаман ачылмый, ишек алдыннан берәү дә чыкмый.

Бер агай баскан урынында таптангалап, гүя бу хәлгә куанган сыман, кычкырып җибәрде:

— Һе! Койрыкны бот арасына кыстырдыгызмы, эттән туганнар! Биетербез әле без сезне!

Шул шау-шу астында унлап ир кеше кибет алдындагы ат бәйләгечне каерып алдылар да, шуның башы белән, кычкыра-кычкыра кибет ишегенә төрттерергә тотындылар.

— Раз, два!

— Раз, два, һоп!

Бер китереп төрттергән саен стеналар дерелди, пыялалар чыңлап китә, тимер ишек бөтен урамны яңгыратып шаңгырдый, кибет эчендә нидәрдер чылтырап коела. Ишек алдында үле-мәле килеп этләр өрә башлады, әллә ничә урында берьюлы акырып җыларга, улашырга тотындылар.

Ниһаять, ишек түзә алмады, бирешге. Эчкә таба сытылып керүгә, ир-хатыны, урысы-татары шау-шу килеп, кысылышып кибет эченә ташландылар.

## IV

Безнең ише яшүсмер малайларга нәрсә? Патшаны бәреп төшергәннәр икән — бик шәп! Әнә урәтникләр дә бетте, стражниклар да каядыр олакты. Хәзер инде буржуйлар белән алпавытларга да кул суза башлаганнар икән — тагын да шәбрәк. Болай булгач, иске дөнья бөтенләй җимерелә дә өр-яңасы туа. Ниндиҙрәк буласы икән соң ул яңа-

дөнья? Без ул ягын белмибез. Аңа безнең баш та җитми. Әмма һәр яңа нәрсә искесеннән әйбәтрәк булган кебек, бу яңа дөнья да, безнеңчә, хәзергесеннән юньлерәк булырга тиеш иде.

Әмма олы агайлар Арчада күргән-белгәннәр турында, башларын кашый-кашый, юл буенча уйланып кайталар. Эшләр кайсы якка табарак борылырга чамалый соң әле? Бу сөйләгәннәрнең кайсының сүзе үтемлерәк? Кайсына ышанырга, кайсы бу бәладән йолып алырга сәләтле булыр икән?

Бу айларда авыллар кырмыска оясыдай кайнап торды. Бөтен халык ничектер сагайды. Берәү дә ерак юлга чыкмый. Яраланып ялга кайткан солдатлар, берәр төрле сылтау табып, китмичәрәк тору ягын карый. Өйләнәсе кеше өйләнми, зур эш кузгатмый. Бүген-таңда нидер булыр шикелле. Я сугыш бетәр дә солдатлар кайтып төшәр, я җир өләшерләр, я бүтән шундый еллар буе көттергән берәр куанычлы хәл булып куяр төсле.

Көн саен берәр яңалык туып тора. Я Арчадан берәр хәбәр килә, я казнага мал-туар, ашлык-мазар сорап язу җибәрәләр. Староста каравыл өенә төшеп тегеләй итәсе, болай итәсе дип җикеренеп карый да бит, аның сүзен колакка да элмиләр. Бөтен эшкә хәзер яралы солдатлар белән читтә йөреп күзе ачылып кайткан теллерәк кешеләр баш. Туган бер яңалыкны, килгән бер хәбәрне шулар каравыл өендә төрле иләктән иләп сөземтәсен чыгара торалар, халыкка җиткерә торалар.

Бер көнне староста пичәтле язу күтәреп төшкән.

— Ашлыкның чутын алырга писерләр киләсе, — ди бу. — Штубы бер гөрәнкә ашлыкны яшермәскә, тегендә-монда куймаска!

Иң башта Мәдьяр солдат кычкырып көлде.

— Башларына тай типкәндер ул өстәге түрәләрнең! Быелгы елны язуга кертерлек ашлык бармыни? Әнә, бура төбендә тычканның башы ярылырлык — шәп-шәрә!

— Синдә булмаса, Бикбулатлар, Миңҗаннарныкын язарлар.

— Әһә! Язасы да сыпырып аласы икән! Тот капчыгыңны!

Бөтенесен уртага салып киңәштеләр дә шунда ук бер сүзгә килделәр.

— Писерләрне авылга кертмәскә, ашлыкны яздырмаска. Казнага бер гөрәнкә ашлык бирмәскә. Солдатның ашарына булмаса, сугыш тизрәк бетәр. Ач килеш нибуч бик сугышасылары килмәс...

Шул ук көннәрдә Әхәт абый кайтып төште. Теге вакытта чыгып киткәннән ул кайдадыр озак кына югалып торган иде.

Хәзер ул бераз олы сымаграк кыяфәткә кергән, маңгаенда аркылы сузылган кызыл җөе дә бар.

Мөхәммәтҗан солдат Әхәтнең иңбашындагы яшел погонына, аннан да бигрәк, бил каешындагы киң йөзле хәнҗәренә карап торганнан соң:

— Алай икән әлисә. Менә, авылда тагын бер солдат артты, — диде. — Ничек соң анда эшләр, сугыш җирендә? Кая табарак тәгәрәгән шикелле? Ничегрәк булыр шикелле?

Әхәт абый җиң эченә яшергән тәмәкесен (окоптагы гадәт буенчадыр инде) башын ия төшеп кенә озак итеп суырганнан соң ике борын тишегеннән ике зәңгәр киндерә итеп озын төтен чыгарды.

— Анда бөтен нәрсә язгы инеш бозы шикелле. Шатыр-шотыр килә, — диде.

— Безнең монда төрлесен лыкылдыйлар. Имеш, янаралларны санамыйлар, имеш, хәзер бөтенесенә солдат үзе баш, диләр.

— Хак сүз, — диде Әхәт абый. — Янарал дип дерелдәп торулар

үтүт инде. Солдат кәмитете ни әйтә — хәзер шул закон. Тыңламыйсың икән, син командир түгел.

Вәли абый Арчага бик еш барып йөргәнлектән, яңа хәбәрләрне күбрәк белә иде. Ул да сорап куйды:

— Патшаны төшергән шикелле, хәзерге хөкүмәтне дә бәреп төшерергә кирәк, диләр. Ул турыларда ничегрәк?

Әхәт абый күп сөйләшергә яратмый иде. Ул бик кыска тотты.

— Алпавытларын да чурту, министрларын да. Җирне үзебезгә алырга! Чын рвалутсия менә шул буласы инде.

Кичкә таба каравыл өе янына, тыны-көне бетеп, судебныйдан Әхмәт йөгереп кайтты. Аның түсе киткән, күзләре әсәрләнгән, ул бик каты каушаган иде.

— Абыйлар! Иптәшем егылып үлде, тирес төягәндә. Менә хәзер генә!

Олы кешеләр аны юатырга керештеләр.

— Нихәл итмәк кирәк? Әҗәле җиткәнне алып калып булмый лабаса! Я авыр күтәргәндер, я йөрәге начар булгандыр.

Ләкин Әхмәт аларны бүлдереп кулын селтәде.

— Туктагыз әле! Белмисез сез, төшенмисез! — диде. — Судебный беләсезме аны нишләтте? Тирес арбасына утыртты да як-ягыннан терәтеп, өенә кайтартты. Аумасын өченгә як-ягыннан тотып бардылар. Ә ул изелә дә төшә, изелә дә төшә...

Мөхәммәтҗан солдат, таягын җиргә бәреп:

— Аһ, кансыз, таш йөрәк! — дип кычкырды. — Янәсе, байда эшләгәндә үлгән булып чутланмасын, акча түлисе булмасын!

Әхмәт, җыларга житешеп, мәетне ничек авылына кайтарып куюларын сөйләде.

— Өй тулы бала-чага икән, алар акырышып җыларга тотындылар. Хатыны күрү белән исеннән язып егылып калды.

Бу коточкыч хәбәр бөтенесенең йөрәгенә барып тиде. Каравыл өе янындагы халык борчылып, дулкынланып тавышланырга, төрлечә нәфрәтләрен белдерергә тотындылар.

— Оятсыз, җансыз кеше икән!

— Тукта әле! Нигә шулкадәр басымчак иттерергә! Ялчы — кеше түгелмени?

— Авыл халкы күрдеме? Нишләделәр? Тавыш кубардылармы?

— Нишләсеннәр? Берни эшләмәделәр, — диде Әхмәт. — Җылашып калдылар. Судебный күмәргә гроб тактасы да бирмәде дип әйттеләр.

— Нишләп мона авыз йомып калырга? Нишләп үзенне-үзең мыскыл иттерергә? Бөтен авыл белән якасына ябышырга кирәк, якасына!

— Судебныйның йортына кызыл әтәч җибәрергә!..

Мөхәммәтҗан солдат:

— Моны болай калдырырга ярамый. Өяз комиссарына дүрт-биш авыл исеменнән жалуба язабыз! — дип, үз янына шундый эшләрнең остасы булган Каймак Ибрайны чакыртты.

Күрәсең, бу хезмәтченең үлеме хәлләрнең куерып җиткән вакытына туры килгәндер, ул төнне авыл бик тынычсыз уздырды. Ярты төнгә кадәр капка төпләреннән кеше өзелмәде. Кемнәрдер икешәр-өчәр кеше булып сөйләшеп узалар, урамнан, я аргы яктан чабып узучы ат аягы дөпелдәгәне ишетелеп тора. Поклар алдыннан әни утны төрле догалар укып сүндерде.

— Ярабби, без ятимнәреңне шәфкатеңнән ташлама! Ни генә булса да хәере белән генә була күрсен! Дөньяларга тынычлык, бәндәләргә иминлек иңсен! Амин.

## V

Иртәгесен яктырыр-яктырмаста бөтен авыл аякка баскан иде. Хәкимҗан белән без дә, аннан-моннан гына өскә элеп, халык җыела башлаган урынга — ындыр артына чыктык. Яраланып кайткан солдатлар, яшүсмер малайлар да чыккан. Эшкә ярардай картлар, бишмәт өстеннән билләрен буып, сәфәр чыгасы кешеләрдәй әзерләнеп килгәннәр. Кайсы тимер сәнәк күтәргән, кайсы билбавына балта кыстырган. Ара-тирә иңнәренә куян мылтыгы элгән кешеләр дә күренгәли. Нинди-дер чиктән тыш зур, шулай да хәтәр эшкә җыенгандай, һәммәсе борчылалар, каушыйлар. Ындыр артыннан ерак та түгел, күрше урыс авылының башында, үзенең җимеш бакчалары, яшел калай түбәле биек каралтылары, зур ап-ак тәрәзәләре белән масаеп утырган алпавыт биләмәсенә бераз шигәебрәк карыйлар.

Күптән түгел Сәлим сугыштан авырып кайткан иде. Ул Цызганов ягына карап иңбашларын җыергалап алды.

— Пленныйлар мылтык белән чыкмас бит? — диде.

Гыйбаш абзый көлгән сымак итеп борыны белән пошкырып җибәрде.

— Пленный аны нишләп якласын? Ач тоткан өченме?

— Белмәссең! Күп итеп акча бирсә, мал бирсә!

— Малдамени хәзер эш? Менә мина кешенең, можыт, сукыр инәсе дә кирәкмидер. Бармы гаделлек дөньяда, юкмы гаделлек дөньяда? Менә нәрсәдә эш!

Халык байтак җыелгач, төрле яктан ашыктыра башладылар:

— Әйдә, кузгал! Тагын нәрсә көтәбез?

— Әнә, Березовка урыслары да кузгалырга тора.

— Атла, киттек!

Шулвакыт мәчет янынннан, авыл комитетының члены булып сайланган Бикбулатны, ике-өч дисәтнигеи нярпгеп, йөгерә-атлый, тыныкөне беткән элекке Йосыф староста килеп чыкты. Хәзер инде ул староста түгел, комитет башлыгы дип атала. Тик байлар белән куштаннар бер булып патша төшкәннән соң комитетка да шуны сайлап куйдылар. Әмма хәзер аны санламыйлар, бигрәк тә сугыштан кайткан солдатлар аның башлык булуын танымыйлар иде.

Йосыф, кила килешкә таягын болгап:

— Туктагыз, тукта! — дип кычкырды. — Ашыкмагыз, җәмәгать, уйлашыйк, киңәшик!

Аңа берничә кеше берьюлы каршы төште:

— Нәрсәсен сөйләшәсең? Тыңламагыз шул карт куштанны!

Ләкин Йосыф халыкның алдына чыгып таягын күтәрде.

— Җәмәгать! Әйткәнне тыңлагыз! Хөкүмәт ярлыларга өстәмә җир кисеп бирәчәк, ашарына булмаганнарга ашлык бирәчәк! Кичә өяз комиссары үз теле белән шулай дип әйтте.

Халык бераз тынып калды. Мөхәммәтҗан солдат:

— Кайчан бирә, ничек бирә? — дип сорады.

Йосыф бераз ык-мык итте, әмма тиз үк яңадан батыраеп тотынды:

— Тиз, тиз, җәмәгать! Сугыш кына бетсен! Шул көнне үк!

Монысыннан шаркылдап көлделәр.

— Һа, һа, һа! Тиз икән!

— Язган булса, яз көне!

— Ышанма, алдыйлар! Түрәләре дә, алпавытлары да — бөтенесе бер шайка!

— Кузгал, киттек!

— Буталма монда! Үзен дә иске, пичәтен дә патша ясаткан пичәт!

Ичмасам, «Керәшен Яңа Саласы» дигәнне боздырып кайтсаң да телгә алырдай бер эшең булыр иде.

Әмма Иосыфның һаман да бирешергә ният юк иде әле. Ул каршы төшеп тагын кычкырды.

— Акылыгыз бармы? Сез бит разбойга барасыз, кеше таларга! Моны бит закон да сыйдырмый, шәригать тә кушмый. Николай Прокопич белән яхшылап сөйләшик, тәмле тел белән! Бәлкем, болай да бирер!

— Бирде, ди, тот капчыгыңны!

— Кирәкми, сөйләшмибез, без үз җиребезне алырга барабыз!

— Бабайлар мирасын!

Бүтән тавышларны җиңеп, иң өскә Вәли абыйның калын тавышы бәреп чыкты:

— Ни пычагыма аңа тел әрәм итәргә! Беләсезме синең Прокопичең җир сорап барган җирсезләргә нәрсә диде? «Монда җир житмәсә, әнә Себергә китегез, сезне анда бик көтәләр», диде. Ишеттегезме?!

Халык яман шауларга тотынды: «Куарга Цызгановны, куарга! Эзе дә калмасын! Долой килмешәкне!» дип кычкырдылар.

Шунда Иосыф каршысына Мөхәммәтҗан солдат килеп басты. Ул, бик иртә булуга карамастан, бәйрәмчә кырынып, төзәтенеп чыккан, өстенә шахтадан алып кайткан туры якалы, җиз төймәле кара пинжәген кигән, бармагында көмеш балдагы да ялтырый иде. Ул кәкре муенлы таягын алпавыт җиренә таба айкады.

— Әйт әле, Иосыф агай, әнә аннан, кояш чыгышыннан, безнең җирне кем килеп умырып алган?

Иосыф, төсен бозып, башын читкә борды. Аның урынына бүтәннәр кычкырдылар:

— Кем булсын, Цызган, Цызган!

Солдатның кәкре башлы таягы урманга таба айкалды.

— Әлисә әйт, Иосыф! Менә бу яктан безнең бугазыбызга кем килеп баскан?

Бөтен халык берьюлы:

— Дәкүчәй алпавыты! — дип акырып куйдылар.

Мөхәммәтҗан солдат халык өстеннән тагын да биегәеп, башын чөеп җибәрде. Аның аксыл чырае кызарып китте. Ярсып, ялкынланып төрле якка борыла-борыла халыкка сорау куйды:

— Туктале! Ничек әле бу? Нужәли без шулай кругом яктан тозак эчендә калдык? Бәлки кояш баешы гына булса да ачык калгандыр?

Бөтен халык берьюлы, тагын да ачулана һәм ярсый төшеп:

— Юк инде, юк! — дип кычкырып җибәрделәр. — Опыттыңмени?! Ул якка якын да барыр хәл юк! Аннан безгә Черпак алпавыты белән судебный бурзайлары өреп чыга.

Вәли абый кара пирчәткәле яңа кулын өскә күтәреп бөтенесен бүлдерде.

— Туктагыз әле, ишеткәнегез бармы? Камалуда калган бүре актык чиктә кая ташлана!

— Кызыл чүпрәк элмәгән якка!

— Бар бит безнең камалмаган як! — Ул кара пирчәткәсе белән зират һәм чиркәү ягын күрсәтте. — Әнә!

Халык бераз гына тынып торды да кинәт яңадан кабынып китте. Арадан иң элек Сарник Галимҗан тавышы бәреп чыкты:

— Себер юлы ич ул!

— Анда чиркәү.

Аңа өстәп тагын берничә тавыш берьюлы күтәрелеп бәрелде:

— Менә шул шул! Кругом алпавыт. Без кругом камалган! Я чукын, я Себергә олак! Безгә бүтән юл калмаган!

— Безнең тыннар буыла!

Вәли абый тагын каршы төшкән кебек итенде:

— Нигә алай гына булсын? — диде. — Безнең авыл кешесенә патша тагын бер сукмак калдырган. Чукынмасаң, Себергә дә китмәсәң, әнә синең юлың туп-туры кабергә!

Халык кинәт җил килеп бәргән урман кебек гүләп куйды. Баш өстендә сәнәкләр, күсәкләр ярсыбрак айкала башлады. Төрле яктан ачы тавышлар ишетелде.

— Кузгал, җитте, тыңлама старостаны! — диде Әхәт.

— Йөрмәсен аяк астында буталып!

— Нигә җанны кыйный, нигә тоткарлый ул халыкны?!

Йосыф карт дөп иттереп таягы белән җиргә сукты.

— Актык сүзем! Арчадан әтрәт килергә чыкты. Атлы казак! Биспәрәдек булса, иң элек үзеңне тотып асабыз, диделәр. Бу нишләвегез?! Бармы иманыгыз, юкмы иманыгыз! Харап итәсез бит!

Сарник Галимҗан аңа:

— Шыңшыма инде! — дип кычкырды. — Ярар, әнә бездән булсын яхшылык. Сине асасы бауны сабынлап бирербез. Ансатрак ычкынырсың.

Бөтен якын-тирәсе белән көлешеп алдылар. Йосыф агарынды, багана кебек баскан җирендә катып калды.

— Киттек! Шаярыр чак түгел!

Әхәт абый үзе алга узып:

— Солдатлар алга! — дип кычырды.

Сәнәкләр, күсәкләр айкалып китте. Бөтен халык яше-карты киң бер агым булып, уҗым басуы өстеннән туп-туры алпавыт йортына таба кузгалды. Кырау төшкән уҗым өстендә ямь-яшел булып яңа, киң юл сузылды.

Картраклар авыз эченнән догалар укып теләк теләргә тотындылар:

— Ярабби, изге сәгатьтә! Ятим балалар, тол хатыннар хакына... Хәере белән. Кансыз-сугышсыз, үлем-җитемсез...

Вәли абый барган килешкә аргы як Кирушның янтавына төртеп, шаяртып алды.

— Әй, Кируш, скрипкәңне алмагансың! Биергә туры килсә нишләрбез?

Кирушның чырае үтә кырыс иде. Күрәсең, аның шаярасы килмәгәндер.

— Исең китмәсен! — диде ул. — Карательләр килеп басса, скрипкәсез дә бик шәп биерсең!

Мадьяр солдат:

— Авызыңнан җил алсын! — диде. — Кеше хакымы әллә? Үз җиребезне генә кайтарабыз! Бабайлар җирен!

Хәкимҗан белән без иптәш малайлар арасында төркемнең алдагылары белән, солдатлар тирәсендәрәк бара идек. Кая басканны да белмибез. Бездәге ярсулы дәртнең иге-чиге юк. Шулай булмаска соң? Бөтен тирә-якны йөз еллар буенча албасты кебек басып яткан алпавытның үрмәкүч оясын туздырырга барабыз бит! Җир алырга барабыз! Их, бу көннәрне әти генә күрә алмады!

— Синең дә үз җирең була, — ди Хәкимҗан. — Үз җирең! Үз җирендә үстергән үз ипиең!

Хәкимҗан үзләренең унга якын кашыкка ике генә имана җир игүләре турында берни дә әйтмәде. Ләкин мин аның күзләре елтыравыннан, очардай булып дәртләнеп атлавыннан ук күреп торам: ул да бик дулкынлана, аның да әйтер сүзләре күп.

Олы кешеләрнең солдатлар килүеннән дә, бер кемнән дә курыкмыйча менә шулай кыю барулары безне җилкетә, дәртләндерә. Кем белә бит! Үен эш түгел! Менә хәзер ни дә булса булыр шикелле. Я ал-

павыт йортыннан пушкалар атып җибәрер, я берәр җиргә яшеренеп торган атлы казаклар килеп чыгар да китәр атыш, китәр үтереш.

Ләкин ни генә булмасын, без кире чигенмәбез, юк, юк! Без олылар белән бергә!

Алпавыт йорты ерак калмаган иде инде. Менә Арпа елгасын кичәсе дә, аннары тау гына менәсе.

Шунда безне Вәли абый үз янына чакырды.

Ул эчендә ниндидер шом саклап, тып-тын яткан алпавыт йортына, аннары безгә серлерәк кенә итеп карап торды да әле генә бик кирәкле йомыш исенә төшкәндәй, маңгаена тиеп алды.

— Карасана, егетләр! Онытылган бит! — диде.

— Нәрсә онытылган, абый?

— Казыклар! — диде. — Без бит җир алырга барабыз. Ә межага нәрсә кагып калдырырбыз?

Без бүген Каф тавы артына дию пәриләрен үтереп кайтырга, тугыз башлы аждаһаның үзенә дә каршы барырга әзер идек. Вәли абыйның авызыннан чыгуга авылга йөгердек.

## VI

Казыкларны алып кире барганда атка атланып чапсак та иң башланган чагына өлгерә алмый калганбыз. Абыйларны куып җиткәндә, алпавытның үзе бер урам булып сузылган әллә ничә капкалы зур йортына бакча ягыннан безнекеләр, урам ягыннан Каенсар белән Березовка кешеләре бәреп кергән иде. Ул тирә өзлексез гөрләп тора. Йорт эчендә нәрсәдер шакылдый, шыгырдый, чылтырап тәрәзәләр коела, кемнәрдер кычкыра, сүгенә, берьюлы бер көтү эт өрә, тавыклар кыраклый. Инеш буенда кемнәрдер кычкыра-кычкыра сыерлар куып йөриләр, җимеш бакчасында кош-корт чыр-чу килә.

Әмма Гыйбаш абый белән Мәдьяр, Кирүш белән Вәли абый, аларга ияргән тагын берничә ярлы-ябагай һәм комитетның кайбер членнары анда тукталмыйча, тау кырыйлатып, алпавытның басуына үттеләр.

Березовка турысына җиткәч, безнекеләргә берничә урыс агай кушылды. Аларның иңнәрендә мылтыклары да бар иде.

— Здрастуй, шабра, здрастуй! — ди-ди исәнләшеп, сөйләшә-шаулаша тагын да өскәрәк менеп киттеләр.

Тәбәнәк кенә чикләвек куагы белән кәрлә имән һәм артыш агачы үскән калку межага барып җиткәч тукталылар. Ерактагы урманга кадәр сузылган киң тигез кыр өстенә, бик сагынышып көткәннән соң очрашкан якын туганнары белән күрешкәндәй, күзләрен ала алмыйча әсәрләнеп карап тордылар. Мәдьяр солдат шатлыгыннан кычкырып җибәрде:

— Менә ул, менә безнең җир! — диде. — Кара, кайларга таба киткән! Дөнья тикле бу, икмәк бу, икмәк!

Урыс агайларның берсе әллә ничә тапкыр мылтык шартлатты, башкалары бер-берсенең кулларын кысарга, кочаклашырга тотындылар. Гыйбаш абый баскан урынында таптанып:

— Их, шабра! Вот бит какой дило! — диде, бүтән сүз табылмагач, шапылдатып сакаллы агайның иңбашына сугып куйды.

Җиргә казыклар кагып алпавыт йортына таба кайтып барганда, безгә мышкылдап йөгерә-йөгерә Нимҗан килеп кушылды. Ул Цызгановның рига[1] янында хезмәтчеләр өчен салган агач өен сүтәргә булышкан. Берьюлы ничәдер атка төяп, аны Әхәт абый нигезенә ташый

[1] Өсте капланулы зур әвен.

башлаганнар. Нимҗан бөтенесенә дә беренче булып җитешә, тегесен-монысын бөтен кешедән күбрәк белә иде.

— Цызганов ничек чыгып тайган, беләсезме? — диде. — Без берни дә белми йөрибез икән.

— Сизенгән ул карт төлке! — диде Нимҗан. — Авылныңниләр уйлавын алдан ук белеп торган. Иң кыйбатлы әйберләрен әллә ничә атка төяп, бөтен бала-чагасы белән чыгып бара икән, бер хезмәтчесе ат башыннан килеп тотмасынмы! «Җибәр!» дип әйтә, ди. Теге җибәрми, ди. «Халык җыелсын, арт сабагыңны тыңлатсыннар әле», дип әйтә, ди. Шуннан Цызганов шарт тегеңәр алтатардан. «Колак яныннан гына сызгырып китте», дип әйтә, ди хезмәтче.

Көн кичкә авышкач, арып, ачыгып кайтырга чыктык. Арпа елгасының бу ягыннан караганда алпавыт йортының тузгып яткан нигезе белән ишек алдындагы ватык йорт җиһазлары һәм Арпа елгасына аркылы төшеп ауган зиннәтле зур чаналар гына күренә иде.

Әхәт абыйның моңарчы күп еллар буш торып эрем белән алабута баскан йорт урынында күршеләре һәм туганнары, өмә ясап, өй житкереп яталар. Ирләр, мүк салып, өйнең стенасын өеп менә, хатын-кызлар пыялаларын сөртеп, тәрәзәләрне куярга әзерли, кайберләре мич чыгарырга балчык изә. Бер кырыйдарак киртәгә бәйләгән зур гына алпавыт аты печән көйшәп тора, тагын да читтәрәк ике-өч баш кара сарык күренә.

Узып барышлый койма буена туктап, Гыйбаш абзый авызын ерып тора.

— Менә син тамаша! Бер көн эчендә атлы-тунлы, йортлы-жирле булдың бит, Әбделәхәт! — ди. — Нәкъ әкияттәге шикелле!

Мин алып кайткан шыксыз дәү тай дугасы белән ниндидер зур сурәттән бушаган алтын бизәкле кызыл рамны күргәч, әни көлемсерәп башын чайкады.

— И бала, бала...

Кулымдагы әйберләрне мин чын-чыннан шунда гына күрдем, әнинең борчулы моңсу күзләреннән үземнең чыннан да сабыйлыктан чыгып житмәгәнлегемне аңладым. Соң бит мондый рамга куярлык сурәт безнең йортта гомердә буласы юк. Әгәр тае була калса... Тае булса, эш дугасына терәлер идемени?..

Кичкә таба авылны атлы солдатлар килеп басты. Алар баштарак, һай-һу килеп, камчыларын айкый-айкый, урамның бер башыннан икенче башына чабып йөрделәр. Әфисәрләре бөтен авылга хәбәр салды:

— Бөтен ир-атка мәчет янына җыелырга! Алпавыттан алып кайткан барлык малны каравыл өенә төшерергә!

Мәчет янына бер кеше дә чыкмады, каравыл өенә беркем бер нәрсә төшермәде. Аның урынына халыкның яше-карты, авыруы-сырхавы берсе бер калмыйча, кайсы сәнәккә, кайсы күсәккә таянып, капка төбенә чыгып бастылар.

Әфисәрләр тыз да быз урам буенча чаптылар, әле бер капка төбенә, әле икенчесенә туктап, камчы да айкап карадылар. Ләкин агайлар ник ичмаса мыегын гына кыймылдатсын! Ясап куйган сындай, бер көчтә урыннарыннан кузгата алмас Алып батырдай, һич кымшынмыйча тора бирделәр.

Шулай тарткалашып байтак вакыт узганнан соң караңгы төшәрәк, каравыл өе янында, бөтен авылны яңгыратып, быргы уйнарга тотынды.

— Ту, ту, туту-туту!..

Бу сугыш авазы күңелләргә шом салды. Ир-атның йөрәге сулкыл-

дап куйды. Бала-чага бакча артларына, койма ярыкларына ябырылды. Хатын-кыз ирләре янына чыгып басты.

— Ни була? Нишлиләр? Әллә югыйсә ата башлыйлармы? Әллә асарга-кисәргә тотындылармы?

Быргы тавышы тынып кына өлгерде, авылның төрле очына таралышкан атлы солдатлар минут эчендә җыелып та житте. Ул да түгел, алар, давыл өреп очырткандай, юкка да чыктылар.

Яңадан бөтен халык урамга сибелде. Ирләр бер тирәгәрәк, хатын-кызлар капка төпләренә җыелып, шатлыкларын уртаклашырга тотындылар. Мәдьяр, аксый-туксый урам уртасына чыгып, бер үзе «ура» кычкырып алды:

— Ура! Качтылар карательләр! Тешләре үтмәде!

— Бетте алпавыт, чәнчелде! — диде берсе. — Муены астына килде!

Мөхәммәтҗан солдат ашыгуыннан бер аягына кызыл чуар, икенчесенә ак итек киеп чыккан. Кулындагы гәзитне айкый-айкый капка төбе саен тукталып үтте.

— Юк, алпавыт кына түгел, иске тормыш бетте! Патшалы тормыш та, буржуйлы тормыш та бөтенләйгә дөмекте!

Солдатлар бер йорттан икенчесенә йөреп берсеннән берсе сөенче алалар, бергәләп куанышалар.

— Бетә болай булгачыннан сугыш, кайта безнекеләр алла боерса! — диләр.

Без, малайлыктан чыгып килүче яшүсмерләр, шушы искиткеч яңалыклар, эчкә сыймастай куанычлар белән канатланып, әле берсе янына, әле икенче төркемгә туктый-туктый бөтен авылны әйләндек. Без чишмә өстендәге иске мунча нигезенә кайтып утырганда кояш баеп, шәфәкъ нурлары сүнә башлаган иде. Әмма аның урынына кояш баешыннан, җир белән күк арасында эленеп торган киң бер нур булып, Казан өстендәге кичке яктылык балкый башлады.

Хәкимҗан, ерактагы шул тылсымлы нурдан күзен алмастан, үзенең шыпырт кына агымлы тавышы белән:

— Казан балкый! — дип әйтеп куйды. — Мәскәү тагын да шәбрәк балкыйдыр, няме?

Без, чыпчык балалары шикелле бер-беребезгә сыенып, һәммәбез дә шул якка карап утырабыз. Күңелләрне, бәйрәм көннәрдәге шикелле, зур куаныч рәхәтләндереп тора. Солдатларның авыл халкына корал күтәрә алмавыннан, олыларның кайбер сүзләреннән чамалап, бөтен илдә ниндидер зур эшләр, башка да сыймастай ниндидер искиткеч үзгәрешләр булып ятуын яхшы сизәбез. Әнә шул нур балкыган җирдә безнең өчен дә яңа тормыш кабындыралар кебек тоела.

Ул яңа тормышның ничек буласын без әле күз алдына да китерә алмыйбыз алуын. Безнең өс-башыбызның да рәте-юше юк, иске-москы гына. Тамагыбызның да тук чагыннан ач вакыты күбрәк. Шулай да безгә бик рәхәт. Әнә шул еракта балкыган якты нур безнең киләчәгебезгә ниләрдер вәгъдә итә, ниләрдер омсындырып, өмет чаткылары белән күңелләребезне җылытып тора иде.

*Аккош күле — Казан. 1967 ел.*

*Ислам Беляев*

# Имәннәрең илтеп утырт шунда...

## I

Кем ул әйтә:
Син картада юк дип!
Дөрес түгел, авылым, бу бер дә,
Дошманнарның сугыш картасына
Төшерелгән һәрбер өең дә,
Базларыңа хәтле билгеләнгән; —
Сейфларда төреп саклана.
Күрдең ничек йортлар янганын син,
Төшерелгән булса картага.
Син еракта идең ул афәттән,
Ләкин күрдең, күрдең барысын да:
Кан эченнән Лидицелар килде,
Хиросима килде каршыңа.
Һәр ишектән кереп йөрде тарих,
Тар булмады аңа бусагаң.
Чыкмаса да анкан шагыйрь Муса,
Чыкты бик күп солдат Мусалар.
Чыкты рота!
взвод арты взвод, —
Ярты дөнья шаһит моңарга.
Ә соңыннан отделениеләр
Кайтты бары туган кырларга...

## II

Кем ул әйтә:
Сине кечкенә дип,
Карталарда юк дип исемең дә!!
Унлап илнең йолдызлары яна
Уларыңның кабере өстендә.
Өйләреңдә сагыну арткан саен
Колачлырак, киңрәк уйларың.
Зиярат кылып канлы туфракларын
Күңелең урый Висла буйларын.
Бозлы диңгез ярларына китә,
Йөреп чыга Карпат тауларын.
Яшең сөртеп Идел ярларыннан
Котлыйсың син Дунай таңнарын.
Уларыңның соңгы сукмагыннан
Күңелең китәр, бәлкем, Хинганга.
Бәлкем, анда дуслык сүрелгәндер,
Тик сүрелми кайгың һаман да.
Чикләр белән чикләп булмый торган
Кайгыларга күңелең төренгән.
Күпме илнең канлы туфрагында
Гөлләреңә урын бирелгән.
Имәннәрең илтеп утырт шунда, —
Барча дуслар булыр шат аңа.

Җир йөзендә барлык авыллар да
Алынганнар хәрби картага.

*Шамил Маннапов*

## Ышандыр

Юашмыкдыр бәлки кирәкмәскә,
Кирәкмәскә бәлки усалдыр,
Тик холкымның әйбәт булуына
Син ышандыр мине, ышандыр.

Сокландыргыч чибәр түгелмен дә,
Буй-сыным да чандыррактыр,
Тик матур бер Кеше булуыма
Син ышандыр мине, ышандыр.

Яннарыңда кайчак мин үземне
Сәеррәк тә бәлки тотамдыр,
Тик үзеңнең мине сөюеңә
Син ышандыр мине, ышандыр.

Ышандыра алсаң, күрерсең
Сүзләреңнең чынга чыкканын.
Тик онытма,
Әйтер сүзләреңә
Син үзеңне башлап ышандыр.

## Хис

Космоста шул түбә ябылмаган,
Күпме нурлар бушка чәчелә...
Сез әйтерсез: «Кысыр кайгы белән
Ак төшермә, егет, чәчеңә».
Уйланырсың,
Йөрәк тә бит шулай
Чамаламый түгә хисләрен.
Их, үлчәргә иде күпме өлеше
Мәгънәле эш өчен киткәнен!
Мәхәббәткә азмы хисең түгелә,
Исең китәр салсаң хисапка.
Ләкин чал карт
Көчем бетте дияр,
Хисем бетте димәс һичкайчан.

Кояш сүнгәндә дә сүрелми, ди,
Җылысының Җиргә күчкәне.
Кеше яши,
Үлә,
Ләкин үлми
Эшенә күчеп калган хисләре.

## Хатирә

Авылыма кайтып җитү белән
Чишмә янына килдем,
Иелдем.
Иелдем дә кинәт тотрәп калдым,
Тидермичә кипкән иренемне.
Бу соң минме!
Олыгайган йөзле
Бер ир карый миңа чишмәдән.
Әйе, чишмә,
Мин киткәннән бирле
Кемнәр күпме суың эчмәгән!!
Салкын суыңа синең гашыйк идем.

Сусаганда капсам бер йотым,
Алга китә идем чабышкыдай,
Аякларым талуын онытып.
Эх, гомернең чәчәк аткан чагы —
Ачылган чак хиснең чишмәсе.
Тик ул хисләр булган үкенечкә,
Үкенечкә булган, нишләсе.
)Яннарыңда үскән зәңгәр гөл дә
Мине озатып калган гөл түгел.
Суга төшеп килгән кызыйларның
Берәүсе дә, беләм, ул түгел
Ул түгел...

Совет властеның 50 еллыгына

*Зәки Әхмәтҗанов*

# ОКТЯБРЬ ЯШЬТӘШЕ

*Очерк*



Бөек Ватан сугышы елларында совет очучылары тиңдәшсез батырлык үрнәкләре күрсәттеләр. Гитлер Германиясен һәм империалистик Японияне җиңүгә, коры җир гаскәрләре һәм хәрби диңгез флоты белән берлектә, хәрби һава көчләре дә зур өлеш кертте.

Хәрби очучыларыбызның сугыш вакытында ирешкән уңышлары һәм күрсәткән батырлыклары халкыбызның зур игътибарын казанды, партия һәм хөкүмәтебезнең югары бәясенә лаеклы булды. 200 меңнән артык авиаторлар орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде. 2 120 очучыга Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелде. 65 кеше бу зур исемне икешәр тапкыр алуга иреште. Ә. А. Покрышкин һәм И. Кожедуб күкрәгендә 3 әр Алтын Медаль балкыды.

Герой очучылар арасында татар халкының да батыр уллары булуы бездә горурлык хисе тудыра. Без биредә шул геройларның берсе—очучы-штурмовик Тамерлан Ишмөхәммәтев турында сөйләргә телибез.

* * *

Гасырлар буена патша Россиясенең зинданы булган, декабристларның якты эзләрен әлегә кадәр саклаган ерак Себердә Ялутыр дигән кечкенә генә бер шәһәр бар. Аннан көньяктарак тын гына агып ятучы Кечтә Тобол елгасы үзәненә Бомаер авылы урнашкан.

Россиядә яңа җәмгыять тууын хәбәр итеп, «Аврора» крейсеры залп биргән 1917 елда әнә шул авылда Тамерлан дөньяга килә. Аның балачагы туган авылында, табигать кочагында үтә. Иптәшләре белән төрле уеннар уйный, Кечтә Тоболга су керергә йөри, балык тота.

Башта үз авылында башлангыч мәктәптә укый, аны тәмамлагач, күрше Аслан авылына колхоз яшьләре мәктәбенә йөри. Монда укыганда иптәшләре арасында рәсемгә осталыгы һәм яхшы спортчы булуы белән таныла.

Мәктәпне тәмамлагач, Тамерлан 3 ел буена Свердловск шәһәрендә татар педагогия техникумында укый. Техникумны яхшы һәм отлично билгеләренә бетереп чыгу турында аттестат алып, яңадан туган ягына кайта.

Дөрес, бу тирәдә шаулап торган калын урманнар да, зур сулар да юк. Кышларын монда бөтен тирә-як — кырлар, бакчалар — тирән кар катламы астында кала. Көзләрен өзлексез сибәләп торган яңгырлар, уңдырышлы кара туфраклы басуларны, юлларны йөреп булмаслык пычракка әйләндерә.

Ә җәй көннәре ел тәүлегенең бөтен матурлыгын берьюлы алып килә. Бөтен тирә яшеллеккә күмелә. Күп санлы кошлар тавышы күңелле симфония булып яңгырый. Шуңа күрә яшьтән табигатьне сөеп, аның кочагында үскән авыл малае Тамерлан, һөнәр алгач та, туган якларыннан китәргә ашыкмый. Ул үзе укып чыккан Аслан мәктәбендә тарих һәм рәсем фәннәрен укыта.

1936 елда Кызыл Армия сафына китә, комсомол путевкасы белән Оренбургтагы очучылар мәктәбенә юл тота.

* * *

...Бөек Ватан сугышын яшь очучы кыр аэродромында каршылады. Ял көнен шәһәрдә үткәрү өчен киченнән үк әзерләнеп куелган рөхсәт кәгазьләре бу юлы файдаланылмый калды. Өйрәнү очышларыннан кайткан очучыларның уен-көлке, шаяру сүзләре дә ишетелмәде бу көнне. Һәркайсы ангарда үз машинасы янында маташты. Беркемнең дә сугыш башлануына ышанасы килми иде.

Ә икенче көнне, 23 июльдә, сугышчан приказ алынды.

Менә Тамерлан Ишмөхәммәтев, гомерендә беренче тапкыр, бомбалар таккан самолетын дошман өстенә алып бара.

Бер дә көтмәгәндә туган илебезгә басып кергән фашист илбасарларына нәфрәт белән тулган очучы йөрәге ярсый, ашкынып тибә. Куллар штурвалны тагын да кысыбрак тота. Күзләр аска, җиргә текәлгән. Самолет канатлары астында, юлларда немецларның фронтка килүче танклары, машиналары, күп санда соры-яшел мундирлы солдатлары мыж килә. Тамерлан машинасын шулар өстенә юнәлдерә һәм бомбаларын ташлый. Самолет тирәсендә ак төтен шарлары ясап, зенит снарядлары шартлый башлый. Аста берничә җирдә зур ут баганалары һәм кара-кучкыл төтен катыш ялкын күтәрелә. Икенче кат әйләнеп кергәндә эскадрилья дошманның тагын бер колоннасын бомбага тота. Задание яхшы үтәлә. Самолетлар барысы да үз базаларына әйләнеп кайталар. Аның сугышчан биографиясе әнә шулай башланып китә.

Сугышның беренче айларында очучылар өчен эш аеруча күп булды. Тамерлан Кырым юлларында фашистларның техникасы, солдатлары өстенә уннарча тонна бомба койды, Севастополь оборонасы вакытында дошманның ут позицияләрен, хәрби складларын утка тотты.

Сугышның дүртенче ае киткәч, 1941 елның октябрендә, Тамерлан, яңа ИЛ-2 самолетын үзләштерү өчен, Куйбышев өлкәсенә, кыска сроклы курсларга җибәрелде. Бу курсларны уңышлы тәмамлап, ул 570 нче штурм авиациясе полкына билгеләнде.

* * *

1942 ел. 22 июль. Иртәдән үк чалт аяз. Күктә бер генә болыт кисәге дә күренми. Иртәнге эш вакытында кайсыдыр:

— Егетләр, күбрәк ашагыз, бүген эш күп булачак, төшке ашка кайтып тормабыз, — дип, шаяртып та алды.

Бу көнне чыннан да эш тыгыз булды егетләргә. Бик күп истребительләр сагы астында дошман самолетлары безнең позицияләргә кабат-кабат һөҗүм иттеләр. Алгы сызык тузан һәм төтен белән капланды.

...Төш вакытында лейтенант Ишмөхәммәтев звеносы үзенең бүгенге бишенче очышын уңышлы башкарып, аэродромга кайтты. Арыган очучылар салкын су белән юынган арада техниклар самолетларны карадылар, яңа бомбалар элделәр.

— Эх, бер йөз генә минут йоклап аласы иде хәзер, — дип хыялланды лейтенант Валерий Афанасенко, звено командирына карап.

— Июль аенда, кызу урак өстендә юньле кеше йокы турында уйлыймыни, — диде Тамерлан, елмаеп. — Әйдә, вакыт барда капкалап алыйк.

Ләкин аларга ашарга да, ял итәргә дә туры килмәде. Берничә минуттан звено, тревога буенча, тагын, алтынчы тапкыр һавага күтәрелде. Бу юлы ул үзенең сыналган лачыннарын, разведка биргән мәгълүматлар буенча, Төньяк Кавказның Гизель районына алып китте. • Иртән һөҗүмгә кучәргә җыенган дошман ул тирәгә үзенең бик күп техникасын, складларын туплаган иде.

Беренче команда булу белән ут ачарга әзер торган танклар, туплар, аларның снаряд запаслары өстенә, бер дә көтмәгәндә, бомбалар ява башлады. Берничә җирдә зур-зур янгын учаклары күтәрелде. Үз снарядлары шартлаудан да дошманның бик күп техникасы юкка чыкты. Икенче әйләнеш тә уңышлы тәмамланды. Бомбаларның барысы да билгеләнгән урынга төштеләр. Звено алдына куелган бурыч тулысынча үтәлде.

Очучылар, үз эшләренең нәтиҗәсенә сөенеп, кайту ягына борылдылар. Нәкъ шул

вакытта командир машинасына снаряд тиеп ярылды. Тамерланның битенә снарядның вак кыйпылчыклары сибелде. Самолет кечле электр тогына эләккән кебек дерелдәп куйды. Очучының күз алды караңгыланып китте. Тәне буенча кайнар кан агуын сизеп, ул күзләрен ачты һәм уң кулындагы ярадан аккан канга буялган штурвалны күрде. Канга баткан килеш ярым ватык самолетын үз аэродромына кадәр алып кайту, аны җиргә төшерү өчен Тимерлан барлык ихтыяр көчен җыйды.

Ул госпитальдә генә һушына килде. Кемгә икәнен үзе дә белмичә, ашыгып сорау бирде:

— Группа ничек, исәннәрме?

— Барысы да исәннәр, тыныч булыгыз.

— Тукта, бу нәрсә соң әле? — диде ул, тирә-якка күз салгач. Кайсы якка караса да аның тирәсендә ак бинтларга чорналган кешеләр яткан койкалар тезелеп киткән иде.

Стенадагы динамиктан фронтовиклар соравы буенча төзелгән концерт башланды. Рус, грузин, казакъ җырларыннан соң, палатага «Шахта көе» моңы агыла башлады. Тамерлан кинәт динамик ягына борылган иде, ярасына ябышкан бинт купты. Ул авыртудан чыраен сытып, элеккечә ятты да дөньясын онытып җырны тыңлый башлады. Туган тел, таныш моң аның уйларын ераккa, туган якларга алып китте. Себере... Бомаер авылы... Балалык дуслары... ул яраткан тарих, география укытучысы Әхмәт ага Шабиков... Кечкенәдән укытучы булу турында хыялланып йөргән апасы Сәйдә...

Бу минутларда Тамерлан үткән 24 ел гомеренең истә калган барлык минутларын күз алдыннан үткәрде. Шул матур уйлар белән йоклап киткәнен үзе дә сизми калды.

Тамерлан госпитальдә дүрт ай ятты.

Ниһаять, беркет яңадан сафта. Бу юлы аны 765 нче штурмовиклар полкы составына җибәрделәр.

Озак та үтми, «Темрюк шәһәре районындагы немецларның кечү корылмаларын җимерергә, су буйлап йөк ташуны туктатырга», дигән приказ алынды. Бу бурычны үтәү лейтенант Ишмөхәммәтевкә тапшырылды. Сугышчан заданиене үтәп, үз аэродромына кайту юлында Ишмөхәммәтевкә немецларның җиде «Юнкрес-52» самолеты һөҗүм итте. Фашист очучылары бу ялгыз штурмовикны үзләре белән алып китәргә теләп, төрле яктан боҗрага алдылар, ә алдан баручысы, кайсы якка очарга кирәклеген күрсәтеп, ракета очырды.

— Юк инде, фашист, бусы булмас, — диде Тамерлан, бар көченә тешләрен кысып, һәм газны арттырып, самолетын алдагы немец машинасына юнәлдерде. Фашист самолеты белән Тамерлан арасы минут саен якынайды. «Батуен бетәм, әмма фашистны да дөмектерәм», дип уйлады ул. Исәбе таранга бару иде. Ләкин фашист козгыны соңгы секундта өскә ыргылды. Тамерлан шул уңайлы моменттан файдаланып, пулеметтан озын очередь бирде. Канатларына һәм фюзеляжына ак каймалы кара тәре төшерелгән «Юнкерс-52», артыннан кара төтен юлы калдырып, Лиман ярына таба төшеп китте. Лейтенант Ишмөхәммәтев бу юлы да үз аэродромына исәнсау кайтып җитте. Озак та үтми, парашют белән сикереп безнең алгы сызыкка төшкән немец очучысын полк штабына алып килделәр.

Урта буйлы, таза гәүдәле бу немец сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен дүрт тапкыр тимер тәре белән бүләкләнгән, майор чиныннан очучы булып чыкты.

— Мин Испаниядә сугыштым, Африка, Европа күгендә күпме очтым, Англия шәһәрләрен бомбага тоттым. Язмыш минс һәр җирдә саклады. Мине җиңгән очучыгызны күрсәтегез әле, — диде ул, калтыранган тавыш белән.

Шул вакыт бүлмәгә килеп кергән яшь пилотның Тамерлан икәнен белгәч, майор урыныннан сикереп торды.

— Әллә сезнең барлык очучыларыгыз Тамерлан исемлеме? Тамерланыгызны узган елда үзем бәреп төшердем бит, — диде ул. — Өченче «тимер тәрене» аның өчен бирделәр миңа. Рейхсмаршал үзе тапшырды. Бу турыда газеталарда да язылды...

Аңа каршы штаб начальнигы:

— Сезнең газеталарга караганда сугыш 41 нче елда ук бетәргә тиеш иде, майор. Ләкин, күрәсез, аның үз кагыйдәләре, үз тәртибе бар, — диде.

Бу вакыйгадан соң, сугышчан бурычны һәрвакыт җиренә җиткереп үтәүче батыр очучының даны бөтен фронтка таралды.

Аның штурмовик белән немец ассын бәреп төшерүе турында фронт газетасына да яздылар.

Бу батырлыгы өчен Тамерлан сугышчан «Кызыл Байрак» ордены белән бүләкләнде.

* * *

1943 елның октябрендә Ишмөхәммәтевне 43 нче гвардия штурм авиация полкына

полк командиры ярдәмчесе итеп билгеләделәр.

Гитлерчыларны Сталинград «казаны»нда һәм Курск дугасында тар-мар иткәннән соң, безнең гаскәрләрнең уңышлы һөҗүм сугышлары нәтиҗәсендә, Украинаның шактый зур өлеше дошманнан азат ителде.

Апрель башында безнең частьлар Днепр суына чыктылар. Алда Кырымны фашистлардан чистарту бурычы тора иде.

Бу тирәдә урнашкан авиация частьлары өчен эш бермә-бер артты. Транспорт самолетлары немецларның көчлә зенит уты кертсен үтә алмый башлагач, башка беркинди юл белән дә азык һәм корал кертеп булмаганлыктан, Кырымның төньягындагы плацдармда 1943 елның көзеннән бирле геройларча оборона тоткан сугышчыларны тәэмин итү штурмовик самолетларга йөкләнде. Ишмөхәммәтев хезмәт иткән полк плацдармнарны тәэмин итүдә зур тырышлык күрсәтте.

Гитлерчылар Кырымны кулдан ычкындырмас өчен, һичнинди югалтуларга карамастан, рәхимсез, каты каршылык күрсәттеләр. Перекоп һәм Ишунь позицияләре эсэсчылар һәм гитлерюгенд членнарына тапшырылды. Ләкин рус солдатының омтылышына алар да каршы тора алмадылар. 11 апрельдә дошманның терәк пункты булган Джанкой станциясе азат ителде.

Бу көнне Тамерлан бер төркем самолетларны Салым тимер юл станциясенә алып китте. Гадәттән тыш начар һава шартларында станция өстендә өч тапкыр әйләнеп, аның җитәкчелегендәге самолетлар юллардагы сугыш кирәк-яраклары төялгән алты вагонны яндырдылар, юлларны җимерделәр. Берничә көнгә поездлар хәрәкәте тукталды.

16 апрельдә Севастопольнең тышкы оборона ныгытмаларына 4 нче Украина фронтының алгы частьлары килеп җитте. Ике көннән соң аларга Приморье армиясе килеп кушылды.

Гитлерчылар, ашыгып, Румыниядән килгән су транспортларына төялергә керештеләр. Ләкин, ачык диңгезгә чыгу белән, аларны безнең авиация һәм торпедалы катерлар диңгез төбенә олактырды.

Кырым һәм Севастопольне азат итү операцияләрендә сугышчан бурычларны һәрвакыт җирена җиткереп үтәве, шәхси кыюлыгы өчен Тамерлан Ишмөхәммәтев «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнде.

1944 елның калган айларында да Тамерлан барлык фронт буйлап чигенүче немец гаскәрләре өстенә үлем йөкләре ташуын дәвам итте. Заболотье—Васильевщина юлында аның тоз һәм тегәл ташланган бомбаларыннан гитлерчыларның 15 автомашинасы юкка чыкты, елга аша салынган кечү корылмасы җимерелде. Нәтиҗәдә дошманның чигенү юлы киселде, һәм безнең җирдәге сугышчылар аларны тар-мар иттеләр.

Октябрь башларында гвардияче очучы, өлкән лейтенант Тамерлан Ишмөхәммәтев йөзенче тапкыр сугышчан очыш ясады.

Фронт газетасында бу уңай белән махсус мәкалә басылып чыкты. Тамерлан яраланып госпитальгә киткәч, аның эзен югалткан сугышчан дусты Валерий Афанасенко ул мәкаләне укыды һәм Ишмөхәммәтевкә газета аша ачык хат язды. Бу хат «Крылья Советов» газетасының 1944 ел, 14 октябрь санында басылып чыкты.

«Котлавымны кабул ит, сугышчан дус! — диган иде В. Афанасенко, — Исәнме, хөрмәтле Тамерлан!

Шушы көннәрдә генә газетада синең йөзенче сугышчан очыш башкаруың турында укыдым. Димәк, син исән һәм элеккечә нык канатлы һәм үзеңә генә хас булган кыюлык белән Ватаныбызның азатлыгы өчен сугышасың.

Йөзенче очышың белән котлыйм сине, дус!

Хатымның беренче юлларын укып кына, син әле аны кем язуын аңламассың. Моны синең сугышчан дустың Валерий Афанасенко яза.

Без 1942 елда Керчь һәм Дон өстендә бергә сугыштык. Ул бик кызу сугышлар җәе иде.

Шунда син уңышсызлыкка очрадың. 22 июльдә безнең янга әйләнеп кайтмадың, госпитальгә киттең. Шуннан соң синең турыда һичкем берниәрсә белмәде...

Без сугыш хәрәкәтләрен дәвам иттек. Ләкин иртәгесен мин дә зур бәхетсезлеккә юлыктым... Машинам белән немецлар территориясенә егылдым. Һушыма килгәндә, немецлар кулында идем. Ике ай ярым әсирләр арасында үлем лагерьларында булдым.

Тамерлан! Атылган кошның канатлары асылынып торган кебек хәрәкәтсез ике сынык кул белән нинди авырлыклар кичерүемне син күз алдыңа да китерә алмыйсың. Ләкин әнә шул шартларда минем дошманга булган нәфрәтем тагын да чыныкты, артты. Хәзер минем тормышымның хыялы бер генә — ул да булса үч алу. Әйе, дош-

маннан уч алу минем төп теләгемә әйләнде. Һәм мин булдыра алган хәтле уч ала башладым. Җае чыгу белән партизаннарга киттем һәм Николаевск райкомы секретаре иптәш Макаров отрядында сугыша башладым.

1943 елның 7 январенда, немецларның өч обер-ефрейторын әсиргә алып, үзебезнең якка чыктым. Шуннан бирле мин тагын фронтта. Ләкин әлегә оча алмавым бик борчый. Шулай да өметемне югалтмыйм.

Кулларым төзәлгәч, һичшиксез, дәһшәтле машинада явыз дошман өстенә үлем ташырмын дип ышанам. Кыскача минә шул. Үзең турында, сугышлар һәм җиңүләр турында яз миңа, дус!

Зур сугышчан уңышлар телим сиңа.

Кулыңны кысып: өлкән лейтенант Валерий Афанасенко.

Полевая почта 15457».

Алга узып шуны да әйтеп үтик, Валерий Афанасенко яңадан самолетка утыра һәм сугыш беткәнче дошман өстенә үлем ташый, Көнчыгыш Пруссия ныгытмаларын утка тота, Берлин операциясенә катнаша. Ул да Советлар Союзы Герое, хәзер Николаевск шәһәрендә яши.

* * *

1945 ел. Март башларында гитлерчылар, Прейсиш, Диршау, Штаргард шәһәрләрен калдырып, Данцигка чигенделәр. Безнең гаскәрләр, Оливц, Ипот һәм Колиткен шәһәрләрен алып, 10 мартта Данциг һәм Гдыняга килеп чыктылар. Дошманның зур группировкасы икегә бүленде.

Дымлы диңгез җиле җир өстен томан һәм юеш кар белән түши. Очу өчен һава шартлары гаять уңайсыз. Шулай да очышларны туктатырга ярамый.

Апрель аен очучылар Данциг «казаны» һәм Штеттин юнәлешендә сугыштылар.

23 апрельдә Штеттинның көньягында инде үлемгә дучар ителгән гитлерчылар, ничек тә булса чолганыштан чыгып котылу нияте белән, көчле контратакага ташландылар. Безнең җирдәге частьлар ярдәм сорап очучыларга мөрәҗәгать иттеләр.

Инде берничә группа һавага күтәрелде. Ләкин куелган бурыч үтәлмәде. Самолетлар, дошманның тоташ ут стенасы аша үтә алмыйча, кире әйләнеп кайтырга мәҗбүр булдылар. Шуннан соң бу задание полк командиры ярдәмчесе өлкән лейтенант Ишмөхәммәтевкә йөкләнде. Приказ аңлаешлы: теләсәң нишлә, ә пехотаның алга баруын тәэмин ит!

— Ичмасам, һавасы да канат җәеп очарлык түгел, — дип, Тамерлан күккә карады.

Күк кургаштай авыр кара болыт белән капланган иде. Ә аның ачылганын көтәргә вакыт юк.

Берничә минуттан Тамерлан звеносы, аэродромнан күтәрелеп, дошман ягына юл тотты.

Командирның һәрвакытта да «Югарырак күтәрелегез», дигән командасын тыңларга гадәтләнгән очучыларны бу юлы «Мөмкин кадәр аскарак төшегез, миннән калмагыз», дигән сүзләре гаҗәпләндермәде, бүтәнчә мөмкин түгел иде. Чиркәү гөмбәзләренә, биек йорт түбәләренә тияр-тимәс биеклектә штурмовиклар алгы сызыкны үттеләр. Орудиеләре янында каушап калган немец зенитчылары тизрәк траншеяларга сикерү ягын карадылар.

«ИЛ»лар үз эшләренә тотындылар. Безнең пехотага баш күтәрергә ирек бирмичә, өзлексез атып торган артиллерия позициясе, пулемет оялары өстенә бомбалар яуды. Гитлерчыларның батареялары урнашкан урыннарда тирән чокырлар, тимер сыныклары гына калды. Алгы сызыкта, әрле-бирле урыннан урынга күчеп, атып йөрүче үзйөрешле орудиеләр дә ялкынга төренде.

Очучыларның батырлыгы белән рухланган укчылар шул минутта ук бердәм һөҗүмгә күчтеләр.

Бу операцияне уңышлы төстә үтәве өчен кыю командирга коры җир гаскәрләре командованиесе рәхмәт белдерде[1].

Ниһаять, соңгы хәлиткеч сугышлар башланды. Авиация алдына дошманның кыр артиллериясенә каршы көрәшү бурычы йөкләнде. Берлин тирә-ягына тыгызлап тутырылган меңнәрчә орудиеләрне утка тоту, аларны сафтан чыгару өчен көн саен 7 шәр, 8 әр очыш ясарга туры килә иде.

29 апрель көнне, шундый очышларның берсендә, Трептов шәһәре районында, Ишмөхәммәтевнең штурмовиклар группасы фашистларның 3 пулемет оясын, 3 кыр орудиесен җимерде, 25 гитлерчыны теге дөньяга озатты.

Заданиене үтәп кайтканда аның группасына, фашистларның 4 «Фюкке-Вульф-190» истребителе һөҗүм итте. Алар төрле юнәлештән дүрт тапкыр атакага ташландылар. Ләкин совет очучыларының кыюлыгы бу юлы да өстенлек алды. Нәтиҗәдә бер

[1] Оборона министрлыгы архивы, 33 фонд, 793756 опись, 19 эш, 329 бит.

«Фюкке-Вульф», кара төтен юлы сузып, җиргә мәтәлде.

43 нче Кызыл Байраклы Волковец штурмовиклар авиация полкы гвардиячеләре Бөек Ватан сугышының соңгы этабында — Берлин өчен барган сугышларда — аеруча оста сугыштылар. Дошманны камап алу, мөмкин кадәр тизрәк тар-мар итү, шуның белән меңнәрчә сугышчының тормышын саклап калу авиациянең уңышлы очышына турыдан-туры бәйләнгән иде.

Совет очучылары бу бурычны да җиренә җиткереп, намус белән үтәделәр.

Сугыш бетү турындагы шатлыклы хәбәрне Тамерлан самолет кабинасында ишетте... Һәр экипаж үз урынында. Очучылар, сигнал ракетасы күтәрелүен көтеп, күзләрен команда пунктына төбәгәннәр. Ракета күренү белән, дәһшәтле штурмовиклар эскадрильясы дошман өстенә ыргылырга тора.

Менә аэродром өстендә яшел ракета...

Кул гадәттәгечә газ секторына сузылды.

Шул вакытта ук сигналны тыючы икенче ракета күтәрелде. Очучыларның шлемофонында командирның дулкынланган тавышы ишетелде:

— Отставить! Җиңү, иптәшләр, җиңү!

Аэродромга җиңел машина килеп керде. Машина туктап җиткәнче үк, кабинадан дивизия командиры сикереп төште. Генералны күрү белән, очучылар аны уратып алдылар, ай-ваена да карамастан, өскә чөя башладылар.

— Шулкадәр ярыйммы соң, егетләр. Сугыш беткән көнне үтерә яздыгыз ич, — диде генерал, елмаеп. Аннан, кесәсеннән зур кульъяулыгы алып, битен сөртә башлады. Генералның тир белән бергә күзенә килгән шатлык яшьләрен сөртүе иде бу.

Берничә минуттан аэродром тынып калды.

Очу полосасында тигез сафларда торучы гвардияче очучыларга генерал, дулкынлануын сиздермәскә тырышып, речь сөйләде.

Полкның авыр сугышчан юлын искә төшерде ул, илебезнең азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен геройларча һәлак булган полкташларның исемнәрен атап чыкты.

Бөек Ватан сугышы чорында полк очучылары ирешкән җиңүләргә тукталып, дивизия командиры Ишмөхәммәтевне иң яхшы очучылар исемлегенә кертте.

«...Сезнең полк, — диде генерал, — татар егете Тамерлан Кәримович Ишмөхәммәтев кебек 188 тапкыр эффектлы сугышчан очыш ясаган геройларны тәрбияләп үстерде.

Ул берүзе дошманның егерме ике танкысын, кырык тугыз автомашинасын, хәрби йөк төялгән алтмыш өч олавын, тугыз бензин цистернасын, ундүрт тимер юл вагонын, биш дзотын, көчле нығытылган сигез ут оясын юк итте, алты катерын су төбенә җибәрде, җиде урында су аша кечү корылмаларын җимерде, утыз ике зенит орудиесен, егерме сигез кыр артиллериясе пушкасын һәм җиде үзйөрешле орудиене сафтан чыгарды. Һава сугышында бер истребительне бәреп төшерде, аэродромнарда ундүрт самолет яндырды. Аның төз бомба ударларыннан һәм пулемет утыннан дүрт йөзгә якын гитлерчы үзләренә кабер тапты.

Менә бу арифметика өстендә ныклабрак уйлап карагыз, иптәшләр. Безнең бер лачыныбыз гына да дошманга шулкадәр зыян китерде. Бу — батырлыкның чын үрнәге.

Барыгызга да зур рәхмәт, иптәшләр. Ә сиңа, Тамерлан Кәримович, аеруча рәхмәт. Синең кебек уллар үстергән татар халкына рәхмәт.

Командование сиңа Советлар Союзы Герое исеме бирү турында эш кузгатты»[1].

...СССР Верховный Советы Президиумының 1946 ел 15 май Указы белән батыр очучы Тамерлан Кәримович Ишмөхәммәтевкә Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелде.

Ул вакыттан соң күп еллар үтте.

Тамерлан яңадан әти-әнисе кайчандыр Татарстаннан китеп урнашкан Себергә әйләнеп кайтты.

Әнә ул, төрле приборлар, колбалар тезелгән озын өстәл артында ниндидер формулалар өстендә уйланып утыра. Акыллы кара күзләр, кырау төшә башлаган кара куе чәч, ак чырайлы йөз.

Ул әнә шул лабораториядә — Түмән индустрия институтында эшли.

Герой хәзер дә туган илгә хезмәт итә...

---

[1] Оборона министрлыгы архивы. 33 фонд, 793756 опись, 19 эш, 327—330 битләр.

# ТАТАР МӘДӘНИЯТЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН

## 1928 ел

**1 январь.** Татар сәхнәсенең күренекле артисты, Хезмәт батыры Мифтах Әпсәләмов үлде.

**23 январь.** Казанга В. Маяковский килде. Шагыйрь шәһәр хезмәт ияләре алдында хәзерге әдәбиятта яңа күренешләр турында доклад белән чыкты, үзенең «Хорошо!» поэмасын укыды.

**25—29 январь.** Казанда Яңалифнең I нче съезды эшләде.

**29 январь.** «Кызыл Татарстан» газетасында Галимҗан Ибраһимовның Дәүләт сәнгать фәннәре академиясенә член итеп сайлануы турында белдерү чыкты.

**15 февраль.** «Галимҗан Ибраһимов» исемле җыентык басылып чыкты. Классик әдипнең егерме еллык иҗат бәйрәменә багышланган бу җыентыкка Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, К. Нәҗми һәм башкаларның дистәгә якын мәкаләсе кертелгән.

**16 февраль.** «Кызыл Татарстан» газетасында Г. Нигъмәтинең «Иске мирастан файдаланырга кирәкме?» дигән мәкаләсе басылды.

**22 февраль.** Җәмәгатьчелеккә «Булат батыр» исемле беренче татарча фильм күрсәтелде.

**10 март.** Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык хезмәт бәйрәменә багышланган тантаналы кичә уздырылды. Әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында докладлар белән Г. Нигъмәти һәм профессор Г. Линсцер чыкты.

Юбилей кичәләре Ташкент, Чиләбе, Свердловск, Мәскәү шәһәрләрендә, шулай ук республиканың бик күп шәһәр һәм авылларында да уздырылды.

**29 март.** Казанның Зур театр бинасында М. Горькийның әдәби эшчәнлегенә 35 ел тулуга багышланган кичә уздырылды. Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында доклад белән Г. Нигъмәти чыкты.

**18 апрель.** Татар мәдәният йортында халык шагыйре Габдулла Тукайның үлүенә 15 ел тулуга багышланган зур кичә булды.

**16 майга кадәр.** Башкорт язучылары Д. Юлтый һәм Г. Хәйри Казанда булып киттеләр.

**12 июньгә кадәр.** Рус пролетариат әдәбиятының үсеше белән таныштыру өчен, Казанга Н. Тихонов, Н. Мещеряков һәм Роман килде.

Алар төрле предприятиеләрдә, клубларда булдылар, укучы яшьләр, эшчеләр, татар язучылары белән очраштылар.

**Июнь.** «Безнең юл» журналында шундый белдерү чыкты:

«Быелгы көздән башлап, «Яшь язучылар» оешмасы урынына ТАПП (татар пролетариат язучылары) оешмасы булачак. Шул эшне башлап җибәрү өчен, түбәндәге иптәшләрдән оештыру төркеме төзелде: К. Нәҗми, Г. Кутуй, Ш. Усманов, Гомәр Гали, И. Хәйруллин, Д. Фәтхи, Г. Минский, Мөбәрәкшин һәм Кәшфи».

**Июнь.** Шагыйрь Һади Такташ Астраханьда булып кайтты.

**9 июль.** Башкортстанның Баймак авылында күренекле татар драматургы Мирхәйдәр Фәйзи үлде.

**14 июль.** Казанга Үзбәкстанның яшь язучылары Гафур Гolәм, Зыя Сәгыйт һәм Имиҗановлар килде.

**Июль.** Х. Туфан ил буенча сәяхәткә чыгып китте.

**3 август.** Казанга Алексей Максимович Горький килде.

**7 август.** «Кызыл Татарстан» газетасында Г. Нигъмәтинең «Лев Толстой һәм Максим Горький» исемле мәкаләсе басылып чыкты.

**13 август.** Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы Галимҗан Ибраһимовка Хезмәт батыры исеме бирү турында карар кабул итте.

**7 сентябрь.** «Красная Татария» газетасында Гадел Кутуйның «Современное состояние татарской литературы» исемле мәкаләсе басылды.

**27 сентябрь.** Татар мәдәнният йортында ТАППның гомуми җыелышы булды.

**26 октябрь.** Ш. Камалның «Ут» пьесасын куеп, татар театры үзенең кышкы сезонын ачып җибәрде.

**Октябрь.** Татар дәүләт театры «Тамашачы» исемле журнал чыгара башлады.

**18 декабрь.** Театр бинасында Бөтенсоюз Яңалиф комитетының III пленумы эшли башлады.

**30 декабрь.** Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы басылып чыкты.

## 1929 ел

**11 январь.** Татар театры З. Бигиевнын «Олуг гөнаһлар» романы буенча эшләнгән яңа спектакль күрсәтте. Әсәрне сәхнәгә Вәлиев-Сульва куйган.

**18 январь.** Татар театрында «Югалган матурлык» (Һ. Такташ әсәре) спектакленең премьерасы күрсәтелде.

**23 февраль.** «Кызылармеец» газетасында Ш. Усмановның «Даладагы эшелоннар» исемле яңа әсәре басыла башлады.

**16 март.** Татар мәдәнният йортында яшьләр матбугатына багышланган кичә уздырылды.

**18 апрель.** Мәскәү Мәгариф йорты янындагы татар әдәбияты түгәрәге утырышында Мансур Крымов иҗаты тикшерелде.

**20 апрель.** Татар академия театрында Г. Камалның 30 еллык әдәби хезмәт бәйрәменә багышланган кичә уздырылды.

**22 май.** «Эшче» газетасында партия Үзәк Комитеты янындагы татар-башкорт бюросы һәм комсомол Үзәк Комитеты янындагы татар-башкорт бюросының «Татар пролетариат һәм совет язучыларына» ачык хаты басылды.

**26 майга кадәр.** ТАПП членнары Г. Кутуй, Г. Гали, Г. Нигъмәти Украина пролетариат язучыларының II нче съездында катнаштылар.

**9 июнь.** «Эшче» газетасында, «Пролетариат язучылары социализм ярышына!» дигән исем белән, түбәндәге игълан басылды:

«Бу эшне (ярышны — З. У.) Мәскәү пролетариат язучылары башлап җибәрделәр.

1. Мәскәү МАПП татар секциясе членнары М. Крымов белән А. Шамов хикәя язуда Ш. Усмановны чакыралар, М. Максуд — К. Нәҗмине чакыра;

2. МАПП татар секциясе көзгә, социализм ярышына багышлап, 10 табаклы әдәби җыентык бирә;

3. Секция членнары М. Крымов белән Муса Җәлил бер ел эчендә социализм ярышына багышлап бер әдәби әсәр бирүдә үзара ярышка керделәр».

**14 июнь.** Востоккино Татарстан тормышыннан иң яхшы сценарийга конкурс игълан итте.

**19 июнь.** Урал АППның татар-башкорт секциясе социалистик ярышка кушылуын белдереп чыкты. Секция членнары Уразмөхәммәтов — Толымбайскийны, А. Әхмәт — Г. Иделлене, Ганиев — М. Әмирне, И. Туктаров — Н. Бәхтияровны социализм ярышына чакырдылар.

**20 июнь.** Көнчыгыш педагогия институтының гыйльми советы Габдрахман Сәгъдине татар теле һәм әдәбияты кафедрасының профессоры итеп билгеләде.

**1 август.** «Красная Татария» газетасында профессор И. Бороздинның «О нацлитературе» исемле мәкаләсе басылды. Автор анда татар әдәбияты үрнәкләрен русчага тәрҗемә итү һәм бастырып чыгару мәсьәләләрен күтәрә.

**10 август.** Татар пролетариат язучылары ассоциациясе, татар язучылар җәмгыяте членнары һәм сәнгать көчләре тугандаш республикалар буйлап экскурсиягә чыгып киттеләр.

**Август.** Мәскәүдә «Октябрь баласы» исемле журнал чыга башлады. Редакторы — Муса Җәлил.

**12 октябрь.** Шәһәр партия оешмасы активының солтангалиевчелек мәсьәләсенә багышланган җыелышы булды.

**21 октябрь.** Мәскәүдә сәнгать академиясе янында татар бүлеге эшли башлады.



# ТАРИХ ҺӘМ ТАРИХЧЫЛАР

*(Профессор Р. И. Нәфигов белән әңгәмә)*

*Республикабыздагы тарихчылардан Рәфикъ Измаил улы Нәфигов эшчәнлеге киң җәмәгатьчелегебезгә дә, журнал укучыларына да яхшы таныш. Аның Мулланур Вахитов тормышына, татарлар арасында алдынгы иҗтимагый фикер үсүенә багышланган махсус хезмәтләре һәм газета-журналларыбызда басыла килгән мәкаләләре турында озак сөйләүгә мохтаҗлык юк.*

*Галимнең тормыш юлына килсәк, ул һәрбер яшь совет укымышлысының язмышын хәтерләтә. Рәфикъ Нәфигов 1928 елда Уральск шәһәрендә дөньяга килә. 1951 елда туган шәһәрендәге педагогия институтының тарих бүлеген тәмамлый. Аның моннан соңгы тормышы һәм иҗат юлы Казан университеты белән бәйләнгән. 1954 елга кадәр шунда аспирантурада укып, кандидатлык диссертациясен яклагач, аны партия тарихы кафедрасында эшкә калдыралар. Педагогик хезмәте белән бергә, Нәфигов гыйльми-тикшерену өлкәсендә актив эшли. Һәм 1964 елда «Татарлар арасында алдынгы иҗтимагый фикернең тууы һәм үсүе» дигән тәмага докторлык диссертациясе яклый. Ә хәзер, 1963 елдан бирле, яшь профессор университетның партия тарихы кафедрасына җитәкчелек итә.*

*Күптән түгел, журнал редакциясе тапшыруы буенча, хәбәрчебез М. Госманов галим белән очрашып сөйләште. Түбәндә шул фикер алышудагы сораулар белән җаваплар тәкъдим ителә.*

РЕДАКЦИЯ

**1. СОРАУ.**

**Профессор, Сезгә революцион тематика бик якын. Бөек Октябрьга 50 ел тулу уңае белән бу өлкәдә республикабыз тарихчылары ирешкән нинди казанышларны аерата билгеләр идегез?**

**ҖАВАП.**

Мин бер гомум һәм төп казанышны махсус атар идем. Бу — соңгы елларда илебездә, шул исәптән Татарстанда да, тарих һәм башка иҗтимагый фәннәрнең җанланып китүе. Шуның нәтиҗәсе була-

рак, галимнәребез яңа-яңа актуаль темалар күтәреп чыгалар; эчтәлекле, фикергә бай хезмәтләр язалар. Бер генә мисал алыйк. Соңгы 4—5 ел эчендә генә безнең Казанда тарих буенча 6—7 докторлык, дисталәгән кандидатлык диссертацияләре якланды. Аларның һәрберсендә мөһим мәсьәләләр күтәрелеп, бай материаллар нигезендә яңача нәтиҗәләр чыгарылды. Димәк, көчләребез арта, колачларыбыз киңәя. Ялгыз карлыгач яз китермәгәндәй, бер-ике тарихчы да фәннең йөзен билгели алмый. Казаныш турында сүз чыкканда, мин менә шул гомум күтәрелүне күз алдында тотам. Игътибар итегез, югары квалификацияле кадрларның болай күмәкләшеп үсүләре элек бер дә күрелмәгән хәл иде. Бөек Октябрьның ярты гасырлык бәйрәменә республикабыз тарихчылары менә шундый гомум күтәрелеш, уртак казаныш белән киләләр. Алдагы еллардан өмет тагы да зуррак.

Аерым хезмәтләрдән исә мин тарих фәннәре докторы М. К. Мөхәррәмовның гражданнар сугышы тематикасына багышланган әсәрләрен канәгатьләнү белән укыдым. Шулай ук доктор А. К. Халиковның да китапларын махсус атар идем.

## 2. СОРАУ.

Әйе, казанышлар бар. Ләкин тикшерелмәгән, әле кул җитмәгән мәсьәләләрдән кайсыларын күрсәтер идегез? Шулай ук ерак узган дәвер, әйтик, феодализм чоры татар тарихының өйрәнелү дәрәҗәсе турында нинди фикердәсез?

## ҖАВАП.

Эшләнмәгән, хәл ителүне көтеп яткан проблемалар бик күп, әлбәттә. Тарих белгечләре генә түгел, тарих сөючеләр дә моны яхшы сизәләр. Алар санап бетергесез. Шулардан менә бигрәк тә кызыксындырганы дип, тарих фәненең методологиясен атар идем. Сүз тарих гыйлеменең үз законнары, аның үсү фәлсәфәсе турында бара. Гадирәк итеп әйтсәк, һәр фәннең гомум тикшеренү-эзләнү ысуллары булган кебек, шул фәннең аерым тармакларында да аларның үзләренә генә хас теоретик алымнары, практик чаралары бар. Ләкин бу мәсьәләләрне хәл иткәндә дә нигездә марксизм-ленинизм методологиясе ятуын кабат әйтергә кирәк.

Борынгы, шул исәптән феодализм чоры тарихының өйрәнелү дәрәҗәсенә килсәк, монда да көн кадагында торган мәсьәләләр җитәрлек. Татар халкының килеп чыгышы дисезме, аның милләт булып формалашуын аласызмы, ул халыкның культурасы, сәнгате һәм иҗтимагый фикеренең төрле дәверләрдәге торышы дисезме — бик күп, бик күп әле хәл кылынмаган мәсьәләләр. Шулай ук татар культурасының, татар язма әдәбиятының Идел буендагы башка халыклар тарихында нинди урын биләвен дә җентекләп өйрәнергә кирәк. Ә халыклар арасында культура мөнәсәбәтләрен өйрәнеп, теоретик гомумиләштерүләр ясап, практик нәтиҗәләр чыгарыр өчен безнең күпмилләтле Идел буенда мөмкинлекләр бик зур. Әмма бу өлкәдә без, тарихчылар, телчеләр һәм әдипләрнең, экономист һәм философларның, юристлар һәм сәнгать белгечләренең ярдәмнәренә бик мохтаҗбыз. Мәсәлән, әдәби үсү баскычлары тегәл һәм тагаен хәл ителмәгән кебек, татарларда Октябрьга хәтле дөньяга карашның эволюция баскычлары да тикшерелмәгән әле. Ә төрле дәверләрдә хөкем сөргән юридик нормалар мәсьәләсе исә бер дә кузгатылмыйча ята.

Кыскасы, эшләнмәгән, эшләүне көтеп яткан проблемалар бик күп. Кызганычка каршы, кадрлар җитеп бетми. Бу турыда ныклап уйларга, тиешле чараларын күрергә кирәк. Ә феодализм чоры татар тарихы буенча танылган зур белгеч Шамил Мөхәммәдьяровның Казаннан китүе исә аерата үкенечле. Аның бирдә булмавы бик нык сизелә.

## 3. СОРАУ.

Сез нигездә архив документлары кебек беренче кул чыганаклар өстендә эшлисез. Эзләнүчеләрне бу өлкәдә нинди специфик кыенлыклар көтү турында бераз сөйләмәссез микән?

## ҖАВАП.

Тарихчы мәгълүм материалларны яңача, тирәнрәк аңларга тырышу өстенә, тагын да яңа чыганаклар табарга тиеш. Алай булмаганда, җитди фән турында сөйләп тә торасы юк. Ә яңаны табу җиңел эш түгел. Китапханәләрдә, архивларда меңләгән, хәтта миллионлаган документлар саклана. Тик аларның барысы да фән өчен яңалык бирмиләр. Йөздән берсе, хәтта меңнән берсе генә чын-чынлап игътибарга лаек. Димәк, кочак-кочак, тау-тау документларны карап чыгарга туры килә. Гади генә күз йөртеп түгел, бәлки аңлап,

җентеклэп, тикшереп карарга кирәк. Кызыклы берәр мәгълүмат очраса, аның дөреслеген ачыклар өчен андый документларның ишен дә табарга кирәк. Кыскасы, атналар, айлар, хәтта еллар буенча бер мәсьәлә буенча эзләнергә туры килә. Шулай итеп, түземлелек, сабырлык, үз хезмәтеңә мәхәббәт һәм предметыңны белү шартларыннан тыш, вакыт проблемасы да килеп баса. Артык сүзмәс өчен бер генә мисал. Мәсәлән, бер Татарстан дәүләт архивындагы нигез фондлардан нибары 3—4 ен гена карап чыгар өчен, әгәр һәр көнне 12 шәр сәгатьтән берминди ялсызбәйрәмсез эшләсәң дә, 150 ел гомер кирәк булыр иде. Ә андый фондларның саны 3—4 кенә түгел бит! Димәк, вакыт, вакыт, вакыт.

Ул документларның начар почерк, авыр тел белән язылулары, һәм аларның үпкәгә каба торган зарарлы тузанга күмелеп ятулары турында сөйли башласам, сүз озакка китеп, җавабым зарлануга әверелеп калыр иде. Ләкин тарихчыны михнәт әҗере — уңышлар, табышлар, иҗади шатлыклар да көтә. Кайвакытларны бер генә документ синең айлар буе чиккән җәфаңны оныттыра. Мәсьәләнең бу ягын да онытмаска кирәк.

## 4. СОРАУ.

Әйе, шул иҗади ләззәт минутлары, ягъни тарихчы хезмәтенең поэзиясе турында да сөйләсәгез иде.

## ҖАВАП.

Беркадәре әйттем дә кебек. Сез «хезмәт поэзиясе» дип дөрес атыйсыз. Минемчә, тарихчы эшенең төп яме аның х е з м ә т булуында. Ягъни аның очраклы рәвештә кызыксыну, һәваскәрлек түгел, бәлки бер максатка буйсынган аңлы хезмәт булуында.

Ләкин чын тарихчы алдан ясап куйган рамкаларга яраклы материаллар чүпләү һәм сипләү белән генә дә канәгатьләнми. Алай гына булганда, тарихи, ягъни гыйльми ачыш дигән төшенчәгә берминди урын калмас иде. Димәк, тарихчы элек табылган һәм үзе тапкан материаллар, фактлар нигезендә иҗат итә.

Кызганычка каршы, бездә тарихчы хезмәтенең ямен-тәмен ачып биргән, ул хезмәтнең иҗат булуын аңлаткан һәм тарихчыларның да шатлана, кайгыра белә торган, алай гына түгел, гел сөенеп, көенеп яши торган гап-гади тормыш кешеләре булуын күрсәткән әсәрләр бер дә юк. Бәлки киләчәктә яңа Кәрим Тинчуриннар чыгып, безнең хезмәт турында да көлдерә-көлдерә күңелле итеп сөйләп бирерләр?

## 5. СОРАУ.

Әгәр мөмкин булса үзегезне соңгы вакытларда шулай мавыктырган табышлардан берәр мисал китерсәгез иде.

## ҖАВАП.

Мөмкин. Мәсәлән, без татарларның революцион хәрәкәтләргә катнашуын бары 1905 елдан башларга гадәтләнеп киттек. Ә казына торгач, азатлык өчен көрәш тарихыннан яңа сәхифәләр дә ачыла төште. Баксаң, XIX гасырның 70 нче елларында татар укымышлыларының вәкилләре «народниклар» хәрәкәтенә актив катнашканнар икән. Шулардан эшчәнлекләре моңарчы бер дә яктыртылмаган бертуган Даут һәм Ильяс Аитовларны алыйк. Моңарчы тикшерелмәгән архив документлары күрсәтүенчә, алар 1871—74 елларда рус булмаган халыклар арасында революцион әдәбият таратуда зур тырышлык күрсәтәләр. Даут Аитов, яшерен әдәбият булдырыр өчен, махсус Мәскәүгә дә бара, тапкан китапларын бер татар ямщигы аша яшертен рәвештә Оренбургка җибәрә. Патша хөкүмәте дә, әлбәттә, йоклап ятмый: ике бертуганны тотып төрмәгә яба. Аитовлар, утырып чыккач та, революцион юлдан тайпылмыйлар. Полиция надзорыннан калган документлар шуны күрсәтә. Ә 1878 елны Даут Аитов Франциягә качарга мәҗбүр була. Революцион эшчәнлеген ул Парижда да дәвам иттерә.

Минемчә, болар бик әһәмиятле фактлар һәм аларның ачылуын мин мөһим табышлардан исәплим. Болар турында бер мәкалә дә язып куйдым.

Форсаттан файдаланып, шуны да әйтәсе килә. Даут Аитовның соңгы язмышын ачыклый алмадым — документлар юк. Ләкин андый документларның халык кулында сакланган булуы бик ихтимал. Мәсәлән, Даутның үз балалары яки туганнары нәселләрендә. Әгәр шундый һәм башка характердагы материалларны җыюда, саклауда җәмәгатьчелегебез дә актив катнашса, татар халкының бай тарихын өйрәнү эше тагы да җанлана төшәр иде. Аитовлар турындагы документларның саны бер генә булмаган кебек, татар халкының Аитовлар кебек кыю уллары да аз булмагандыр. Ләкин аларны эзләргә, табарга кирәк. Бу мәсьәлә белән җәмәгатьчелегебез дә кызык-

сыныр дип уйлыйбыз. Ә халык кулында андый материаллар бик күп. Мәсәлән: хатлар, көндәлек дәфтәрләре, истәлекләр, газета-журналлар, борынгы фотолар. Алар югалмасыннар иде. Югалмасын, хәрап булмасын өчен аларны китапханәләргә, музейларга тапшырырга кирәк.

6. СОРАУ.

Сезнең хакта «полемика яратучан» диган фикер яши. Моңа үзегез ничегрәк карыйсыз һәм полемиканың нинди ен яратасыз?

ҖАВАП.

Үзең турында кистереп хөкем чыгаруы авыр. Шулай да, гыйльми дискуссия дәрәҗәсеннән төшмәгән конкрет бәхәсне беркем дә кире какмас дип уйлыйм. Фаразларга нисә чәйнәлгән догмаларга түгел, ә яңа фактларга нигезләнгән, яңа теоретик проблемалар күтәргән гыйльми дискуссия, минемчә, фәнне үстерүдә дә, яшь кадрларны чыныктырып тәрбияләүдә дә бик файдалы булыр иде.

7. СОРАУ.

Яшьләр турында сүз чыккач, тагын бер сорау туды. Сез, педагог буларак, студентлар укытуда, аспирантлар тәрбияләүдә актив катнашасыз. Тәҗрибәгездән чыгып, яшь тарихчыларда нинди сыйфатларны күбрәк күреп, ниндиләрен бер дә күрмәскә теләр идегез?

ҖАВАП.

Әйе, бездә аспирантлар күп укый. Аларның зур өлеше югары квалификацияле партия тарихы белгечләре булып җитлеготәләр. Мин аларда хезмәт сөючәнлекне, белергә теләүчәнлекне күбрәк күреп, тәкәбберлек һәм нигезсез масаюларны бер дә күрмәскә теләр идем. Партияле принципиальлек, гыйльми намуслылык һәм кыюлык исә чын тарихчыга һава белән су шикелле кирәк.

8. СОРАУ.

Киләчәктәге эш планнарыгыз белән уртаклашмассызмы?

ҖАВАП.

Планнар да, хыяллар да бар. Электән яратып эшләгән темаларым белән бергә Ленин темасы өстендә эшлим. Җыйналган материаллар шактый. Җыясылары тагы да күп. Ленин алар турында бәйнә-бәйнә сөйләп тору кирәк микән? Планнар турында җәелеп сөйләгәнче, шул планнарны тормышка ашыру өстендә эшләргә кирәк, минемчә. Куелган сорауларга да конкрет эш белән җавап бирәсе килә.

Локман Аитов

# АРТИСТНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ[1]

## ПЕРМЬДА

*(1919—20 нче еллар)*

Сентябрь аенда Пермь шәһәренә кайтып, атна-ун көн чамасы ял иткәч, мине Пермь губерна Советы каршындагы милләтләр бүлегенә чакырттылар. Пермь шәһәрендә татар кызылармеецлары һәм эшчеләре өчен клуб ачарга телиләр икән, шул клубта театр труппасы оештырырга булганнар. Аны оештыру эшләрен миңа тапшырырга, шул труппаның житәкчесе итеп тә куярга уйлаганнар. Бу эшкә каршы булмавымны, ләкин үземнең Казан Мөселман Хәрби коллегиясе карамагында икәнлегемне, хәзерге көндә ял итүемне әйттем. «Безгә ризалыгыгыз гына кирәк, ә инде Казаннан сезне сорап алуны без үзебез карарбыз», — дигәч, мин ризалыгымны белдереп кайтып киттем.

Берничә көн үткәч, Казаннан Нәби Вахитов кул куйган рөхсәт кәгазе килде. Шуннан труппаны оештыру эшенә тотындык. Пермь шәһәрендә 1911 елдан бирле эшләп килгән үзешчән түгәрәк бар иде, ләкин 1919 елның башында, шәһәргә Колчак кергәч, клуб ябылып, түгәрәк таралган булган. Шул түгәрәккә 7—8 ел йөргән иптәшләрдән 16 кешене жыеп, шулар өстенә «Нур» труппасында эшләгән артисткалардан Рабига Галимованы да чакырып алдык. Шулай итеп, Советлар хөкүмәтенә ике яшь тулган көннәрдә Пермьда кызылармеецлар һәм эшчеләр өчен беренче татар труппасы төзелде. Элек шәһәрнең нәкъ уртасында бертуган Агафуровларның ике катлы зур таш кибете тора иде. Шул бинаны бераз ремонтлап, сәхнә эшләтеп, 300 кеше сыярлык зал ясадык. Патша заманында шушы кибеттә приказчик булып эшләгән егетләр, инде артист булып, «Татар кызылармеецларының һәм эшчеләренең Пермь шәһәр клубы»нда театр уйнарга керештеләр.

Беренче спектакль кызыл гаскәрләр һәм чакырылган кунаклар өчен бушлай гына уздырылды. Сәхнәгә Гафур Коләхметовның «Яшь гомер» әсәре куелды. Халык күп булды һәм спектакль шактый күтәренкелек белән узды.

Көннәрнең берендә, гомуми жыелыш ясап, ягъни артистлардан башка тагын костюмершалар, сәхнә эшчеләре, бутафор, парикмахер, контролерлар һәм башка хезмәткәрләр белән барлыгы 45 кеше жыелып, местком сайладык. Мине местком рәисе итеп билгеләделәр.

Икенче спектакль итеп Шәриф Камалның «Хажи әфәнде өйләнә» комедиясен куеп жибәрдек. Хажи ролендә мин, артист Жәләлетдин ролендә Хәйдәрский уйнады. Бу спектакль биш-алты тапкыр кабатланып куелды.

Тора-бара Галиәсгар Камал әсәрләреннән «Уйнаш», «Бәхетсез егет» драмалары, шулай ук «Банкрот» комедиясе куелды. Бу спектакльләрнең дә һәркайсысын тамашачы бик яратып каршы алды. Шуннан соң урындагы язучылардан Габдулла Гатауллин-Апушның «Ачы хакыйкать» дигән өч пәрдәлек драмасын куйдык. Аның авторы да Пермьныкы булганлыктан, шуның өсте-

---

[1] Истәлекләрнең беренче өлеше журналыбызның 1966 елгы 6, 7, 8 саннарында басылган иде. Дәвамын укучылар соравы буенча тәкъдим итәбез. *Ред.*



*Пермьда кызылармеецлар һәм эшчеләр клубы каршындагы труппа артистларыннан бер төркем*[1].

нә беренче бөтендөнья сугышы вакыйгаларын эченә алган бу әсәр ярыйсы гына көчле язылганлыктан, күп мәртәбәләр кабатланып, сезонда уңышлы спектакльләрнең берсе булды.

Һәр атнада бер мәртәбә кызыл гаскәрләр өчен һәм ял көннәрендә көндез балалар өчен бушлай, ә атнага ике мәртәбә эшче-хезмәткәрләр өчен акчага билет сатып спектакльләр куя идек. Шәһәрдән биш километр ераклыктагы Мотовилиха заводына аена ике мәртәбә, егерме-утыз чакрым ераклыктагы Башкултай һәм Кече Мул дигән авылларга аена өч-дүрт мәртәбә барып кайта идек. Аена егермедән артык спектакль куя идек.

Гомумән, Пермь халкы бу сезонда клубка яратып йөрде. Бу еллар сугыштан калган җәрәхәтләрне, җимерекләрне төзәтү вакыты, азык җитмәү заманы, төрле яктан интервентлар һөҗүм итеп торган чор булганга күрә, артистларга бик авыр шартларда эшләргә туры килде.

Ул елларны ягу мәсьәләсе дә бик авыр иде. Артистлар һәр ял саен өмәләргә чыгалар, кышкы салкыннарда урманнан ат белән утын китереп, аны кисеп һәм ярып клуб миченә үзләре ягалар иде. Менә шушы авырлыкларга карамастан, труппаның Хәйдәрский, Хәйретдин Хәнҗәров, Рабига Галимова, Мәрьям Вәлиева, Хәдичә Рәхмәтуллина, Әминә Шахмаева, Исхак Хәсәнов, Харис Шахмаев, Имам Ибраһимов, Госман Арсланов, Мәхмүт Хәсәнкәевләр составындагы бөтен бер коллективы, театр эшен чын күңелләреннән яратып, Пермь шәһәрендә беренче мәртәбә татар тамашачыларын мәгънәви азык белән тәэмин итүгә иреште.

Җәй көннәрендә халыкның клубка аз йөрүен исәпкә алып, клуб идарәсе артистларны киләсе көзгә кадәр таратып торырга булды. Апрель ахырында кышкы сезон ябылды.

Мин әтиемнең туган авылы Әгерҗегә кайтырга уйладым. Анда әтиемнән калган кечкенә генә йортка урнашып, бакчасына яшелчәләр утыртып, җәйне шунда үткәрү максаты белән, иптәшемне култыкладым да, пароходка утырып, Сарапулга юнәлдем.

## АВЫЛЛАРДА БЕРЕНЧЕ ТЕАТРЛАР

Сарапулда Мәгариф бүлеге мөдире Мөхәммәт иптәш Исхаков янына кердем. Алар Сарапул өязендәге татар авылларына аң-белем тарату эшләрен тәэмин итү өчен

[1] Рәсемнәр барысы да беренче тапкыр игълан ителә.

кучмә бер авыл труппасы оештырмакчылар икән.

— Сез бу мәсьәләгә ничек карыйсыз? Труппага ничә кеше кирәк булыр, аның өчен никадәр расход кирәк булачак? Әлбәттә, кереме булмас, чөнки спектакльләрне авыл халкына бушлай күрсәтергә туры киләр, — дип, ул миңа төрле сораулар яудырды.

Мин смета төзергә киңәш иттем. Бухгалтер янына кердек тә, бергәләп, беренче октябрьдан эшкә башлау нияте белән, 16 кешелек труппа өчен смета төзедек. Сметаны Вятка (хәзерге Киров) шәһәренә раслатырга җибәрделәр.

Бу мәсьәлә хәл кылынганчы, мин Әгерҗегә киттем. Анда үземнең йортка урнашып, бакчаны сукалап, яшелчәләр утырттым.

Көннәрнең берендә Әгерҗе яшьләрен җыеп, сөйләшеп, түгәрәк эшләрен кузгатып җибәрергә булдык. Авылда клуб та ачарга уйладык. Әгерҗенең нәкъ уртасында, зур урамда, Тимкин белән Газиев байларның янәшә салынган ике таш кибетләре бар иде. Ләкин янгын чыгып, аларның түбәләре һәм тәрәзә рамнары янып беткән. Без шул биналарны сорап райбашкарма комитетына бардык. Башта көлделәр: «Ул ташландык коры стеналар белән нишләмәкче буласыз? Аңар бик зур ремонт кирәк бит!» — диделәр. Без: «Барысын да үзебез рәтләрбез», — дигәч, ниһаять, ризалык бирделәр. Икенче көнне, бөтен Әгерҗе яшьләрен җыеп, балта, лом, кирәкләр алып, эшкә тотындык. Ике арадагы таш стенаны тишеп, зур залның бер башына сәхнә ясап җибәрдек. Ай ярым вакыт эчендә, бер кайдан да ярдәм алмыйча, ташландык кибет биналарын йөз илле кеше сыярлык клуб кыяфәтенә китердек. Әмма аның эчендә утырырга урындыклар да юк иде әле. Мин Сарапулга Мәгариф бүлегенә барып ярдәм сорадым. Аннан безгә йөз илле данә агач урындык, илле метр киндер, сәхнә өчен ун метр ак полотно биреп җибәрделәр. Шулардан декорацияләр ясадык, сәхнәгә һәм тәрәзәләргә пәрдәләр кордык, залга урындыклар тездек — ялт иткән клуб булды да куйды. «Мулланур Вахитов» исемен биреп, клубны июль аенда ачып җибәрдек. Даими рәвештә ике атнага бер мәртәбә спектакль куеп һәм концерт кичәләре ясап, Әгерҗе халкын клубка йөрергә өйрәттек.

Спектакльләр булмаган кичләрдә клубка яшьләр җыелып төрле уеннар оештыралар иде. Шулай ук Буби авылының драма түгәрәге килеп тә спектакльләр куя иде. Без дә Бубига барып уйнап кайта идек.

Шул рәвешчә сентябрьнең яртыларына кадәр эшләп килгәч, Сарапулдан мине чакырып телеграмма җибәрделәр: Вятка Мәгариф бүлеге труппа оештырырга рөхсәт иткән икән. Мин Сарапулга киттем.

Сарапул Мәгариф бүлегендә мине труппаның баш режиссеры итеп билгеләделәр. Труппаны оештыру һәм беренче октябрьдан эшкә башлау өчен әзерлекләр алып барырга куштылар. Мин декорацияләр ясатырга, сәхнә өчен пәрдәләр тегәргә куштым да, үзем труппага артистлар җыярга дип, Әгерҗегә киттем. Анда кайтып үзешчән түгәрәктән тәҗрибәлерәк ун кеше туплап, алар өстенә Буби авылы түгәрәгеннән баш рольләрдә уйнаучы Ибраһим Бәдретдиновны алып, Сарапулга юнәлдек. Анда баргач, тагын дүрт кеше табылды. Репетицияләр башладык. Коллективның гомуми җыелышын ясап, артистларның барысын да Сәнгать эшчеләре союзына алдык. Мине профуполномоченный итеп сайладылар. Коллективта өч партия члены — Мөхәммәтхан Вахитов, Габдрахман Шункаров һәм Базыйфа Шункарова, ике комсомолец — Габделхак Вахитов һәм Рокыя Әпсәләмовалар бар иде.

Беренче октябрьда Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» әсәрен куеп, Сарапул шәһәрендә «Беренче татар кучмә авыл театры»ның кышкы сезонын ачып җибәрдек. Совет хөкүмәтенең яшәвенә өч ел тулганда безнең труппа авыл халкына культура хезмәте күрсәтә башлады. Артистлар айлык хезмәт хакы белән тәэмин ителделәр, ә спектакльләр бушлай куела иде.

Тора-бара «Кемдә гаеп» дигән драма куелды. Хөкүмәт кешеләре тарафыннан төзелгән комиссия членнары да безнең эшне бик хуптадылар. Озакламыйча Г. Мөнасиповның «Әдәпсезләр арасында хиҗапсыз кыз»ын һәм концерт бүлеген әзерләдек.

Безнең барыбызны да Мәгариф бүлегенә җыеп, труппаның нинди максат белән оештырылуы, авылларда алып барачак эшләребез турында аңлаттылар. Халыкка тарату өчен газета, журналлар, плакатлар бирделәр, үзебезне дә җылы киемнәр һәм киез итекләр белән тәэмин иттеләр. Шуннан, биш атка төялеп, Тугызбый (Исәнбай) якларына чыгып киттек. Авылларда спектакль-концертлар куя, митинг-докладлар



*Режиссер Х. Шункаров һәм артистка Р. Тәкәнәева.*

үткәрә идек. Безгә бу эшләрдә урындагы укытучылар да булыша иде.

Көндезләрен, яшьләрне җыеп, газета, брошюралар тараттык, төрле лозунг, плакатлар ябыштырдык, стена газеталары чыгардык, әңгәмәләр үткәрдек.

Бу якларда клуб биналары бөтенләй булмаганлыктан, мәктәпләрдә такталардан гына сәхнә ясап уйнарга туры килә иде. Спектакльләребез гәрчә бушлай гына куелсалар да, халык аз җыела. Авыл Советыннан махсус кешеләр чыгарып, ул кешеләр өй саен кереп, җыелыш була дип, чакырып йөриләр иде. Картлар доклад беткәч тә кайтып китеп, яшьләр, күпчелеге балачагалар гына кала иде. Менә шундый шартларда айдан артык йөреп, кырыклап спектакль куйдык та Сарапулга кайттык. Кайткач, «Ачы хакыйкать» белән «Чын мәхәббәт» драмаларын әзерләдек. Аннары Әгерҗе, Алабуга районнарына чыгып киттек.

Ике айга якын йөреп, илледәп спектакль куйдык. Яз җитеп, юллар өзелгәч, бер-ике атна чамасы Әгерҗедә торырга туры килде.

Юл төшкәч, тагын Әгерҗе, Алабуга районнарында айдан артык вакыт йөрдек, утыз-кырык спектакль куеп, Сарапулга кире кайттык. Анда инде безгә махсус клуб бинасы бирелгән иде.

Кайткач, «Уйнаш» драмасы белән «Банкрот» комедиясен әзерләдек. Бу спектакльләрне инде билет сатып куйдык. Шуннан безгә унбиш көн ял бирделәр. Без, Әгерҗенекеләр, ял итәргә кайттык. Шушы җиде-сигез ай вакыт эчендә, бөтенесе ике йөздән артык спектакль куеп, утыз меңнән артык халыкка хезмәт күрсәттек.

Көннәрнең берендә Татарстан Мәгариф Комиссариаты исеменнән Газиз Айдарский миңа чакыру кәгазе җибәрде. (Газиз Айдарский ул вакытта Мәгариф Комиссариатында Татарстан театр эшләрен алып бара иде.) Казанга килгәч, Айдарский миңа беренче татар күргәзмә труппасы төзү, элек танылган барлык артистларны шул труппага җыю кирәклеге турында сөйләде. Ул мине дә шул труппага чакырмакчы икән. Бу эшкә ризалыгымны белдердем. Сарапул труппасының эшләрен режиссер Хуҗа Шункаровка тапшырырга куштылар.

## КАЗАНДА

*(1921—22 нче еллар)*

Август аеның ахырларында Казанга килеп, Проломный (Бауман) урамындагы Брестоль номерларыннан бер бүлмәгә урнаштым. Сентябрь аенда башка артистлар да килә башлады. 15 сентябрьдә барлык артистлар театрга җыелдык. Габдрахман Камал II, Нури Сакаев, Нәгыймә Таҗдарова, Гөлсем Болгарская, Касыйм Шамиль, Мохтар Мутин, Мөхәммәт Вәлишин һәм электән таныш башка артистлар белән күрештем. Астраханьнан килгән яшь артистлардан Габдулла Уральский, Гали Илья-



*Г. Айдарский Таһир ролендә.*

сов, Исмәгыйль Кугушов, Хәдичә Ханская, Сара Байкина һәм Җәлал Байкиннар белән таныштым. Минем өчен барысыннан да кызыграгы һәм иң күңеллесе сөекле язучыбыз Галиәсгар абзыйның, мәһабәт сакал-мыекларын кырып, сәхнәдә артист булып эшләргә килүе булды.

Барлыгыбыз утызга якын артист җыелган идек. Житәкчеләр эш планы белән таныштырдылар. Атнасына ике мәртәбә зур театр бинасында уйнарга тиеш булдык. Шуның өстенә атнасына бер мәртәбә эшчеләр районына барып уйнарга тиешлегебезне әйттеләр. Бу беренче танышу җыелышы шуның белән тәмам булды. Икенче көнне репетицияләр башланды. Сезон ачылгач, беренче спектаклебез Максим Горькийның «Мещаннар» әсәре (Галиәсгар Камал тәрҗемәсе) булды. Бу спектакльне сәхнәгә Касыйм Шамиль куйды, ярдәмче режиссер Исмәгыйль Кугушов иде. Бу әсәрне куярга рус театры режиссерлары Зотов белән Славянова да безгә ярдәм иттеләр.

Икенче спектаклебез Фәтхи Бурнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясе булды. Хан ролендә — Колмәмәт, ханча — Г. Болгарская, Таһир — Газиз Айдарский, Зөһрә — Сара Байкина, гарәп — Габдрахман Камал II уйнадылар. Әсәр өчен художник П. Беньков тарафыннан матур декорацияләр ясалды. Композитор Солтан Габәши яңа көйләр язды. Бу спектакль сезонда әллә ничә тапкыр кабатланды һәм театрга матди яктан зур файда китерде.

Чираттагы спектакльләрдән, русчадан тәрҗемә ителеп, «Диңгез артында» дигән әсәр куелды. Бу спектакль дә уңышлы үтте.

Аннары Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәтнең үлгәч терелүе» дигән комедиясен куйдык. Бу спектакль аеруча алкышлар белән барды һәм берничә мәртәбә кабатланып куелды. Бу әсәрне Фатих Әмирхан үзе сәхнәләштерде һәм һәр спектакльдә карап утырды.

Шуннан соң Гогольнең «Ревизор» комедиясен әзерләргә керештек. Городничий ролен Мохтар Мутин, хатыны ролен Болгарская, кызлары ролен Сара Байкина, Хлестаков ролен Газиз Айдарский, Осип ролен Колмәмәт, Добчинский ролен Вәлишин башкарды, Бобчинский ролендә мин уйнадым. Шулай даими рәвештә спектакльләр куеп, сезонны дәвам иттек.

Җомга көннәрендә куела торган спектакльләргә халык аеруча күп йөри, дүшәмбе көнне куелганнарында азрак була иде. Эшчеләр районында куелган спектакльләргә дә халык күп килми, чөнки бу заманда елга аръягында Җамалый Порховскийлар һәм агалы-энеле Бохарайлар тарафыннан оештырылган икенче татар труппасы эшләп килә иде.

Озак та үтмәде, Галиәсгар абзыйның «Хафизалам иркәм» пьесасы һәм бер пәрдәлек «Корсын, балам, бу кала» музыкаль әсәрләре дөньяга туды. Бу әсәрләрне халык бик яратты. Ачык әйтергә кирәк: нәкъ менә шушы елларда татар театры музыкаль әсәрләр кую белән мавыгып китте. Шунысы да бар: бу нәп чоры иде, музыкаль булса, кызык, көлке булса, шул җитте дип карадылар. «Порховой Фатих» яки «Прахуб-махуб» кебек түбән зәвыклы әсәрләр дә сәхнәгә менде. Ләкин алар озак яшәмәделәр.

Инде шуннан соң, чын опереттalardан Хаҗибековның «Аршин мал алан» әсәре дә татар сәхнәсендә куелды. Сара Байкина, Рәкыя Кушловская кебек яхшы тавышлы җырчылар булу аркасында, бу спектакльләр тамашачыда яхшы тәэсир калдырдылар. Җәлал Байкин, Габдулла Уральский, Гали Ильясов һәм Мөхәммәт Вәлишиннар кебек комик һәм җитди рольләрне башкаручы артистлар да бу спектакльләрдә үз-

ләрен халык алдында танытып өлгерделәр. Ул сезон, гомумән, тыныч кына, матур гына үтте. Чөнки коллективта бердәмлек, дуслык нык иде.

Шушы рәвештә апрель аеның яртысына кадәр эшләп, кышкы сезонны яптык. Мәгариф Комиссариаты артистларга договор нигезендә кышкы сезон өчен генә хезмәт хакы түли иде. Шунлыктан, кышка кадәр дип, труппаны тараттылар.

Җәйге айларда артистлар хезмәт биржасында учетта торырга яисә кечерәк кенә коллективлар оештырып, үз көннәрен үзләре күрергә тиеш булдылар.

### ХЕЗМӘТ БИРЖАСЫНДА

1921—23 еллар яшь Совет хөкүмәте өчен гаять авыр еллар иде.

Өч елдан артык сузылган беренче бөтендөнья сугышы өстенә инде ике елдан артык дәвам иткән гражданнар сугышы барышында илебез хуҗалыгы бик нык таркалган иде. 1921 елгы ачлык хәлне тагы да авырайтты. Шуңа күрә В. И. Ленин тәкъдиме буенча Совет хөкүмәте, партиябез яңа экономик политикага күчәргә мәҗбүр булды.

Рус байлары Казанның үзәк урамнарында төнге сәгать 3 кә кадәр сәүдә итә торган рестораннар ачтылар. Татар байлары да бу кәсептән читтә калмадылар. Атаклы Печән базарында «Болгар», «Амур», «Шам» һәм башка исемнәрдә милли рестораннар, «Ашханә», «Мосафирханәләр» ачып җибәрделәр. Анда милли музыка, милли җыр, милли блюдәләр башкарылып, бу биналарда төнге өчкә кадәр сәүдә бара иде.

Шул ук елларда, завод-фабрикалар туктау сәбәпле, хезмәт белән көн күрүче күп кенә кешеләр эшсез калдылар. Бу, әлбәттә, вакытлы хәл булды. Менә шундый эшсезләргә ярдәм күрсәтү өчен хөкүмәт хезмәт биржалары оештырды. Бу биржаларда һәр профсоюзның бүлекләре булып, алар үз членнарын хисапка ала һәм хезмәткә урнаштыру буенча чаралар күрәләр иде. Эшсез калган артистлар да биржада үз бүлекләрендә исәптә тордылар.

Беркөнне шулай хезмәт биржасына баргач идем, Габдрахман Камал II белән Сафа Габитовны очраттым. Җәйге сезонда эшсез калган артистлардан бер коллектив төзергә булдык. Шул ният белән Мещанская[1] урамдагы типография эшчеләре клубына киттек. Клубның мөдире артист Габдрахман Түтүрүш иде. Ул да безнең ниятне хуп күрде. Ләкин клублары бик кечкенә булганлыктан, якындагы бакчага җәйге сәхнә ясап, шунда спектакльләр куярга булдык. Икенче көнне, хезмәт биржасына барып, унөч кешелек коллектив тупладык. Аның җыелышын үткәреп, мине коллективның җитәкчесе, Габдрахман Камал II белән Сафа Габитовны режиссерлар итеп куйдылар да эшкә тотындык. Май аенда ук спектакльләр куя башладык. Атнасына өч мәртәбә уйный идек. Һәркемгә йөрергә мөмкинлек булсын өчен, билет бәяләрен арзан иттек. Афишаларны, плакатларны үзебез кулдан яздык, үзебез үк урамнарда ябыштырып йөрдек. Антракт араларында һәм танца вакытларында уйнар өчен музыкантларыбыз да бар иде. Болары инде клуб каршындагы түгәрәк членнары, ягъни типография эшчеләре булганлыктан, уйнаган өчен акча алмыйлар иде. Аренда өчен дә түләмәдек. Бары тик ут өчен генә түләттерделәр. Гомумән әйткәндә, барлык эшләрне үз көчебез белән эшләп башкарганлыктан, чыгым ягын мөмкин кадәр кысарга тырыша идек. Халык башта аз йөрсә дә, соңга таба ияләнеп китте, аеруча яшьләр күп йөри башлады. Ял көннәренә каршы булган спектакльләрдә халык аеруча күп була иде. Шул рәвештә көзгә чаклы эшләп килдек. Бу коллективның оешуы, ачлык елы булу сәбәпле, эшсез калган артистларның семьяларын көзгә чаклы туйдырып тору өчен дә ярады. Клубларда драма түгәрәкләренә җитәкчелек иткән иптәшләр ихмәк паегы алалар иде. Мин дә, инвалидлар клубына йөреп, паек алдым. Шушы авыр шартларда көзгә чаклы эшләп, сентябрь аенда бакчаны яптык.

Бу сезонда Габдрахман Камал II, Сафа Габитов, Мөхәммәт Вәлишин, Гази Салтиковский, Габдрахман Түтүрүш, Бакый Ибәтуллиннар, хатын-кызлардан Фәхрия Кудашева, Зәйнәп Исаева, Камилә Нигъмәтуллина һәм башкалар чын күңелләреннән бирелеп эшләделәр. Гомумән, коллектив бик бердәм булды.

### КАЗАН, 1922—23 ЕЛГЫ КЫШКЫ СЕЗОН

Көннәрнең берендә Газиз Айдарский мине Мәгариф Комиссариатына чакырды. Быелгы сезонга үзебез өчен махсус театр бинасы салынып бетәчәк (Островский урамда 1920 елны салына башлаган бина),

[1] Хәзерге Нариман урамы.

һәм анда татар спектакльләре һәркөнне куелачак икән. Труппа составын да бу сезонда көчәйтергә уйлыйлар, шуның өчен танылган артистларның барысын да тупламакчы булганнар. Астраханьнан Зәйни Солтанов белән Камал III не, Ташкенттан Тинчурин белән Әхмеровларны, Оренбургтан Габдулла Камал I белән Фатыйма Камаловаларны, тагын берничә артистны чакырганнар. Миннән дә үзем белән эшләгән артистлар турында сорашты, кемнәрне беләсез, шуларны тәкъдим итегез, диде. Мин Шакир Шамильский белән Маһирә Мирвәлиеваларны тәкъдим иттем. (Алар Пермьда кызылармеецлар клубында эшлиләр иде.) Иптәш Айдарский аларга шундук чакыру телеграммасы җибәрде.

Берничә көннән артистлар Казанга җыела башлады. Артистларга тору өчен Чернышевский урамдагы «Франция номерлары» әзерләнеп куелган иде. Октябрь башларында артистлар барысы да җыелып бетте. Үткән сезонда булган 30 артист өстенә янадан 20 гә якын кеше өстәлде. Алар арасында Әсгать Мәҗитов, Хөсәен Уразиков, Терегулов, Мифтах Әпсәләмов, Бари Тарханов белән Фәхрия Тархановалар да бар иде. Шулай ук Һади Такташ белән Тажи Гыйззәт тә килеп чыкты. Салих Сәйдәшевне дә Оренбургтан Казанга чакыртып алдылар. (Минем аның белән беренче мәртәбә танышуым әнә шул театрда булды. Моңарчы мин аны ишетеп кенә белә идем.) Барыбызны да җыеп, бер-беребез белән таныштырдылар да эш планын сөйләп аңлаттылар. Баш режиссер итеп Кәрим Тинчурин билгеләнде. Суфлер Һади Такташ булды. Шушы состав белән репетицияләр башлап җибәрдек.

Бу сезонда дублер системасы (артистларның рольләрне алмашлап уйнаулары) кертелде.

Үзебезгә аерым театр бинасы булгач, һәрбер цехка эшчеләр һәм хезмәткәрләр алырга туры килде. Коллективта барлыгы 100 гә якын кеше булды.

Бөек Октябрь революциясенең 5 еллык бәйрәме көнне «Кызыл Октябрь» исемендәге Татар дәүләт театрының кышкы сезонын «Юлсызлар» дигән пьеса белән ачып җибәрдек.

Бу спектакльгә халык күп җыелды. Чакырылган кунаклар да шактый иде. Салих хаҗи ролендә Мифтах Әпсәләмов уйнап, үзенең зур талант иясе икәнлеген күрсәтте.

Театрның үз мастерскоенда һәр спек-



*Артист Мифтах Әпсәләмов.*

такльгә диярлек махсус декорацияләр эшләтелә, шулай ук костюмнар һәм бутафория кебек нәрсәләр дә үзебездә махсус әзерләнә иде. Гомуман, бу сезонда Татарстан хөкүмәте татар театры өчен зур чыгымнар тотты.

Январь аена кадәр эшләп килдек. Спектакльләр һәр көнне куелгангадыр инде, халыкның йөрүе уртача гына булды. Музыкаль әсәрләр дә күренә башлады. Музыка турында сүз чыккач, Салих Сәйдәшев хакында да әйтеп китми булмый: аның татар театрына килеп керүе белән аеруча зур яңалыклар туды. Салих Сәйдәшев Казандагы музыкантларны үзе сайлап алып оркестр оештырып җибәрде, үзе язган көйләргә үзе дирижерлык иткәндә, театр бинасының салкынлыгы да онытыла иде.

Бу сезонда беренче положениедагы танылган артистлардан һәркайсына аерым бенефисләр үткәрелеп, икенче, өченче положениедәге артистларга ике-өч кешегә бер бенефис ясалды.

Минем дә бенефис спектаклем булып, үзем язган әсәрләрдән «Кызыл авыз» дигән өч пәрдәлек комедияне куйдык, билетларны да профсоюзлар, месткомнар, шулай ук кибетләр аша йөреп сатарга туры килде. Халык шактый күп җыелды, залда буш урыннар юк диярлек иде.

Шакир Шамильский үзен халыкка бик тиз танытты. Ул уйный торган спектакль-

ләрне халык күтәп ала торган булып китте. Баш рольләрдә уйнаучыларның фамилияләре афишаларга басылып чыга. Шуңлыктан, халык үзе яратканрак артистлар уйнаган көннәрдә аеруча күп килә иде. Шундый хәлләр була башлагач, репетицияләргә вакыт бик күп алынганга, дублер системасы үзеннән-үзе юкка чыкты.

Бу сезонда театрга күп кенә зур көчләр тартылган булса да, ул көчләрдән тиешенчә һәм тулы файдалана белмәү аркасында, эштә сүлпәнлек күренде. Артистларга чын мәгънәсендә образлар өстендә эшләргә мөмкинлек юк, чөнки һәр атнада берәр, хәтта икешәр премьера чыгарырга туры килә. Артист алган рольне берничә тапкыр укып чыга да, борып җибәрелгән машина кебек, сәхнәдә суфлер артыннан сүзләрен кабатларга гына мәҗбүр була. Шуңа күрә бу сезонда артистларның уеннарына дөрес бәя бирү кыен мәсьәлә. Тиешенчә әзерләнеп куелган «Юлсызлар» һәм «Сакла, шартламасын» спектакльләрендә уйнаган Мифтах Әпсәләмов кына киләчәктә чын сәхнә остасы булачагына өметләр тудырды.

### БУ СЕЗОНДА СӘХНӘГӘ КУЕЛГАН ӘСӘРЛӘР

Кәрим Тинчурин. «Соңгы сәлам», «Беренче чәчәкләр», «Сакла, шартламасын», «Йосыф-Зөләйха», «Назлы кияү», «Хан кызы», «Зәңгәр палас», «Американ», «Сүнгән йолдызлар» һәм «Казан сөлгесе».

Фәтхи Бурнаш. «Яшь йөрәкләр» һәм «Җирсезләр».

Афзал Таһиров. «Янгура».

Мирхәйдәр Фәйзи. «Галиябану».

Ибраһимов. «Башмагым».

Галиәсгар Камал. «Безнең шәһәрнең серләре».

Фатих Сәйфи. «Дошманнар» һәм «Ямьсез тормыш».

Шамил Усманов. «Беренче адым» һәм «Бай кызы».

Хаҗибеков. «Аршин мал алан».

Габдрахман Мангушев. «Бәхет эзләүчеләр».

Локман Антов. «Кызыл авыз» һ. б. лар.

### ТӘРҖЕМӘ ӘСӘРЛӘР

«Ревизор», «Буш бугазлар» (Г. Камал тәрҗ.), «Яхшы тегелгән кием» (Н. Кули тәрҗ.), «Сугым» (К. Гобәйдуллин тәрҗ.).

### ЭШСЕЗ АРТИСТЛАР

*(1923—24 еллар)*

Кышкы сезон ябылгач, артистлар, һавадагы кошлар кебек, азык эзләп, төрле якка оча башладылар. Астраханьнан килгән артистлар Астраханьга кайтып китте. Нури Сакаев белән Таждарова һәм Мутин — Уфага, Касыйм Шамиль — Буага юнәлде. Калган артистлардан: Шакир Шамильский, Мәһирә Мирвалиева, Габдулла Камал, Фатыйма Камалова, Габдрахман Камал, мин, бер суфлер һәм Казан музыкантларыннан Фәйзи Биккинин белән Габдрахман Биккининны алып, барыбыз 9 кеше булып, хезмәт биржасы аркылы рәсмиләштереп, Татарстан кантоннарына гастрольгә чыгарга булдык. Әгерҗе һәм Ижевскига баруыбыз хакында хәбәр җибәреп, җавап та алдык. «Килегез, яхшылап каршы алачакбыз», дип язганнар иде. Шиллерның «Юлбасарлар»ын, икенче программага — «Кайниш» (Г. Камал әсәре) белән зур гына концерт бүлеге әзерләп, мин бригаданың җитәкчесе, Шакир Шамильский режиссер булып, поездга утырып чыгып киттек.

Әгерҗе яшьләре безне вокзалда каршы алдылар. Өч-дүрт квартира да әзерләп куйганнар. Минем туган авыл, шуның өстенә ике ел элек эшләп киткән район да булгач, танышлар да күп иде. Икенче көнне, «Юлбасарлар» спектакленә афишаларны урамнарга ябыштыру белән ук, халык билет сорап квартирага килә башлады. Уен буласы көнне көндездән үк билетлар сатылып бетте. Зал шыгрым тулы хәлендә спектакльне башлап җибәрдек. Спектакль зур күтәренкелек белән барды. Халык алкышлар белән каршы алгач, артистлар берсеннән берсе тырышып уйнадылар. Бигрәк тә Габдулла Камал I Карл ролендә искиткеч яхшы уйнады. Сәхнә артында, буш вакытларыбызда, Биккининнар белән сокланып карап тордык. Минем Габдулла Камал I белән сәхнәдә очрашуымның беренче елы иде бу. Шуның өстенә ул, үткән сезонда үзенә лаеклы рольләр эләкмәгәнлектән, Казанда артык күренә алмады. Монда чын мәгънәсендә аның зур мастер, зур талант иясе икәнлеге беленде. Башка артистлар да ти ез, матур уйнадылар. Спектакль беткәч, халык аягүрә торып, артистларның фамилияләре белән кычкыра-кычкыра пәрдәне өч-дүрт мәртәбә ачтырдылар.

Ике көннән соң, икенче программабызны — «Кайниш» белән концерт бүлеген куйдык. Бу кичәбез дә зур алкышлар белән үтте. Бигрәк тә концерт бүлегендә Мәһирә Мирвәлиева, татарча, башкортча халык көйләрен җырлап, Фатыйма Камалова «Башмагым», «Аршин мал алан» әсәрләреннән өзекләр башкарып, халык күңелен яулап алдылар. Фәйзи Биккинин да скрипкада һәм кечкенә гармоньнарда уйнавы белән Әгерҗе халкының күңелен җәлеп итте. Габдулла Камал I белән Габдрахман Камал II шигырьләр, монологлар сөйләделәр, Фатыйма Камалова, махсус киемнәр киеп, татарча һәм үзбәкчә биеде. Аларны да кат-кат чакыра-чакыра ардырып бетерделәр.

Бер-ике көннән кабатлап «Юлбасарлар»ны куйдык. Халык бу юлы да күп килде. Хәтта бер караган кешеләр дә, Габдулла Камалның уйнавын аеруча яратканлыктан, яңадан килеп тамаша кылдылар. Шушы бер атна эчендә «Башмагым» әсәрен әзерләп өлгердек. Монысы да Әгерҗе халкына бик ошады. Габдрахман Биккинин рояльдә, Фәйзерахман Биккинин белән Әгерҗе егете Госман Әбтерәшитов икәүләшеп скрипкада уйнап җибәрделәр — нәкъ менә кыллы оркестр диярсең.

Казаннан чыгуыбызга бер ай чамасы вакыт үткәнне сизми дә калдык. Сборлар барыбызны да канәгатьләндерерлек иде.

Гомумән, бу йөрүебез һәркайсыбызның күңелендә гомергә онытылмаслык хатирә булып калды.

Габдулла Камал I белән Фатыйма Камалованың Әгерҗедә калуларын сорый башладылар. Аларның үзләренә дә Әгерҗе халкы бик ошаган булса кирәк, клубта эшләргә калырга риза булдылар. Ә без Казанга кайтып киттек.

Көннәрнең берендә Шамильскийга Уфадан хат килде. Анда балалар комиссиясе каршында татар-башкорт труппасы төзелүе, шунда эшләргә артистлар кирәклеге хакында язылган иде. Шакир Шамильский белән Габдрахман Камал II һәм Мәһирә Мирвәлиева Уфага китәргә булдылар.

Көз көне бу кышкы сезон өчен Татар дәүләт театры үзенә артистларны күп ала алмады. Шуңа күрә хезмәт биржасында учетта 20 гә якын эшсез калган татар артистлары бар иде. Шул артистларның гомуми җыелышларын үткәреп, эшчеләр районында эшчеләр өчен бер труппа оештырырга булдык. Елга аръягындагы Алафузов театрында эшчеләрнең үз коллективы эшләп ятканлыктан, без бу якта, Вахитов заводы эшчеләренә хезмәт күрсәтүне планлаштырдык. Завком да безне хуплап каршылады. Клубны атнага ике көн безгә бирергә булдылар. Без үнсигез кешелек коллектив белән эшкә башладык. Галиәсгар Камалны, Сафа Габитовны һәм мине режиссерлар коллегиясенә сайладылар.

Сезон ачылу көненә Галиәсгар абзыйның «Бәхетсез егет»ен куярга булып, рольләр бүлә башладык. Закир ролен Гази Салтиковскийга бирергә булдык. Кәрим бай белән Сәгыйть бай рольләрен бүлгәндә Галиәсгар абзыйга мөрәҗәгать иттек.

— Я, Галиәсгар абзый, син бу байларның кайсысын уйныйсың? — дип сорадык.

— Юк, иптәшләр, минем бу байларны уйнарга исәп юграк иде. Минемчә, Кәрим байны Аитов, Сәгыйть байны Сафа Габитов уйнарга тиеш, — дип җавап бирде ул.

— Ә үзең, Галиәсгар абзый, нинди роль уйныйсың? — дип сорагач, ул:

— Мин, иптәшләр, Васька ролен уйнарга кызыгып тора идем, сез тагы ни әйтерсез, — диде. Без каршы төштек:

— Галиәсгар абзый, Васька бер генә пәрдәдә керә, кечкенә роль, — дидек.

— Рольнең кечкенәсе, зурысы юк. Менә мин шул Васьканы чын үзе итеп уйнап бирим әле. Афишага да язгыз. Аның бер дә хурлыгы юк, — дип җавап бирде Галиәсгар абзый.

Репетицияләрне Фәхрия ханым Кудашеваларның квартирында үткәрә идек. (Тукай ур., йорт 58). Чөнки, беренчедән, күп кенә артистларга йөрергә якын, икенчедән, клуб бинасы да буш булмый торган иде.

Ике атна чамасы әзерләнгәч, бер уңайдан чиратта куелачак «Банкрот» әсәренә дә репетиция ясап, октябрь аенда элеккеге Крестовников заводы клубында «Эшче» труппасының кышкы сезонын ачып җибәрдек.

Бу районда татар эшчеләре күп торса да, даими эшләп килгән татар труппасы юк иде. Галиәсгар абзыйның «Бәхетсез егете» Казанда күптән куелмаган булганга, өстәвенә, Галиәсгар абзый үзе дә катнашкач, халык ифрат күп килде. Спектакль дә бик уңышлы үтте, артистлар үз рольләрен бик яхшы башкардылар. Галиәсгар абзый үзе рәхәтләнеп, кәефләнеп уйнады. Хәтта Васьканың йозак каерып ача торган тимер кисәген дә махсус эшләтеп алып килгән иде.

«Банкрот» комедиясендә Җамалины Сафа Габитов, Камалины Галиәсгар абзый уйнады, Сиражетдин ролен мин башкардым. Бу спектакльгә дә халык күп җыелды. Бер атна эчендә ике спектакльнең уңышлы узуы артистларның күңелләрен күтәрде.

Күп тә үтмәде, «Кемдә гаеп» драмасын һәм Әнәс Камалның «Хуҗа Насретдин әфәнде» комедиясен әзерли башладык. Чөнки драма белән комедияне алмашлап, җомга көннәрне драма, дүшәмбе көннәрне комедия куя идек.

«Хуҗа Насретдин әфәнде» театрга зур сборлар бирде. Шунысын да әйтергә кирәк, Ботан бакчасыннан ишәк алып тордык. Ләкин ул бала булды, баскычтан менәргә яратмый икән, күтәреп менгерә-менгерә җаннарыбыз чыкты. Ишәкне сәхнәгә керткәндә һәм чыгарганда да Хуҗа Насретдинны уйнаучы Габдрахман Кушай җәфаланып бетте.

Шулай матур гына эшләп килгәндә, декабрь аенда Галиәсгар абзый салкын тидереп авырып китте. Бу вакытларда ул бары тик өендә генә язып, шуннан килгән гонорарга гына яши иде. Җитмәсә без дә хезмәт биржасы каршындагы эшсез калган артистлар коллективы гына идек. Аңа авыру вакытында больничный лист буенча акча алырга беркайдан да мөмкин түгел иде. Без һәр көнне диярлек чиратлап барып, аның хәлен белеп кайта идек. Галиәсгар абзыйның моңа бик күңеле була: «Менә ул чын дуслар, чын иптәшләр шушындый вакытларда гына беленәләр икән!» — ди иде. Аның семьясы шактый зур, үзеннән башка хезмәт итәрлек кеше юк, балаларының иң олысы Әнәс техникумда укый, иптәше Әсма ханым да, йорт карап торганлыктан, беркая да эшли алмый... Менә шуларны истә тотып, көннәрнең берендә мин:

— Галиәсгар абзый, сине тизрәк сәламәтләндерәсебез, тагын бергәләп эшлисебез килә. Аның өчен сиңа тынычланырга, яхшы гына тукланырга кирәк. Синең файдага бер спектакль куеп җибәрсәк, ничек булыр икән? — дидем.

— Һай, Локман дус, син бик зур нәрсә уйлап чыгаргансың, бик зур рәхмәт. Ләкин башка иптәшләр моңа ничек карар? Аларның үзләренең хәлләре дә минекеннән артык түгел, — дип шикләнү белдерде. Мин барыбызның да бер теләктә икәнлегебезне әйттем. Аның бу эшкә ризалыгын сорадым. Галиәсгар абзый, балаларча шатланып:

— Алай булгач, мин ни әйтим, рәхмәттән башка бер сүзем юк, — диде.

Билетларны үзебез йөреп сатарга булдык. Галиәсгар абзыйның үз әсәрләреннән «Уйнаш» драмасын әзерли башладык. Бөтен чатларга афишалар ябыштырдык. Афишаларның күбесен Галиәсгар абзый улы Әнәс Камал бик матурлап язып бирде. Без, гомумән, афишаларны типографиядә бастырмый, үзебез кулдан гына яза идек. Шулай итеп билетларны кулдан таратып, калганнарын кассадан сатып, «Уйнаш» спектаклен куеп алдык.

Икенче көнне отчет ясагач, спектакльнең чыгымнарыннан арткан акчага бер потлы капчык белән ак он, сары май, йомырка, сарык ите, дөге ярмасы, кер сабыны һәм егерме метрлап мануфактура алып кайттык. Бер «барабыз» яллап, барысын да төяп, Галиәсгар абзыйның өенә киттек. Бу әйберләрнең һәммәсен дә өстәлгә өеп куйгач, Галиәсгар абзый, куанычыннан, каравытыннан ук тора башлады.


— Менә монысы артып калган акча, утын кирәк дигән идең, — дип, аңысын да биргәч, аның өчен шатлык өстенә шатлык булды.

— Кунакларны үз күчтәнәчләре белән сыйлыйк әле. Гомерләре озын булыр! — дип Әсма ханымга самовар куярга кушты. Чәй эчкәндә спектакльләребез хакында сорашты.

Озак та үтмәде, Гафур Коләхметовның «Яшь гомер» әсәрен куйдык. Йосыф ролендә мин уйнадым. Шуннан Галиәсгар абзыйның берәр пәрдәлек комедияләреннән «Кайниш», «Беренче театр», «Бүләк өчен» әсәрләрен әзерләп, «Комедияләр кичәсе» үткәрдек.

Галиәсгар абзый айдан артык авырып яткан урыныннан торып, сәламәтләнеп, эшкә йөри башлады. Безнең күңелләр тагын да күтәрелеп китте. Яңа дәрт белән эшли башладык. Галиәсгар абзыйның тәрекчәдән тәрҗемә итеп язган «Шәрык гыйшкы» дигән әсәрен куйдык. Шул вакытларда Дәүләт театрында артистларның бенифисләре үткәрелә башлады. Без дә, гомуми җыелыш ясап, коллективтагы артистларның күңелләрен күтәрү өчен, алардан үрнәк алырга булдык.

«Беренче бенифисне труппаның җитәкчесе иптәш Антовтан башлыйбыз», дигәч, «Апуш» — Габдулла Гатауллин әсәрләреннән «Ачы хакыйкать» дигән драманы әзерләп, 11 январьда минем бенифисне үткәрдек.



*Г. Камал үз кулы белән язган адрес.*

Гадәттәгечә Обкомсоюздан, хезмәт биржасыннан һәм башка аерым иптәшләрдән котлау барганда, Галиәсгар абзый, сәхнәгә чыгып, бөтен коллектив исеменнән үз кулы белән матурлап язылган адресны укып, кулымны кысты. Кочаклап, үбеп тәбрик итте. Бу бүләк минем өчен гомеремдә иң зур бүләкләрнең берсе булды.

Аннан соң Сафа Габитовның бенифисен үткәрергә булдык. Аның үзе тарафыннан Печән базары тормышыннан алып язылган «Перец-перец — сахарин» диган комедиясен әзерләп куйдык. Бу спектакль көнне клубның ишегеннән үтәргә мөмкин түгел иде, хәтта милиция чакырырга мәҗбүр булдык. Билетлар сатылып беткән булуга карамастан, халык һаман килә бирде, спектакль башлангач та урамда бик күп халык калды.

Моның төп сәбәбе шул иде: билетларның яртысыннан күбрәген Сафа Габитов танышлары арасында үзе таратып бетерде. Кассада калганнары озакка бармады. Аннары ул үзе Казан халкына мәшһүр булган

борыч сатучы озын абзыйның кыяфәтен ясап, плакат язып Печән базарындагы атаклы «Болгар» номерлары чатына куйган иде. Моны күреп, бөтен Печән базары халкы шаулады. Хәтта бу сатучы абзый үзе дә билет алып карарга килгән иде. Шул заманның атаклы «кырык тартмачысы»н Сафа Габитов үзе уйнады.

Бу әсәр сезонда кат-кат уйналды, һәрберсе аншлаг белән үтте...

Шуннан карт артисткаларыбыздан Фәхрия ханым Кудашеваның бенифисен ясадык. Шул арада Галиәсгар абзыйның яңа әсәре өлгерде.

«Алтын кармак» дигән биш пәрдәле, алты картиналы мелодрама иде ул. Бөтен коллектив белән укып чыгып, куярга әзерли башладык. Әсәрдәге иң җаваплы роль — каторжан Павлус роле — Галиәсгар абзыйга, аның энесе художник Альберт роле миңа бирелде. Бу әсәр яңа, беренче мәртәбә куелу өстенә безнең коллектив өчен зур гына әсәр булганлыктан, репетицияләрне күбрәк ясарга туры килде. Февраль аенда «Алтын кармак» әсәрен куеп, Галиәсгар абзыйның бенифисен үткәрдек. Бу спектакль өчен реклама аеруча яхшы эшләнде. Улы Әнәс белән бергә Галиәсгар абзый үзе пьесаның эчтәлегенә кагылышлы рәсемнәр ясап, матурлап 40—50 афиша язып китерделәр. Сафа Габитов плакатлар да ясап ябыштырды. Афишаларның башында «Халыкның яраткан язучыларыннан Галиәсгар Камал бенифисе» дигән сүз дә әллә кайлардан кычкырып торгач, халык гаять күп килде.

Галиәсгар абзыйның сәхнә бәйрәмен ихтирам итеп, шәһәрнең бөтен районнарыннан килделәр. Бу спектакльдә зал да үзенә бер аерым төс алган иде. Залда шәһәр интеллигенциясе, шулай ук редакцияләрдән килгән журналистлар, язучылар да күп иде. Спектакль бик яхшы, бик тигез, күтәренке рух белән уйналды. Артистлар сәхнәдә үзләрен бер зур бәйрәм үткәргәндәге кебек хис иттеләр. Өченче пәрдәдән соң бенифис хуҗасын котлау булды.

Редакцияләрдән, язучылардан, Обкомсоюздан, эшче труппасы коллективыннан, шулай ук Дәүләт театрыннан, аерым иптәшләрдән зур бүләкләр бирелде. Кыскасы, бу бенифис күңелләребездә тирән хатирә калдырды.

Галиәсгар абзый бу әсәрне Татар Дәүләт театры сәхнәсендә дә куеп күрсәтү теләгән белдерде.

Мин хезмәт биржасына барып, коллективның «эшсезләр фонды» файдасына бер кичә үткәрү теләгән аңлаттым. Мәгариф Халык Комиссариаты аша Татар Дәүләт театрын бер көнгә алып бирделәр. Тагын берничә тапкыр репетиция үткәреп, бу юлы афишаларны типографиядә бастырып, «Кызыл октябрь» исемендәге Татар Дәүләт театрының сәхнәсендә «Алтын кармак» әсәрен куйдык. Билетларны хезмәт биржасы аркылы саттырдык, залда халык тулы иде.

Калган артистларыбызның да бенифисләрен ясадык. Һәр артист үз бенифисенә моңарчы куелмаган яңа әсәр табарга тырышты, һәркайсы билетларны үзләре таратты, шуңа тамашачылар һәркайсына күп җыелды.

Көннәрнең берендә, Сәнгать эшчеләре союзының төзелүенә биш ел тулу уңае белән, бөтен Татарстан күләмендә юбилей үткәрү өчен 12 кешелек комиссия оештырылды һәм шул комиссиягә мине дә сайладылар. Бу комиссия Союзның биш еллык тарихына карата җыентык төзеп бастырды. Зур театр бинасында юбилей кичәсе үткәрде.

Мәнә тагын яз килеп җитте. Репертуарны бераз үзгәртеп, Галиәсгар абзыйның музыкаль әсәрләреннән «Хафизалам иркәм»не куйдык, аннан «Комедиянләр» кичәсе үткәрдек. Минем «Мөгезле ир» комедиясен дә куеп алдык. Шулай итеп, апрель аеның ахырында «Эшче труппасы»ның кышкы сезонын яптык.

«Эшче труппасы» — Казанда өченче труппа булганы хәлендә — бу сезонда барлыгы 60 ка якын спектакль күрсәтте.

Былтыр Уфага киткән артист-артисткалардан: Шакир Шамильский, Мәһирә Мирвәлиева, Габдрахман Камал II, Нури Сакаев, Нәгыймә Таждарова һәм Мохтар Мутиннар инде Казанда иделәр. Бари Тарханов бу вакытта Буада иде. Ул анда Бари Болгарский, Зөләйха Багдановалар белән бер труппа төзегән иде. Астраханьнан Габдулла Уральский, Гали Ильясов һәм Камал III ләр килеп төште. Кыскасы, читләргә таралган барлык артист-артисткалар Казанга җыела башлады...

*(Дәвамы бар.)*

# УЯНГАН АФРИКА ҖЫРЛАРЫ

*240 миллион халкы булган Африка континентында иллегә якын дәүләт бар. Культуралары, телләре, тормыш-көнкүрешләре ягыннан бу халыклар бер-берсеннән нык аерылып торалар.*

*Африка халыкларын бергә берләштергән уртак яклар да юк түгел. Аларның кичәгесе авыр һәм шатлыксыз: коллык, камчы, кусәк һәм сыкранулар белән үтте.*

*Безнең көннәрдә Африка халыклары үз тарихларында кискен борылыш кичерәләр. Евразия илләрендәге революция давыллары тәэсирендә уянган африкалылар хурлыклы коллык богауларын җимерәләр. Хәзерге көндә 200 миллионнан артык африкалы азатлык яулап алды.*

*Африка халыкларының азатлык сөюче шагыйрьләре миллионлаган изелүче колларның ирекkә, якты киләчәккә омтылышларын чагылдырып, колонизаторларга каршы нәфрәт белән сугарылган әсәрләр иҗат итәләр.*

*Татарстан китап нәшрияты быел Африка шагыйрьләренең «Давыллы Африка» исемле шигырьләр җыентыгын басып чыгара. Журналның бу санында без укучыларны шул җыентыкка кергән шигырьләрнең кайберләре белән таныштырырга булдык.*

*Нәхид Әбү Зәһра*

(Мисыр)

## Өченче бомба ташланмас

### 1

**Нагасакидагы туганнар!**
**Хиросимадагы туганнар!**
**Сездә күкләр диңгезләрдәй**
**Зәңгәрләр...**

**Сездә дә бит хыялланган алар —**
**Бишек җырын сөйгән аналар.**
**Асылмалы чуен күперләр**
**Салават күпере төсле булганнар.**
**Сездә дә бит өмет яшәгән,**
**Балланып пешкәннәр чияләр.**
**Әйтерсең лә, серле тынлыкны**
**Беркайчан да бозмыйк, дигәннәр...**
**Чу!**
**Кинәт**
**Мин нәрсә күрәм —**
**Зәңгәр күкләр җиргә сыена.**
**Чыжлап үтә үлем чалгысы,**
**Җиргә кызыл чыклар коела.**
**Җилләр исә исереп, тилереп,**
**Мәетләргә абынып, сөртенеп.**
**Монда арый хәтта үлем дә,**
**Бу төш түгел...**
**Бар да өнемдә!**
**Ничек инде шунда:**
**— Җиңдек! — дип**
**Быргы кычкырталар як-якта.**
**Ничек итеп шунда, оялмый,**
**Роталар тезелә парадка!!**
**Көлләр оча чиксез бушлыкта,**

Җирне алар каплап алганнар...
Нагасаки, Хиросимада
Көл булганнар безнең туганнар!

Атом тузаннары
Пәрдә каплый аның йөзенә;
Җан биралмый яткан японның
Газиз гомере шунда өзелә.
Хәтта кояш сүнә утрауда
Дәһшәт чәчеп мотор улаугa;
Ракеталар күккә атыла,
Гәүдәләре гүя — акула!
Һәм өрәкләр монда җан сорап,
Яшел болын буйлап әйләнә.
Өченче бер бомба төшәргә
Әзерләнә өстә, күр, әнә!
Юк! Без аңа ирек бирмәбез!
Без башына аның җитәрбез!
Очып килгән афәт бомбасын
Күктә чакта ук көл итәрбез!
Без тынычлык яклап яшибез!
Без мәңгелек дошман сугышка!
— Юк, өченче бомба ташланмас!
— Юк, ташланмас өчене бомба!
Без ант итәбез, Хиросима!

2

Йолдызлар шаһит
Хиросимада...
Йолдызлар шаһит
Нагасакида.
Алар күрделәр
Үлем атавын;
Атауда сулар
Канга батканын.
Гөл-чәчәкләрдән
Калды көл генә.
Матур үйлардан
Калды көл генә.
Кеше гәүдәсе —
Агуланган көл...
Онытма моны,
Онытма, гомер!
Кешене кеше
Көлгә калдырган.
Җырләр куырылып
Көйгән янгыннан.
Кешеләр тумый
Янып үләргә!..
Яшим! дип туа,
Якты көннәрдә.

3

Шушы дөньяда —
Ачы дөньяда,
Шушы дөньяда —
Дәһшәтле дөньяда,
Шушы дөньяда —
Явыз дөньяда,
Кешеләр,
Таралмыйк!
Гел бердәм атлыйк!

4

Балкый йолдызлар
Нагасакида.
Балкый йолдызлар
Хиросимада...
Йолдызлар тыңлый
Безне тын гына:
— Юк, төшмәс кабат
Өченче бомба!

## *Деннис Осадебей*

(Нигерия)

# Тәвәккәллек

Җитәр күп сүз!
Юк, сөйләмик бүтән.
Җитәр, түздем!
Үз юлымнан китәм.
Киртәләр күп минем барыр юлымда,
Дошман яный уңымда һәм сулымда.
Мин, барыбер, үземнекен итәм!

Ват ишеген,
Кер китапханәгә.
Ач китапның
Бикләнгән битләрен.

Бел борынгы кулъязма серләрен,
Йотылып укы акыллы сүзләрен.
Син шулай ит — үзеңнекен эшлә!

Диңгезләр киң,
Акыл көчен бел син.
Әлифбаны
Балаларың белсен.
Галимнәрнең ачкан ачышларын,
Син белергә тиеш барын-барын.
Син шулай ит — үзеңнекен эшлә!

*Флавиен Ранаиво*

(Мадагаскар)

## Бер гашыйкның җыры

Сөйсәң мине шулай сөй —
Шәүләң кебек булмасын:
Ул була көндез генә,
Ә без булыйк гел бергә!
Сөйсәң мине шулай сөй —
Борыч кебек булмасын:
Ул эчне яндырса да,
Беләм тамак туймасын.
Сөйсәң мине шулай сөй —
Мендәр кебек булмасын:
Төнлә бергә дә бит сез,
Тик аерыласыз көндез!
Сөйсәң мине шулай сөй —
Дөге кебек булмасын:
Аны кабып йотасың
Һәм шундук онытасың!
Сөйсәң мине шулай сөй —
Балдай татлы булмасын:
Балны бар да ярата,
Күп бал күңел болгата!
Сөйсәң мине шулай сөй —
Булмасын төче сүздәй:
Ул бик татлы тоела —
Тик борчактай коела!
Сөйсәң мине шулай сөй —
Тәмле төш кебек булсын.
Өйләнсен аннан өнгә,
Бар дөнья онытылсын!

*Аманква Опоку*

(Гана)

## Елга

Мин — Елга,
Кып-кызыл Елга...
Башланам мин
Таулар арасыннан.
Койган җирем —
Тынгысыз океан.
Мин бу юлдан
Бүген генә түгел,
Одаманкома[1] чорыннан бирле агам...

---

[1] Одаманкома — Мәңгелек. Алла исеме.

Мин — Елга,
Елга мин...
Минде моннан
Бик күп еллар элек
Үзем сайлап авыр юлга чыктым...
Таш кыялар аша
Юл салганда,
Дулкыным белән
Барын юдым, ектым.

Мин — Елга,
Елга мин...
Миңа кешеләр,
Ял сәгатьләрендә,
Дулкынымда
Ял итәргә килә.
Балыкчылар миндә
Ятьмә сала.
Макталам мин,
Миңа рәхмәт ява.

Мин — Елга,
Елга мин...
Чакрымнарны артымда калдырып,
Кызу ярлар буйлап
Алга чабам.
Андый юл үтмәгән
Хәтта ата-бабаң!
Эчәргә дип кабак дуңгызлары
Суларыма төшкән чагында, —
Бернигә дә кирәк түгелсез, дим...
Көлеп ага бирәм тагын да.

Мин — Елга,
Елга мин...
Миндә леопардлар су эчәләр,
Крокодиллар мыжлап кайнап ята,
Буар еланнар, хәшәрәтләр...
Барысы миндә,
Барысын күрәм,
Барысын хәтерлим мин...

Мин — Елга,
Кып-кызыл Елга...
Мин йөк-йөк ташлар,
Алтын-көмешләр ташыйм;
Көн-төн юам,
Мин ярларны ашыйм.
Беләм: кайда рудалар бар
Ләкин кирәк түгел миңа алар!
Мин — Елга,
Мин ашыгам чиксез диңгезгә.

*Ә. Синегулов*
тәрҗемәләре.

— — □ — —

# *Рәссам һәм тормыш*





Татар совет язучыларының образлары өстендә эшләү теләге бик күптәннән инде мине тынгысызлап тора иде. Гаҗәеп шигырьләре һәм дөньяны таң калдырган батырлыгы белән Муса Җәлил күңелемне биләп алды. Шуңа күрә беренче эшемне мин аңа багышладым. Бу рәсемне берничә вариантта эшләп карадым. Башта Моабит төрмәсенең җимерелеп төшүен, шул фонда совет самолетларының узып баруын күрсәтергә уйлаган идем. Бу артык фотографик, иллюстрациягә тартым булганга күрә тагын да эзләнергә туры килде. Нәтиҗәдә мена шушы вариантына туктарлырга булдым. Ул — герой шагыйрьнең халык күңелендә мәңге калуын, Ватанга, фашизмның оясын туздырган Совет армиясенә аның саф мәхәббәтен әйткән һәм куркусыз көрәшче генә түгел, нечкә күңелле шагыйрь икәнен дә күрсәткән рәсем булырга тиеш иде.

«Кызыл ромашка» турында күп ишеткәнебез бар. Ул сәхнә һәм музыка әсәрләрендә дә күп тасвирланды. Көрәш символы булган ул чәчәк миндә дә шул тема өстендә эшләү теләге уятты. Берничә рәсем ясап кара-

дым, үземә ошамады. Озак эзләгәннән соң теләгәнемне таптым шикелле. Гариплән-гән, тапталган, ләкин егы-лып, изелеп калмаган, ти-мер-бетон, таш өемнәре ара-сыннан яктыга, кояшка ом-тылган чәчәк күңелемне би-ләде.

Галимҗан Ибраһимов пор-треты исә давыллы көрәш елларын үткән революцио-нерның ачык, саф йөзен, бетмәс энергиясен чагылды-расы килү теләге белән эш-ләнде.



Бөек Тукайның туган җи-рендә — Кырлайда берничә тапкыр булганым бар иде. Бер баруымда шулай кич-кырын авыл читенә чыктым. Гаҗәп бер сихри тынлыкта акрын гына кояш батып ба-ра. Шәфәкъ нуры фонында шагыйрьнең кара мәрмәр һәйкәле күренә. Әйтерсең лә шагыйрь исән. Ул Кырлай авылы кырына чыгып бас-кан да соклангыч табигать-не, күкрәп үскән бодай ба-суларын күзәтә. Шушы кү-ренеш һәм Тукайның үлмәс шигырьләреннән туган хис-ләр миндә бу рәсемне ясау теләге уятты.

Әнә шул пландагы эшем-не мин киләчәктә дә дәвам итәргә уйлыйм. Берничә еллар эзләнүемнең нәтиҗәсе булган бу рәсемнәремне исә «Казан утлары» журналын укучыларга тәкъдим итеп карарга теләдем.

М. РӘХИМОВ



*Хатип Госман*

# ХАЛЫКНЫҢ ҮЗЕННӘН

Узган ел Г. Халит «Бәхәссез һәм бәхәсле хакыйкатьләр»[1] исемле кызыклы мәкалә бастырды. Ул анда шигырь төзелешенә дә кагылып үтте. Без классик шигырьне төрки халыклар үз телләре нигезендә мөстәкыйль рәвештә үзләре иҗат иткән дибез. Халит моның шулай булуына шик белдерде. Ул ритмик ачык иҗекләр системасына корылган шигырь төзелеше — «аруз» төрки халыклар поэзиясенә «башлыча фарси-таҗик поэзиясе аша кергән», аннан «байтак үзгәрешләргә дучар ителүе шулай ук билгеле», ди. Ул «борынгырак чорда гарәп-фарси арузының билгеле бер формаларына төрки шигырьне хәтта *буйсындыру, көчләү* (курсив безнеке — Х. Г.) күренешләре күбрәк очраган» дип тә раслый. Халит үзенә ярдәмгә С. Айни белән З. Османовадан цитаталар китерә. Әмма бу урында цитата түгел, дәлил кирәк иде.

Без исә, дәлилләр китереп, үз карашыбызны якларга уйлыйбыз. Монда без барыннан да элек татар халкының мәкальләренә һәм табышмакларына таянабыз. Халык тудырган классик шигырь (аруз) орлыклары боларда, игътибар белән күзәтсәң, гаять бай һәм матур булып ачыла. Хәзер мондый күзәтү өчен мөмкинлек тә әйбәт. Нәкый ага Исәнбәт 1941 елда ук татар табышмаклары җыентыгын чыгарган иде. Соңгы елларда ул «Татар халык мәкальләре»нең өч томлыгын бастырып чыгарды. 1960 елда Х. Ярми «Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре» исемле җыентык бастырды. Барысын бергә алганда (Исәнбәт басмасының өченче томын без өйрәнеп елгермәдек әле), бу басмаларда гына да 30 меңгә якын мәкаль һәм табышмак бар. Шигырь төзелешен мәкаль һәм табышмакларга бәйләп тикшерүдә бу бик зур хәзинә, бик ышанычлы таяныч, һичнинди шик-шөбһә тудырмаслык дәлил чыганагы. Болардан тыш без, әлбәттә, Орхон-Енисей язмаларындагы, Мәхмүт Кашгаридагы мәкальләргә дә мөрәҗәгать иттек. Ихтыяҗ туганда казакъ мәкаль һәм табышмакларына да («Казактың макалдары мен мәтелдере». 1959. Алматы; «Казактың халык жумбактары». 1959. Алматы) күз салдык.

Мәгълүм ки, арузчылар бер төрки шигырь, шул исәптән бер татар шигыре, ритмик төзелешнең икесеннән тик берсендә генә язылa ала диләр: я ул «бармак», ягъни халык шигырендә генә язылa, ул чагында аңарда ачык иҗекләрнең нинди дә булса тәртибе күзәтелми, тик буынара ачыклыклары гына саклана, диләр алар, я шигырь «аруз»да гына язылa ала, ул чагында аңарда янәсе тик ачык иҗекләр тәртибе генә исәпкә алына, буынара ачыклыкларын саклауның кирәге дә, әһәмияте дә юк.

Без мондый карашларга каршы чыктык: «аруз» дигәне дә, «бармак» дигәне дә төрки халыкларның үзләре тарафыннан мөстәкыйль рәвештә иҗат ителгән, бу ике күренеш бер анадан туган игезәк, шуңар күрә алар аерым-аерым кулланыла алган кебек, бер үк шигырь эчендә икесе берьюлы да кулланыла алалар, дидек. Мәкаль һәм табышмакларга да без шушы ноктадан якын килдек, аларның тик берьюлы ачык иҗекләр тәртибенә дә, буынара ачыклыкларына да корылганнарын гына, анда да бу берлекне идеаль пөхтәлек дәрәҗәсендә булдырганнарын гына сайлап алдык. Андыйлары гына да меңәрләгән булып чыкты.

[1] «Казан утлары» журналы. 1966 ел. 4 сан.

Ике ритмик чараның бер үк мәкаль һәм табышмак эчендә искитәрлек табигыйлек белән берләшеп хәрәкәт итүе — бу кызыклы күренеш — безне халык әсәрләрендәге ритмик төзелешнең синкретиклыгы турында уйларга мәҗбүр итте.

Синкретик дигәнне, татарча әйтсәк, укмашулы диярго туры киләчәк. Кешелек җәмгыятенең яңарак барлыкка килгән борынгы чорында шулай ук яңарак кына барлыкка килгән сәнгать иҗаты өчен синкретизм, ягъни күп сыйфатларның бергә укмашкан булуы хас. Хәзерге заманда, мәсәлән, бер кеше шигырь яза, ләкин үз шигыренә үзе көй чыгармый, шигырьгә көйне бүтән кеше — композитор чыгара, ләкин композитор үз көен халык алдында үзе җырлап йөрми, җырны аерым таланты һәм җырлау тәҗрибәсе, җырлау осталыгы булган кеше — артист башкара. Борынгы заманда исә иҗатның бу аерым-аерым рәвешләре бергә укмашкан булган, аларның өчесен дә бер үк кеше берүзе башкарып биргән. «Синкретик» дигән сүз әнә шундый хәлне аңлата. Ләкин синкретизм үзе бик катлаулы. Аңарда соңрак һәрберсе аерылып чыгып, мөстәкыйль төстә күтәрелеп китәчәк бик күп элементлар, аларның башлангыч яралгылары күптөрле формаларда укмашып яши. Бу хәл шигырьнең төзелеш элементларына да, ритмик чараларына да кагыла. Мәкальләр белән табышмаклар да бик борынгы заманда ук, язу барлыкка килердән күп элек туган шигъри әсәрләр. Әлбәттә, аларга да төрле сыйфатларның укмашканлыгы хас булган. Без бу урында алардагы синкретизмның барлык якларына да түгел, бәлки ритмик төзелешләрендәге укмашып яшәгән сыйфатларга гына игътибар юнәлдерәбез.

Сүзгә керешкәнче элекке хезмәтләребездә аңлатылган нәрсәләрне кабат искәртергә, ә кайберләрен анькларга, тулыландырырга кирәк кебек. Иң элек ритмик буыннар турында. Мәкаль һәм табышмаклар арасында гел ачык иҗекләрдән генә яки, киресенчә, гел ябык иҗекләрдән генә торганнары бар. Мәсәлән,

Ашына күрә табагы,  
Балына күрә калагы[1].

Бу мәкальнең һәр тезмәсе, һәр ритмик буыны тик ачык иҗекләрдән генә тора.

Әкрен барган аттан узган.  
Иөгреп барган тайдан калган[2], —

дигән мәкаль гел ябык иҗекләрдән генә төзелгән («Тай» иҗеге ике урталыкта тора: ул ябык урынына да, ачык урынына да килә ала). Яки менә табышмак:

Ордым, бәрдем,  
Карнын ярдым[3].

Монда да гел ябык иҗекләр генә. Әлбәттә, бу күренешләр тикмәгә генә түгел, аларның бер хикмәте булырга тиеш. Гади колак белән тыңлауга беренче мәкаль кычкырулырак укыла, икенче мәкаль белән табышмак исә бераз мамыклырак, көрпә аваз беләнрәк әйтелә кебек.

Гел ачык иҗекләрдән генә, шулай ук гел ябык иҗекләрдән генә торган ритмик буыннар да мәкаль һәм табышмакларда индивидуаль роль уйныйлар, ягъни билгеле бер мәкальдә һәм табышмакта алар, тәртипле рәвештә бер урыннан тезелеп төшкәндә, тегеләрнең ритмик яңгырашына үзенчәлекле тәсмер кертә алалар. Мәсәлән, Юсуф Баласагуни тарафыннан үзенең «Кутадгу билиг» поэмасына (1069 елда язылган) кертелгән бер мәкаль:

Үкүш күрки тил ул,  
Бу тил күрки сүз,  
Киши күрки йөз ул,  
Бу йөз күрки күз.

Бирөдә беренче буынның беренче, урта буынның соңгы иҗеге ачык һәм өченче буын гел ябык иҗекләрдән гыйбарәт.

---

[1] Х. Ярми. Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре. 1960. 128 бит.  
[2] Шунда ук, 179 бит.  
[3] Табышмаклар. Төзүчесе Н. Исәнбәт. 1941 ел. 49 бит. Алга таба бу чыганаклар «Х. Ярми», «Табышмаклар» дип кенә әйтелер һәм шуннан соң битләре генә күрсәтелер.

Мәкаль һәм табышмакларда, бер ноктадан караганда, ритмик буыннар өч төрлегә бүленә: гел ачык иҗекләрдән корылганнары, гел ябык иҗекләрдән корылганнары, берсе ритмик ачык һәм калганнары ябык иҗекләрдән торганнары. Боларның һәр аерым төре бер мәкаль яки табышмакта гел үзе генә дә кулланыла ала, шулай ук алар бер табышмак һәм мәкаль эчендә ритмик яктан үзара гаять күркәм тәртиптә оешып та хәрәкәт итә алалар.

Борынгы мәкаль һәм табышмакларда, шулай ук борынгы шигырьләрдә бер иҗекле ялгыз сүзнең берүзе ритмик буын урынын биләп торган хәлләр дә очрый. Югарыда Баласагунидан китерелгән мәкаль — моның бер мисалы. Монда икенче тезмә ахырындагы «сүз», дүртенче тезмә ахырындагы «күз», бер иҗекле ялгыз сүз булуларына карамастан, бөтен бер ритмик буын алырга тиешле урынны билиләр. Бу җәһәттән Кашгари «Лөгате»ндә бик матур шигырьләр очрый:

Тикүр мәнин сәвеми
Билгәлигә ай:
Тынар кали ататса,
Ќыйсрак сыни тай[1].

М ә г ъ н ә с е: Син минем сүземне акыл иялəренə җиткер, әйт: колын тай булып үсеп җитсә, анасы — бия ял итәр.

Мондый күренеш борынгы төрки мәкальләрдә булгач, аның яңа заман төрки шигырьләрендә дә яңартылуы ихтимал.

Безнең элекке тикшеренүләрдә бу күренешләргә тиешенчә игътибар ителмәгән.

Татар шигырендә ритмик буыннарның күләме мәсьәләсе дә һаман өйрәнүне, аныклауларны сорый. «Татар шигыре» исемле китабыбызда (12—14 битләрдә) бездә ритмик буыннарның кыскасы 2 иҗектән, озыны 4 иҗектән тора дигән идек. Без моның ни өчен шулай икәнен татар телендә сүз күләме дүрт иҗектән артмавы белән аңлатырга тырыштык. Бу хәл һәрьяклап тикшерелергә тиеш. Үзбәк Байчура, мәсәлән: «Татар телендә басымсыз сузык авазларның озынлыгы ике дәрәҗәле, басымлы сузыкларның — дүрт дәрәҗәле»[2], — ди. Бездә ритмик буын күләме, бәлки, чыннан да шушы дәрәҗәләр белән билгеләнәдер. Бер ритмик буын ул — бер ритмик дулкын. Бу дулкын, бәлки, төрле озынлык дәрәҗәсендәге иҗекләрнең бер-бер артлы билгеле тәртиптә тезелеп килүләреннән тора торгандыр. Чыннан да шулай икән, сузыклар озынлыгында бишенче дәрәҗә булмагач, ритмик буынны биш иҗеклегә кадәр сузарга нигез дә калмый дигән сүз, дүрт иҗектән соң аларга кереп беткән дәрәҗәләр тәртибен яңадан кабатларга, ягъни яңа ритмик буын тезергә генә мөмкин була.

Бер ритмик буын составына, әйтик, бер ачык, өч ябык, ягъни дүрт иҗек керген, ди. Болар озынлык ягыннан берсе икенчесенә тиң була алмаска тиешләр, аларның дүртесе дүрт үлчәмле булса кирәк. Ике ачык, ике ябык иҗек булганда да, аларның дүртесе дүрт дәрәҗәле булырга тиеш.

Димәк, безнең шигырь тезелешен нигезенә җитеп аңлатыр өчен, ритмик буынның материаль составын, аңардагы иҗекләрдән һәрберсенең хас үзенчәлеген төгәл белергә кирәк. Моны исә эксперименталь фонетика гына башкара алачак.

Элекке тикшеренүләребездә искә алынмаган тагын бер мөһим күренешкә тукталырга кирәк. Бусы татар телендәге тартык авазларның табигатенә кагыла. Элекке язганнарыбызда бернинди ябык иҗек тә ритмик ачык иҗекне алмаштырып килә алмый, дигән кискен фикер уздырылган. Ләкин яңа тикшеренүләр аерым шартларда, аерым урыннарда ритмик ачык иҗек урынына ябык иҗек тә килә алуын, моңа карап ритмның бозылмавын күрсәттеләр. Менә бер мисал:

Күлдә йөзгән коңгыр каз
Чүл кадерен белмидер,
Чүлдә йөргән дуадак
Күл кадерен белмидер[3].

[1] М. Кашгари. Дивани легатит төрк. Ташкент. III том, 173 бит. Алга таба «Кашгари» дип кенә әйтелер һәм томы, бите күрсәтелер.
[2] У. Ш. Байчура. Звуковой строй татарского языка. ч. I, 1959. стр. 59.
[3] Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. I том. 617 бит. Алга таба «Исәнбәт» диелер һәм томы, бите күрсәтелер.

Мәкальнең ритмик схемасы $\cup + \cup\cup$ $\cup + \cup$ буыннарыннан тора. Беренче тезмәдә ритмик ачык иҗек урынына «гыр» иҗеге килгән. Шулай да ул ритмны бозмый, ритмик ачык иҗек функциясен үти.

Үзбәк Байчура, «ахун» сүзен экспериментальь юл белән тикшереп, «хун» иҗеге ачык, дигән нәтиҗәгә килгән. Ул ачык иҗекнең «Н» авазына бетү очраклары берничә, дип күрсәтә[1]. Шигырь төзелешен тикшергәндә без дә шундый ук хәлләргә очрадык: Л, М, Н, Р авазларына беткән иҗекләр кай урыннарда ачык иҗекләрне алмаштырып киләләр, һәм моңардан шигырьнең ритмы бозылмый. Бу авазларның хасиятендә, тартык булуларына карамастан, сузыла яки кыскара алу сыйфаты да булса кирәк, күрәсең. Сузык авазга ялганып килгәндә алар гүяки үзләре сузык аваз белән бер булып китәләр дә сузыкның агышын кисеп, бөтенләй ябып, биклап куя алмыйлар.

Шигырь төзелешендә, сирәгрәк очракларда булса да, шундый ук рольне уйнаучы тагын 4—5 аваз күренә. Болар К, Т, Ш, З, П. Мәсәлән, С. Хәкимнең «Колын» шигырендә беренче буыннарда 36 һәм рифма булып килгән соңгы буыннарда шулай ук 36 ритмик ачык иҗек булырга тиеш. Шулардан беренче буыннарда Л, Н, Р авазларына бетеп тә, ритмик ачык иҗек урынына килгән ябык иҗекләр — 6, К авазына беткәне — 1. Рифма булып килгән баганада 36 иҗектән тик бер урында гына Т авазына беткән ябык иҗек (ат) ачык урынына килгән. Моны «Хат» шигыреннән алынган мисалда да күрергә мөмкин.

Яза ул: «Әле хәзергә
Мин үзем исән», диеп.
«Ташлама бала-чаганы
Сугышта үлсәм», диеп.
Вакыт — җәй ахры димме,
Яңгырлы көзме иде...

Биредә дә ачык иҗекне алмаштыручы ябык иҗекләр тик беренче баганада гына китерелгән, рифма булып килгән соңгы багана аларны кабул итми; чөнки рифма аваз, аһәң гармониясен таләп итүдә гаять кырыс, гаять усал, ул һичнинди диссонансларга, хәтта аз гына да бозуларга юл куймый, үзендә ачыкларны алмаштырып килгән ябык иҗекләргә дә урынны бик саранланып, бик саклык белән генә бирә. Әгәр ритмик ачык иҗекләр сузылулары ягыннан иң кыска иҗекләр дип фараз итсәк, әлеге авазларга беткән ябык иҗекләр үзләренең озынлыкларында, бәлки, аларга якын торганнардыр. һәрхәлдә, биредә экспериментсыз кистереп әйтү кыен. Хәзергә без ритмик ачык иҗек урынына мондый ябык иҗек килгәндә схемаларда аны ярым плюс «┬» төсендәге өстәмә билге белән күрсәтергә тиеш булабыз, исемен дә шартлы рәвештә «урынбасар» диярбез.

Төп мәсьәләгә керешкәнче тагын бер нәрсәне ачыкларга кирәк.

Шигырь төзелешен ике яклап үзләштереп була. Берсе аның шигырь ритмикасын турыдан-туры тыңлап, колак белән ишетеп, күңел белән тоеп, ритмик дулкынны турыдан-туры үзенең яңгырашында ятка алу, үзең язганда сүзләрне шул ятка алынган ритм җаена сала бару. Без моны т о й г ы, х и с с и з е м л ә в е белән өйрәнү, үзләштерү дияр идек. Бу өйрәнү кешедә бик иртә, аның теле ачылгач та башлана. Шул чагында ук ул һәртөрле ритмлы сүзләр, такмаклар, аннан җырлар ота һәм кулләнә. Бу аның хис һәм тойгыларында, эмоцияләрендә (күңел сизгечләрендә) турыдан-туры аваз аша ритм тану сыйфатларын тәрбияли, үстерә, бу өлкәдә аның күңел сизгечләренә күнекмә бирә. Мондый очракта кеше ритмны турыдан-туры җанлы матурлык белән гәүдәләнешендә, яшәешендә таный һәм үзләштерә. Шигырьләр ятлау, җыр өйрәнү, шигырьләрне үзең яза башлау бу сыйфатларга аерата куәт бирә. Табигатеннән үк көчле талантка ия булган кешеләрдә шушы юл белән ахыр чиктә гаять төгәл һәм нечкә сиземле ритм күнекмәсе, р и т м б е л е м е барлыкка килә. Бу эштә акыл, зиһен һәм аң бөтенләй катнашмый дисәк, тирән ялгышу булыр иде. Тормыш барышында хисапсыз күп мәртәбәләр кабатланган тойгы, хис хәрәкәтләре, әлбәттә, зиһенгә һәм аңга да тәэсир ясый баралар. Акыл, аң бу тәэсирләрне исәпкә ала, хәтердә беркетә, җыйный һәм бер бөтен тәҗрибә рәвешенә кертә килә, соңрак исә

[1] У. Ш. Байчура. Звуковой строй татарского языка. ч. I. Казань. 1959. стр. 59.

анда тупланган тәҗрибә контроль көченә әверелә. Бер тапкыр ишеткән ритмны икенче тапкыр ишетергә туры килсә, дөрес откан идемме икән дип, әлеге кеше бу икенче тыңлавы барышында ритм яңгырашын элек үз хәтерендә калдырган «күчергече» белән чагыштырып бара, ялгыш тапса — төзәтә. Бу хәл күп тапкырлар кабатланып, ритмның объектив яшәештәге камиллеге үзенең төп хасиятләрендә әлеге тыңлаучының субъектив байлыгына әверелеп җитсә, мәсьәлә тагын яңа төс ала: тыңлаучы инде шул ук ритмны төрле кешеләр башкарганда, дөрес башкара микән дип, аларның һәрберсенә контроль ясап тора торганга әйләнә. Әгәр үзенә башкарырга туры килсә, ул үзенең эшен дә, әлбәттә, шундый ук аң контроле астында алып бара. Аның бу соңгы эшендә ритмны тануда тулысынча хис һәм аң гармониясе барлыкка килә.

Халык иҗатында гаҗәеп гүзәл, төзелеше белән искиткеч пөхтә шигъри әсәрләр булуына хәйран калмыйбызмыни, сокланмыйбызмыни?! Аларның иң зур күпчелеге әнә шундый сәнгать белеме, шундый шигырь төзелеше белеме ярдәмендә чыгарылган. Халыкның сүзләрдән торган шигъри сәнгате генә түгел, көйләрдән торган музыка сәнгате дә шулай туган һәм шулай үсеп килгән. Азмыни халыкта үзенең идея тирәнлеге, көй-моң матурлыгы белән хәйранга калдырган, халыкча даһи әсәрләр, көйләр? Ләкин боларны да көй ритмы белемен хис, тойгы аша алган кешеләр иҗат иткән, аларда музыка теориясе белеме, нота укымышлылыгы булмаган, алар музыкаль ритмны тудыра торган чараларны фәнни анализ ээләп тапкан элемент итеп түгел, бәлки күңелгә тәэсир итә торган матур яңгырашлы аваз үрелмәләре итеп таныганнар, шулай үзләштергәннәр. Хәзер композитор килә дә, шул көйләрне тыңлап, аларны нотага күчерә һәм халык музыка чараларының да шул ук бер «музыкаль алфавит»ка сыеп бетә алуын ачып ташлый. Монда шунысын әйтергә кирәк: кече күләмле музыкаль әсәрләр иҗат итәр өчен хис, тойгы аша алган белем җитсә дә, катлаулы үрелмәләрдән торган, зур күләмле музыкаль әсәрләрне — симфонияләрне, операларны — язар өчен хис, тойгы белеме үзе генә җитми инде. Ул белем көче белән генә зур гомумиләштерүләр ясап булмый, катлаулы иҗат процессы белән идарә итәргә аның көче аз. Монда, үзеннән үзе билгеле, халыкның бөтен тарихи гомере дәвамында өлгерткән хис, тойгы белемен бу өлкәдә бөтен прогрессив кешелек тәҗрибәсе өлгерткән фәнни белем белән бергә бербөтен итеп кушарга кирәк. Шунсыз эш чыкмый.

Шигырьдә дә мәсьәлә шулай тора: үткән заманнарда иҗат иткән татар шагыйрьләренең иң зур күпчелеге хис, тойгы белеменә таянып эш иткән, хәзерге татар шагыйрьләренең дә күпчелеге шул юлны тота. Бу юллар начар түгел, ләкин берьяклы юл. Шушы берьяклылык шигырьнең уңышлы үсешенә билгеле күләмдә комачаулый, шигырь өлкәсендә халык тудырган байлыкны мөмкин хәтле тулырак файдалану эшен кыенлаштыра. Шуңа күрә безгә дә тойгы, хис белемен фәнни белем белән тулыландырырга кирәк.

Шушындый аңлатмалардан соң синкретизм, укмашканлык мәсьәләләренә кабат әйләнеп кайтырга мөмкин.

Хәзерге татар шигырьләре я ритмик ачык иҗекләр тәртибенә корыла да, буынара ачыклыкларын игътибарга алмый, яки, киресенчә, буынара ачыклыкларына корыла да, ачык иҗекләр тәртибен сакламый, дибез. Моның кайбер мисаллары элекке мәкаләләрдә, безнең «Татар шигыре» исемле китабыбызда китерелгән. Ләкин бик борынгы заманнарда, төрки халыкларының авыз иҗаты яңарак барлыкка килгән чакта, борынгы мәкаль һәм табышмакларда боларның икесе берьюлы яралган булса кирәк. Борынгы кешеләр буынара ачыклыкларын һәм ачык иҗекләрне, без хәзер схемага күчергән кебек, бусы монда, тегесе теге урынга туры килсен әле дип, акыл исәбе белән билгеләп эшләмәгәннәрдер. Алар мәкальнең яки табышмакның ритмын телдән әйткәндәге яңгырашына карап билгеләгән булсалар кирәк. Моның өчен мәкаль һәм табышмакның күңелдә сөенеч уята торган матур ритмик дулкынын алар әсәрне телдән әйтә-әйтә, аваз һәм интонация күркәмлеген кабат-кабат тикшереп караулар, кирәклесен тапканчы сүзләрне һәм аларның урыннарын, төрләнешләрен әле тегеләй, әле болай куеп, сынап караулар ярдәмендә эзләгәннәрдер. Ләкин кешеләр әйтелештә кирәкле ритмик дулкын табылуына, бу турыда үз-үзләренә хисап бирмәсәләр дә, сүзләрнең тигез-тигез кисәкләр (ритмик буыннар) булып бер тәртипкә

утырулары, ачык-ябык иҗекләрнең дә тигез-тигез вакыт аралыкларында шулай ук тәртипле кабатланып килүләре нәтиҗәсендә генә ирешкәннәр.

Шулай итеп, шигырь ритмик төзелеш чарасының икесе дә берьюлы бер үк мәкаль һәм табышмаклар карнында игезәк булып, бер-берләренә укмашулы — синкретик төстә бергә яралганнар. Аннан соң алар үскәннәр һәм, ниһаять, җитлеккәннәр. Үскән һәм җитлеккән! — әйтергә генә ансат: ләкин моңар килеп җиткәнче мәкальләр һәм табышмаклар ничәмә-ничә буыннарның телләреннән телләренә тапшырылып, йөз елларны, мең елларны кичкәннәр! Без генә хәзер, бу хәлнең өлгергән һәм сыналган нәтиҗәләренә таянып, җиңел генә әйтеп ташлыйбыз, әмма чынлыкта исә бу бик озак эшләнгән, әллә күпме меңнәрнең, миллионнарның гомерләрен, рухи һәм зиһен көчләрен үзенә алган. Төрки дөньяның варварлыктан цивилизациягә чыгуы, ягъни язу куллануга күчүе алдыннан мәкаль һәм табышмакларда синкретик шигырь төзелеше тәмам өлгереп җиткән булган дип уйларга кирәк. Язмада иҗат итә башлаган шагыйрьләр үзләренә туп-туры шул шигырьне күчереп алганнар. Моның шулай икәнен Мәхмүт Кашгаридагы мәкаль һәм шигырьләрне үзара чагыштырып карау раслый, мондагы һәр шигырь үзенең ритмик төзелеше ягыннан мөгаен кайсы да булса берәр мәкаль өлгесендә язылган булып чыга. (Бу хәл безнең «Татар шигыре» диган китабыбызда тикшерелгән.)

Сүз кыска һәм күргәзмәле булсын өчен, борынгы заманнан башлап, мәкаль һәм шигырьләрне, гасырдан гасырга тоташтыра-тоташтыра, язып чыгу яхшырак булыр дип уйлыйбыз. Башлыйк V гасырның кабер ташы язуыннан (ачык иҗек һәм аларны алмаштырып килгән «урынбасар»ларны симез хәрефләр белән билгелибез):

Аты Чур(а), отуз оглан,
Асыйг ачыйг адырылмыш,
Сизә талчыйг, әрән сизә
Оглан чур у — лаю калмыш,
Катуный то — лый калмиша...[1]

## XI ГАСЫР

Бу күк керсүн, кызыл чыксун.
Балык суда, күзе таштин.
Качыш булса, кая кермәс[2].

## ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕ

Яшең җитмеш, эшең бетмеш[3]
Гыйлемлек — нур, наданлык — хур.
Эчен ярсаң, әлиф чыкмас[4].
Җаның тынса, кулың тынмый,
Кулың тынса, җаның тынмый.
Тамак булмый тамук булмый,
Давыл булмый явым булмый[5].

## ТУКАЙНЫҢ «МӨНАФИКЪКА» ШИГЫРЕ

Җиһанның эс- сесен, салкын,
Бозын күрдем, карын күрдем.
Ниләр күрсә бөтен үксез,
Барын күрдем, барын күрдем.

Мәкальләр дә, Тукай шигыре дә +◡◡◡ ритмик буынына корылган. Шигырьдә бу буын бер тезмәдә (без тезмәне икегә бүлеп яздык) дүрт тапкыр кабатлана.

---

1 С. Малов. Памятники древнетюркской письменности, М.-Л., 74 бит.
2 Кашгари. I том, 342, 360, 350 битләр.
3 Исәнбәт. II том, 852 бит.
4 Х. Ярми. 156 бит.
5 Исәнбәт. I том, 265; II том, 650 бит.

Хәзер ◡+◡◡ ритмик буыннарыннан төзелгән мәкаль һәм шигырьләргә күчик, аларны да гасырдан гасырга тоташтырып языйк. Менә VII гасырдагы кабер ташыннан бер җөмлә:

Тәңридәки күн кә, йирдә—
Ки элимкә бөк мәдим [1].

«Күктәге кояшны, җирдәге илемне күреп туймадым», — дигән сүз була бу. XI гасырның Мәхмүт Кашгари лөгатеннән мәкальләр:

Ач нә йимәс, тук нә тимәс.
Эт жакыйри атка тәкир.
Ат жакыйри эткә тәкмәс [2].

### ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕ:

«Кил» димәк бар, «кит» димәк юк.
Бирсәләр ал, суксалар кач.
Кышкы көннәр җәйне әйтер.
Җәйге көннәр җайны әйтер.

Син пәригә мин пәри кил- гән кәри [3].
Ирнең уңма- ганы икмәк- сез булыр.
Хатын уңма- ганы күлмәк- сез булыр.
Яхшы хатын яман ирне ир итәр.
Яман ир ях- шы хатынны жир итәр [4].

### Н. ИСӘНБӘТНЕҢ

### «КОММУНА ТИМЕРЛЕГЕНДӘ» ИСЕМЛЕ ШИГЫРЕ:

Һәй, егетләр! Без дә гайрәт, бездә рәт!
Бездә бар эш, бездә бар көч, бездә дәрт.
Бәр тимер кыз- ган чагында! Бәр дә бәр!
Актарылсын бар тәхетләр зир-зәбәр!

Бу һәр тезмәдә өчәр буынлы мисаллар булды. Хәзер дүртәр буынлысыннан китерик (һәр тезмәне ике юлга бүлеп язабыз).

### XI ГАСЫР:

Булмадыйк нәңгә сәвинмәң,
Билгәләр ани йирар [5].

### ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕ:

Бер болыттан боз да явар,
Кар да, яңгыр да явар [6].
Син дә мулла, мин дә мулла,
Атка печән кем сала? [7].

### ТАБЫШМАК

Бер атасы, бер анасы
Ничә йөз мең баласы! [8].

---

[1] С. Малов. Енисейская письменность тюрков. М.-Л., 1952. 22 бит.
[2] Кашгари. I том, 108, 343 битләр.
[3] Х. Ярми. 59, 64, 41, 190 битләр.
[4] Исәнбәт. II том, 223, 220 битләр.
[5] Кашгари. I том, 396 бит.
[6] Исәнбәт. I том, 505 бит.
[7] Х. Ярми. 203 бит.
[8] Табышмаклар. 32 бит.

## С. РӘМИЕВ ШИГЫРЕ

Әй хатыннар галәме, сез
Ник наданлык дәрьясы?
Дәрьяңызда баткан, үлгән
Бар татар зат баласы.

## ТАКТАШ ШИГЫРЕ

Төн. Ерак күкләр караңгы,
Йоклый тынлыкта җиһан,
Йоклый җир, йоклый акыл, йоклый мәхәббәт һәм иман.

Менә сезгә төрки һәм классик шигырьнең («аруз»ның) моннан мең ярым ел элек башта ташка, соңгарак кәгазьгә язып беркетелгән үрнәкләре! Әйтергә генә ансат: ташка язган һәм мең ярым ел! Боларның дөреслеген, бу хакыйкатьне кем инкарь итә алыр? Кире кагарга кемнең кодрәте җитәр? Язуда беркетелеп, безнең заман өчен сакланып калыр хәлгә кергәнче, — ул, аңа хәтле, халык хәтерендә күпме гомер, тагын ничә мең ел яшәде икән? — анысына хәтта безнең күзебез дә җитми.

Мәкаль һәм табышмак өлгесе, язма шигырьгә күчерелгәндә, әлбәттә, орлык, нигез итеп алынган, шагыйрьләр аны үстергәннәр. Болай эшләү бик табигый. Чөнки мәкаль һәм табышмак кече күләмле, ә язма шигырьләр — зуррак күләмле әсәрләр. Дөрес, күп очракларда орлыкны үстерү, кечене зурайту мәкальдәге тезмәләр санын арттыру белән генә дә эшләнгән. Мәсәлән:

Килем- китем бар,
Үлем- җитем бар[1].

## С. САРАИ

Камәр йөзеңдән
Булур мөнәүүәр,
Шәкәр сүзеңдән
Килүр мөкәррәр.

Сәйфи Сараиның (XIV гасыр) бу шигыре биш строфадан тора, аның һәр тезмәсендә, мәкальдәге кебек үк, +∪ +∪∪ рәвешендәге буыннар тәртибе кабатланып бара. Монда буынара ачыклыклары белән ачык иҗекләр системасы икесе берьюлы бер үк шигырьдә кулланылган. Бу — ритмик төзелеш принципларының укмашканлыгы, синкретизмы.

Цивилизация заманында иҗтимагый тормыштагы мөнәсәбәтләр күпьяклап үсеп китә, кешеләрнең холык-фигыльләре, уй-тойгылары, күңел ихтыяҗлары катлаулы төс ала. Бу хәл шигырьнең дә тармакланып үсүен сорый, укмашканлык сүтелә башлый, шигырьдәге аерым сыйфатлар, чагыштырмача мөстәкыйльлек алып, үзләренчә үсеп китәләр. Ритмик төзелештәге ике принцип та бер-береннән аерыла, көрәсең, бер шигырьдә аларның икесеннән берсе генә кулланыла башлый. Бу бүленешнең үзен нәрсә мәҗбүр иткән? Хәзер кистереп әйтүе кыен. Фараз итәргә генә мөмкин. Хәзерге көндә көйгә җырлана торган татар халык җырларын алсак, аларда ачык иҗекләрнең тәртибе элекке сакланууын, кагыйдә буларак, очратмыйбыз (чуваш халык иҗатында бу иса — киресенчә). Татар җырларында ритм нигезен буынара ачыклыклары тәшкил итә. Дөрес, җырларның рифма өлешендә иң зур күпчелек очракларда ритмик ачык иҗекләр дә саклана, үзләре булмаса, алар урынында «урынбасарлар» тора. Ләкин рифмадан элегрәк килгән ритмик буыннарда ачык иҗекләр тәртибе югала.

Киресенчә, халыкның көй белән җырланмый, бәлки җанлы интонациясе белән сөйләм барышында кулланыла торган әсәрләрендә — аларның ритмик төзелешендә —

---

[1] Исәнбәт. II том. 894 бит.

[1] Исәнбәт. II том. 894 б.

буынара ачыклыклары өстенә, ачык иҗекләр тәртибе дә бик күп әсәрләрдә саклана. Болар — мәкальләрдә һәм табышмакларда.

Шушыннан фараз итәргә мөмкин: халык иҗатындагы ритм синкретизмының таркалуын, язма иҗат заманына күтәрелгәч, бәлки җәмгыять бер очракта шигъри әсәрләрнең махсус җырлар өчен, икенче очракта көйсез, махсус җанлы интонация авазы белән укыр өчен язылуын таләп итә башлавы китереп чыгаргандыр? Шул шартларда көйгә җырлана торган шигъри әсәрләрдә ритмик ачык иҗекнең роле кимегән, бәлки бөтенләй артык булып калгандыр? Киресенчә, җанлы сөйләм интонациясе белән укыла торган шигъри әсәрләрдә ритмик ачык иҗек төп функциясе өстенә интонация төсмерләрен дә баета торгандыр?

Бәлки шигырьгә җәмгыять тарафыннан таләпнең артуы, аның төрләрен күбәйтү ихтыяҗы синкретизмны сүтәргә, бер карында туган ике кардәшне — ритмик ачык иҗек һәм буынара ачыклыкларын — бер-берсеннән аерырга, аларның һәрберсен мөстәкыйль яшәтергә мәҗбүр иткәндер?

Әйе, ике туган бер-берсеннән аерылып киткәннәр, мөстәкыйльлек алганнар. Әмма алар дошманлашып, сугышып аерылмаганнар, җитлегү, балигъ булу нәтиҗәсендә генә аерылганнар. Шуңар күрә аерылган чакта һәрберсе икенчесенең сыйфатын да, бер өлеш төсендә, запас орлык яки өстәмә бизәк итеп, үз эчендә алып чыккан. Нәтиҗәдә халык шигырендә («бармак»та) классик шигырьнең («аруз»ның), классик шигырьдә исә халык шигыренең җанлы эзе калган. Шуңа күрә шагыйрьләрнең иҗат процессында бу ике туган гел бер-берсенә якынаю омтылышы белән яшиләр, ә шарты килсә хәтта бер шигырь эчендә үк яңадан кушылып китәләр. Бу хәлне мисаллар белән аңлатып була. Мәхмүт Кашгаридан бер мәкаль һәм бер шигырь китерик:

Усукмишә сакыйг камугъ су курүнур.

Чагри алиб, аркум мүнүб, аркар йитәр,
Аулар киек тайган изиб тилкү тутар [1].

Беренчесенең мәгънәсе: сусаганга барлык нәрсә су булып күренер, икенчесенең — кулына ау лачыны кундырып, чапкын атына менеп, тау кәҗәләрен куар, киек аулап, төлке тотар.

Күренә ки, борынгы мәкальнең синкретик ритмик төзелеше язма шигырьгә башта шул килеш күчерелгән. Ләкин бара-тора бу хәл үзгәрә: ритмны оештыручы ике чараның берсе — бу очракта буынара ачыклыклары — өстенлек ала. Шунда да шигырь ачык иҗекләрнең эзен бөтенләй үк бетереп ташламый, бераз саңгыраулана төшкән төскә китереп булса да, алар урынына әлеге «урынбасар»ларны утырта, ә күп кенә очракларда туп-туры ачык иҗекләрнең үзләрен саклый. Шигырьнең рифмасы булып килгән ритмик буында эш тагын да кискенрәк: монда ритмик ачык иҗекләр күпчелек очракларда тулысынча сакланалар. Мондагы рифма классик шигырь белән халык шигыренең — «бармак» белән «аруз»ның — органик тоташкан урыны булып кала. Әле генә Кашгаридан китерелгән мәкаль һәм шигырь өлгесе соңрак үзенең беренче һәм икенче буыннардагы ритмик ачык иҗекләрен ташлаган, менә нинди төскә кергән:

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш әлбәт ачы хәсрәт көен,
Җирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

Тукайның «Сәрләүхәсез» исемле бу шигыре янына аның тагын «Кечкенә музыкант», «Ай һәм кояш», «Бабай», «Туган авыл» кебек шигырьләрен дә теркәп булыр иде. Без мондый хәлне татар халкының авыз иҗаты әсәрләрендә дә еш кына очратабыз. Бәетләрдән, мәсәлән, «Ташкай», «Ялчылар» [2] кебекләренә игътибар итегез. Аларда да рифма буыны ритмик ачык иҗекле, ачык булмаганда, ул урында әлеге «урынбасар» тора. Тукайның «Милли моңнар»ын карасак, анда да шул ук хәл.

Хәзер мәсьәләне классик шигырь (аруз) ягыннан торып карыйк.

[1] Кашгари. I том, 199, 397 битләр.
[2] Бәетләр. Төзүчесе Х. Ярми. Казан, 1960, 81, 129 битләр.

Классик шигырь дә аерылып чыкканда халык шигыре ягыннан үзенә өлеш калдырган. Мин буынара ачыклыкларын күздә тотам. Әгәр буын ахыры белән сүз ахыры бергә туры килсә, буынара ачыклыгы классик шигырьдә үзеннән-үзе, «автоматик» рәвештә саклана. Ә менә буын аралыгын сүз каплап үтсә, эш башкарак. Мондый хәлдә классик шигырь бер буын беткән урынга сүзнең ябык иҗеген туры китерә һәм икенче буынны башлап җибәргән иҗекнең сузык авазга түгел, тартык авазга башланган булуын мәҗбүр итә. Бу хәлне мисал белән аңлатыйк:

Әйтә иртән- ге намазга бик матур моң- лы азан,
И Казан! Дәрт- ле Казан! Моң- лы Казан! Нур- лы Казан!

Буынаралыгы сүзне урталайга бүлгән урыннарга игътибар итегез: буынаралыгына килеп тәрелгән аваз да тартык, аңардан соңгы ритмик буынның башланып китүе дә тартыктан («иртән-ге», «моң-лы»). Теләсәң, шигырь язганда шушы урыннан буынаралыкларын бөтенләй дә ачып була. Мәсәлән, Дәрдмәнд белән Сәгыйть Рәмиев аларны ачканнар (бу хәлне без «Татар шигыре» исемле китапта тикшердек).

Әйтелгәннәрне бергә җыйнаганда, шулай килеп чыга:

1. Татар шигырендә ритмиканы оештыру чаралары — ачык иҗекләр тәртибе белән буынара ачыклыклары — бик борынгы заманнарда ук бер үк шигъри әсәрләрдә синкретик, укмашулы төстә бергә яралганнар, бергә үскәннәр һәм бергә җитлеккәннәр.

Шул заманда ук мәкальләрдә һәм табышмакларда аваз составлары ягыннан түбәндә өч төрле ритмик буыннар барлыкка килгән: гел ябык иҗектән торган буыннар (◡ ◡ ◡), гел ачык иҗектән торган буыннар (— — —), ачык һәм ябык иҗекләрнең тәртипле оешуыннан торган буыннар (— ◡ ◡ ◡). Шигырь болардан кайсы да булса берәрсен бер-бер тезү юлы белән дә, шулай ук бер үк шигырьдә аларның икесен яки барысын да билгеле бер тәртиптә үрелдерә бару юлы белән дә язылган.

2. Шигырьне хәтердән иҗат итүдән язып иҗат итүгә күчкәндә беренче шагыйрьләр үз әсәрләренә өлгене турыдан-туры халыкның әнә шул шигъри әсәрләреннән алганнар. Шуңар күрә язма шигырь дә беренче дәверләрдә ритмик төзелеше ягыннан синкретик булган, соңрак исә ул, иҗтимагый тормышның шигырьгә булган яңа таләпләре нәтиҗәсендә, таркалган, һәм ачык иҗекләр тәртибе үзенә аерым, буынара ачыклыклары үзенә аерым мөстәкыйль роль уйный башлагач, халык шигыре («бармак») һәм классик шигырь («аруз») дигән күренешләр килеп чыккан.

3. Бу ике чара, бер-берсеннән аерылып чыкканда, араларын кырт кисеп өзеп ташламаганнар. Ачык иҗекләргә корылган шигырь («аруз») үзендә буынара ачыклыклары үтәргә тиеш урында аның, нечкә генә булса да, эзен саклаган, аны гүяки ритмик чаралар арасында бер резерв итеп тоткан. Киресенчә, буынара ачыклыкларына корылган шигырь («бармак») ачык иҗекләр тәртибенең рифма өлешендәгесен үзендә тотып калган, саклаган, бу ачык иҗекләр баганасын, аз дигәндә, «урынбасар» иҗекләр ярдәмендә беркетеп килгән.

4. Шул рәвешле шигырьнең борынгы синкретик заманда орлыкланып, соңыннан, шигырь тармакларга аерылгач, аның һәр тармакта тагын да ныграк үскән, камилләшкән сыйфатлары һаман да бер-берсенә туган, якын кардәш, игезәк булып калганнар. Шул сәбәпле шигырь үсешенең югары баскычында аларны яңадан бергә кушу, югары сыйфат дәрәҗәсендә синтезлау мөмкинлеге бар.

Хәзерге татар поэзиясендә әнә шул с и н т е з л а у бара да. Хәер, халык бу мөмкинлекләрне борынгылыкта үзе тудырган кебек, аны үз иҗатында бөтен тарихи гомере буена хәзергәчә файдаланып килгән. Без халыкның бу иҗат эшчәнлеген тиешенчә күреп җиткерә алмаганбыз гына. Болар бигрәк тә үзе бер чиксез хикмәт һәм матурлык диңгезе булган мәкальләр һәм табышмаклар дөньясында аеруча җанлылык белән хөкем сөрәләр. Язма шигырь бу диңгездән билгеле дәрәҗәдә аерылып калган. Ни өчен? Монда да әлеге шул, классик шигырь гарәптән кергән, фарсыдан кергән, дигән караш зыян китергән булса кирәк. Шигырьнең халык өлгерткән өлгеләреннән шагыйрьләр гарәпнең б ә х р е х о җ а з белән б ә х р е р ә м а л г ә охшашлыларын алганнар да, калганына бөтенләй игътибар итмәгәннәр. Нәтиҗәдә безнең классик шигыребез гасырлар буе шушы ике өлгедән узмаган. Хәтта Г. Тукай, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев тә бу хәлне үзгәртмәгәннәр.

Соңгы ярты гасыр эчендә татар шигъре өлкәсендә матур яңалыклар барлыкка килде. Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, Ф. Кәрим, С. Хәким, Ш. Мөдәррис монда аеруча зур ачышлар ясадылар. Безнең игътибарыбызны бигрәк тә нык җәлеп иткәне, әлбәттә, классик шигырь белән халык шигъре сыйфатларын яңа югарылыкта яңадан бергә кушу, синтезлау. Бу эш, чамача, 30 нчы елларның ахырларында көчәеп китте. Моның сәбәпләре культура революциясенең уңышларында, мирас байлыгын дөрес үзләштерә баруда, совет поэзиясенең иҗат тәҗрибәсе артуда иде. Совет язучыларының I съезды тудырган мөхитнең дә әһәмияте истән чыгармаска кирәк. Бөек Горькийның халык иҗатын тирән өйрәнергә чакыруы да дәрт бирде, совет әдәбиятын, совет поэзиясен халык үзе өлгерткән гүзәллекләр белән баету эшен көчәйтеп җибәрде.

Егерменче елларда пассивлаша төшкән классик шигырь традицияләре шушы шартларда шигырьдә яңадан көчәя башладылар. Ләкин шунысы: алар язма поэзиядәге элекке рәвешләрендә түгел, үзгәчә, яңа рәвешләрдә калкып чыктылар. Иң элек мондый шигырь яңгырап китте:

Алтын ай төннең түрендә
Кандилле лампа иде...
Керосин сора мый торган
Расходсыз якты иде [1].

Бу шигырьнең тууы булды, аны элеп тә алдылар, үстерә-эшкәртә дә башладылар. Бөек Ватан сугышы елларында ул тәмам өлгереп җитте, Х. Туфанның үзендә дә, С. Хәким, Г. Латыйп кебек шагыйрьләр иҗатында да тулы авазы белән яңгырарга кереште.

Булмә син фикерен аның, әй
Кояшым, иртә батып,
Күр, ничек ихлас белән ул
Хат укый кырын ятып.

Әнә ул С. Хәкимнең «Куллар» шигырендә шушындый рәвешкә керде, тулысынча утырып җитте, үзендә буынара ачыклыкларын да, ачык иҗекләр тәртибен дә бердәй төзек формада берләштерде, татар шигырен яңа, элек ишетелмәгән аһәң белән баетты. (Бу ачыш шулай ук безнең «Татар шигъре» исемле китабыбызда тикшерелгән.)

Шул ук 30 елларның урталарында Ф. Кәримнең «Аучы» поэмасында яңачарак аваз яңгырап калды:

Аучы килде яр буена,
Карады суга:
— Менә кайда икән алар,
Шауламa, туган.

Дөрес, бу әле бик үк эшкәртелеп җитмәгән иде. Әмма Бөек Ватан сугышы елларында шагыйрь «Идел егете» поэмасында аның яңгырашын тулырак ачты:

Төн үтә. Тау лар артына тулган ай бата,
Украина кырларында язгы таң ата.

Мондый шигырь язма поэзиядә булмаса да, халык иҗатында — мәкальләрдә күптән булган:

Үзең адәм булсаң, безнең өйдә аш әзер,
Үзең яман булсаң, безнең өйдә таш әзер. [2]

Боларда да буынара ачыклыклары һәм ритмик ачык иҗекләр бер ук хокук белән кулланылган. Шигырьнең үзенчәлеге, уникенче урындагы иҗекне ачык итеп, аңардан алда торган унберенче иҗекнең басымын гадәттәгедән көчәйтү, рифманың ике иҗеклегә калып, кәтмәгәндә кыскаруы интонацияне кырт кистерә, бу да шигырьдәге

[1] Х. Туфан. Тукайның туганы (Татар поэзиясе антологиясе. 507 бит).
[2] Исәнбәт. II том. 741 бит.

«ай», «таң» сүзләренең, мәкальдәге «аш», «таш» сүзләренең басымнарын гадәттәгедән көчәйтә.

Бу шигырь «Идел егете»ндә шактый эшкәртелгән булса да, шулай да аны тәмам эшкәртелеп җиткән дияргә булмый. Ф. Кәрим монда бөтен строфаларны да бер калыпка салып җиткермәгән әле. Әмма арада, коеп алгандай, һәрьяктан өлгергән строфалар да бар. Мәсәлән:

Күкләргә җәеп хыялны,
Бер тынлар идең,
Күзләрне йомып, ахырда
Бер сулар идең.

Унөч иҗек ритмик буыннарга биредә башкача бүленгән, икенче урындагы гына түгел, дүртенче урындагы иҗек тә ачылган һәм аңа, өченче иҗекнең басымын көчәйтер өчен, яңа вазифа йөкләнгән. Строфаны шушылай баету аның яңгырашына романтик моң сирпегән.

Халык мәкальләре арасында мондые да бар:

Саулыкның кадерен киткәч белерсең,
Яшьлекнең кадерен үткәч белерсең [1].

Шәрәф Мөдәррис Бөек Ватан сугышы тәмамланган елларда шушы мәкальгә охшашлы яңа шигырь куллана башлады. Бу юлда аның аеруча уңышлы беренче әсәрләреннән «Рәмзия» исемле шигыре булды. Шигырьнең бер-ике строфасын күчереп үтик:

«Килер» дип, сагынып, көтеп торасың,
«Килде» дип, ашкынып, каршы чыгасың,
Күрмичә сөйгәнең, бәгърем Рәмзия,
Ялкынлы яшь йөрәк ничек чыдасың?

Кыймыйча, ятсынып, ян(ы)ма[2] киләсең,
Бит алмаң кызарып, кулың бирәсең,
Карамыйм текәлеп, бәгърем Рәмзия,
Тукта, дим, зифама күзем тимәсен.

Күренеп тора: шигырьнең икенче һәм соңгы ритмик буыннар баганасының урталыгыннан ритмик ачык иҗекләр тезелеп төшә. Әйтергә кирәк, миңа мондый шигырь язма поэзиядә бер урында да очрамады. Бәлки ул моңа кадәр чынннан да булмагандыр. Бәлки аны беренче ачкан шагыйрь Ш. Мөдәрристер.

Бер ачылгач, Мөдәррис бу шигырьне төрле-төрле рәвешләрдә вариацияли. Бу яктан ул бигрәк тә үзенең «Сонет»ларында җитди нәтиҗәләргә ирешә.

Мәкальләрдә гел ачык иҗекләрдән генә яки, киресенчә, гел ябык иҗекләрдән генә торган ритмик буыннар булуын югарыда әйткән идек инде. Ш. Мөдәррис үз шигырьләрендә аларның тегесен дә, бусын да гамәлгә кертә. Менә аның Гөлсем Сөләймановага багышланган «Тормыш җиңә» исемле шигыре:

Ф(ы)ронт төне. Землянка... Салам җәйгән нарлар.
Ялкын сулый тимер мич, тиздән чәй дә кайнар.
Сирәк булган тын вакыт. Күкрәмиләр туплар.
...кайтып керде бервакыт минометчы Туктар.
Пөзе балкый, күзләрен шатлык нуры баскан.
Әллә каян патефон, пластинкалар алган.

Шигырьнең рифма булып килгән соңгы ике иҗекле буынына игътибар итегез: монда барлык рифмалар тик ябык иҗекле сүзләрдән генә тора. Шигырьнең буеннан буена шулай. Бу рифмалар кычкырусыз, шау-шусыз, күңелгә җылы землянканың — сугыш шартларында вакытлы иминлек, тынычлык почмагының — рәхәтен сирпеп агылалар.

---

[1] Исәнбәт, II том, 941 бит.
[2] «Янымa» сүзе шигырьдә кыска әйтелештә алынган.

Ш. Мөдәррис гел ябык иҗекләрдән генә торган ритмик буынны тезмәнең башламында яки бетемендә генә түгел, эчке өлешендә дә куллана.

Тагын мәкаль китерик әле.

Алып Мәмшән ир иде,  
Үзеннән бер яшь олыга:  
— Без торыек, газизем,  
Сез белерсез,— дир иде.

Үзеннән бер яшь кечегә:  
— Син тора тор, газизем,  
Без белербез,— дир иде [1].

Бу мәкаль халыкның зур күләмле борынгы әсәреннән кителеп калган һәм хикмәтле сүз төсендә халык күңелендә саклана торган бер өзек булса кирәк. Аның ритмик төзелешендә буынара ачыклыклары белән ачык иҗекләр тәртибе икесе берьюлы кулланылган.

Әсәрдә бер строфага хикәяләү дә, хикәядәге персонажның туры сөйләме дә сыйдырылган. Өстәвенә ачык-ябык иҗекләр тәртибенә корылган төрле-төрле калыптагы ритмик буыннарның үзара ритмик тәңгәллекләре дә бик төгәл сакланган, шул ук вакытта строфаның үз төзелешендә иреклә шигырь элементы да кулланылган. Кечкенә мәйданга бу хәтле нәрсәләрне берьюлы сыйдыру һәм шул ук вакытта строфаның үз эчендә табигый иркенлек атмосферасын да саклый алу — бу бик зур сәнгать остасы гына булдыра ала торган эш.

Сонет — ундүрт тезмәле шигырь. Артык та түгел, ким дә түгел. Түбәндәге сонетта да шулай:

1. Күргәнең бармы, дус, ялтырап чыккан  
2. Ал-кызыл шар сыман июнь кояшын.  
3. Кerәсең килми һич бүлмәгә тыштан,  
4. Йөрәктә чын рәхәт илһам тоясың...

5. Йөрәктә чын рәхәт илһам тоясың,  
6. Иртәнге саф нурны күрәсең чыктан.  
7. Бу, дисең, минем көн, минем кояшым,  
8. Ул, дисең, шатлыкка, бәхеткә чыккан.

9. Елмаеп, шатлыкка, бәхеткә чыккан  
10. Сүндерә алмаслар мәкерле көчләр,  
11. Томалый алмаслар караңгы төсләр!

12. Кичебез болытсыз, таңыбыз — чын тан.  
13. Төнебез кайгысыз, көнебез — шатлык, —  
14. Яшәсен тынычлык, яктылык, сафлык.

Журнал битендә график схема бастыруны бик килештереп бетермиләр. Әлегә хәтле без моңардан тыелып килдек. Әмма югарыдагы сонетның схемасын күрсәтми торып, төзелешендәге үзенчәлекләрен аңлатуы кыен. Схемасын карыйк:

1. ∪+∪ ∪—∪ ∪—∪ ∪∪  
2. ∪—∪ ∪—∪ ∪∪ ++∪  
3. —+∪ ∪—∪ ∪—— ∪∪  
4. —∪— ∪—∪ ∪∪ ++∪  
5. —∪— ∪—∪ ∪∪ ++∪  
6. ∪+— ∪∪— ∪—— ∪∪  
7. ——∪ ——∪ —∪ ++∪  
8. ∪+∪ ∪∪— —∪— ∪∪  
9. ∪+∪ ∪∪— —∪— ∪∪  
10. ∪+— ∪∪∪ —∪— ∪∪  
11. —+— ∪∪∪ —∪— ∪∪  
12. —+∪ —∪∪ ——∪ ∪∪  
13. —+∪ ∪—∪ ——∪ ∪∪  
14. —+∪ —∪∪ ∪—∪ ∪∪

[1] Исәнбәт. II том, 833 бит.

Күрәнә ки, шигырьнең ритмик тезелеше бик бай: өч иҗекле беренче багана уртасыннан ачык иҗекләр тезелеп төшә, 1, 3, 6, 8—14 тезмәләрнең рифмалары саф ябык иҗекләр баганасыннан гыйбарәт, 2, 4, 5, 7 тезмәләрдә — бүтән тәртип, саф ябык иҗекләр биредә дүртенче баганаы түгел, өченчене били, ә рифма өчен ачык иҗекле буын алынган. Бу соңгы ритмик буынның тагын бер үзенчәлеге бар: аңарда ике ачык иҗек янәшә китерелгән һәм икесенә дә индивидуаль ритмик функция йөкләтелгән. Мондый хәл мәкальләрдә дә еш кына очрый. Мәсәлән:

Акчалының эше күп [1],
Бакчалының ашы күп.

Ике ачык иҗекнең берсе артыннан берсе килүе сүзне акрынайтып укырга мәҗбүр итә. Ш. Мөдәррис «Сонет»ында да шул сизелә: «чынлыктан — тыштан...» кебек рифмалар җитез һәм кистереп әйтелсә, «коашым — тоясым...» кебекләр өчен сүзне гүяки «туктатып», сабыр уку хас.

Мөдәррис үзе ачкан унбер иҗекле бу шигырьне төрлечә вариацияли. Бу урында аларның барысын да тикшереп чыгарга мөмкин түгел, урын тар.

Ритм тудыручы ике чараны бер үк шигырь эчендә бергә үрелдереп куллануда. С. Хәким дә яңа һәм бик кызыклы ачышлар ясады. Менә аның исемсез бер шигыре. Аны тулысынча китерәбез:

Барсы да бүген текәлеп карый,
Кайда ул инде минда чибәрлек.
Бәлки, шөһрәтем таралгандыр, дим,
Меннәр йөрәге сөенеп тибәрлек.

Бу хакта кичен, өемә кайткач,
Хатын белән дә икәү сөйләштек.
Ул әйтте миңа: янында булган
Малаең синең үнҗиде яшьлек.

Бу шигырьнең ритмик схемасын ачканда ике юлын бер юлга тезәргә кирәк:

∪— —+∪ +—∪ —— ‖ ∪— ∪∪— ∪— +∪∪
∪— ∪+∪ +∪∪ ∪∪ ‖ ∪∪ ——— ∪∪ +∪∪

Бу, безнеңчә, язма поэзиядә яңа шигырь, яңа ачыш. Шагыйрьнең «Күреп кит» шигыре дә шундый ук ачыш саналырга тиеш:

«Күреп кит, бәхиллеген ал...» — шулай дип исә җилләр
Үз улы, үз(е)нең [2] баласы, әнкәй мине бәхилләр.

Шигырьнең ике юлын да бер тезмә итеп алгач, монда 6 һәм 13 нче урыннарда ритмик ачык иҗекләр китерелгәнен күрәбез. Шушы хәл югарыдан алып түбәнгә таба әсәрнең буеннан буена үтә.

С. Хәкимнең «Мин шагыйрьне алып кайтам» исемле шигыре дә үзенә башка яңача корылган.

Мин шагыйрьне алып кайтам безнең
Мәскәү поездында.
Бик кыска да кебек юлым минем,
Гүя бик озын да...
Үз хәленең авырлыгын белә,
Арзанлы сүз сатма,
Кызгануны яратмаучы караш
Тора һаман сакта.

---

[1] Н. Исәнбәт. I том. 862 бит.
[2] Биредә сүз «үзенең» дип түгел, «үзнең» дип, кыска әйтелештә алынган.

Бу шигырьдә, ике тезмәне бергә алганда, уналты иҗек. Шулардан бишенчесе мәҗбүри рәвештә ачык һәм басымсыз. Бу ачык иҗекнең вазифасы — я үзеннән алдарак, я үзеннән соң килгән берәр иҗекнең басымын аерата көчәйтергә мөмкинлек тудыру. Бу ноктадан карагандa рифмадагы иң соңгы иҗекнең дә ачык булуы аңардан алдагы иҗекнең басымын көчәйтә, ачык иҗек булмаган очракта, икенче иҗеге басымсыз сүз китерелгән («ычкын, тизрәк ычкын», «шушы арадан мин» — «бергә баралам мин»). Ачык иҗекләрнең шушындый тәртибе шигырьнең ритмик яңгырашына үтә тә үзенчәлекле аһәң кертә.

Бу шулай ук С. Хәким ачкан шигырь. «Белсәң иде» исемле әсәр дә — аның бәхетенә чыккан ачыш.

Алмагачның алмаларын бергә өзәсем килә;
Бергә яныл, бергә көеп, бергә түзәсем килә.
Аның белән бакчам буйлап бергә үтәсем килә;
Төн йокламый, таңнарымны бергә көтәсем килә.
Эзләнә күң- лем, эзләнә, бөтен җирне тарсына;
Яшрен сагыш- лары белән чыксын иде каршыма.
Белсәң иде аның таңда йөри торган юлларын;
Шул мәхәббәт юлларының кайларда кушылганын.

Биредә һәр тезмәдә (ике юлны бер итеп алганда) 15 иҗек бар. Һәр тезмә дүртәр иҗекле өч, өч иҗекле бер буыннан, ягъни дүрт буыннан гыйбарәт. Беренче һәм өченче буыннарның өченче иҗеге, соңгы буынның икенче иҗеге — ачык.

Бу да яңа шигырь. Дөрес, әле ул бөтенләй үк эшләнеп, өлгереп җитмәгән: ачык иҗек торырга тиешле кайбер урыннарда әлегә ябык иҗекләр очрый. Ләкин инде шигырь нигездә табылган. Киләчәктә, һичшиксез, эшкәртелер, җитлектерелер.

Табылган шигырьнең үзен җитлектерү барышы да бик кызыклы. Туфанның 1940 елда язылган «Тукайның туганы» шигыреннән өзек алыйк:

Түбәдә, морҗа төбендә
Без — китап белән икәү —
Сукранып уйчан • ятабыз:
Бу болыт үтәр микән.

Бисмилла өчен- ме, җүләр,
Син шулай тузы- насың? —
Кирәксә, үзең мәтәштер
Аның син бисмил- ласын.

Туфанның бу шигырьне яңа ачкан чаклары. Шуңар күрә шигырьнең эшләнеп җитмәгән яклары күренеп тора: икенче строфаның беренче ритмик баганасында ачык иҗек бер генә урында сакланган, беренче, дүртенче тезмәләрдә буынараларын сүзләр каплап киткән.

Туфан ачкан бу шигырьне Бөек Ватан сугышы елларында С. Хәким җитлектерде, «Куллар» әсәрендә аның идеаль дәрәҗәдә эшкәртелгән, искиткеч пөхтә үрнәген бирде.

Х. Туфан исә соңгы вакытларда шул ук шигырьнең инде яңа төсмерен эзли. «Җирдә яз» (1963) шигырендә ул беренче ритмик баганадагы ачык иҗекне икенче урынга түгел, беренче урынга куя.

«Киләчәк көннән сиңа,
Сәлам бу», — дигән кебек,
Бу сүзне синме, кояш,
Китердең нурга төреп?

Бу инде яңа шигырь. Әлбәттә, аның да җитлектерәсе урыннары бар: беренче баганадагы ачык иҗекләр урынына биш буында сонантлы иҗекләр куелган (Р Н), ике иҗекле буын урынына өч яки дүрт иҗекле сүзләр кую да бар.

Туфанның «Агрессорга» исемле шигыре дә ритмик ачык иҗекләргә корылган:

Өсмне тараттың син,
Йөземне канаттың син,
Башымны агарттың син,
Ни кирәк сиңа тагы?

Без Х. Туфанда да, Ф. Кәрим белән С. Хәкимдә дә, Ш. Мөдәррисгә дә яңа ачылган мондый, ягъни үзендә ачык иҗекләр тәртибе белән буынара ачыклыклары тәртибен бергә берләштергән шигырьләрнең бүтән рәвешләрен дә күп кенә очратабыз. Әмма кыска мәкаләдә барысын да китереп булмый. Тик шунысын гына әйтергә кирәк: борынгы синкретизм тудырган сыйфатлар язма шигырьгә күчкәч, үзләренә чагыштырмача мөстәкыйльлек алгач, аерым-аерым хәлләрендә үз эчке сыйфатларын тагын да тирәнрәк ачканнар, тагын да баетканнар, җитлектергәннәр. Килеп, безнең заманда инде, телнең, поэзиянең югарырак баскычка күтәрелүе шартларында аларны яңадан бергә ялгарга, синтезләргә, аларның элек күрелмәгән яңа үрелмәләрен тудырырга мөмкинлек ачылган. Бу табигый күренеш: диалектик үсешнең югарыга таба юлы туры сызык белән бармый, бәлки борылмалы, спираль рәвешендә, түгәрәк артыннан түгәрәк ясаулар белән бара һәм шуның белән бергә һәр яңа түгәрәктә киңрәк әйләнеш ясала. Түгәрәк ясаган саен үсеш түбәндә үтелгән бер ук сыйфатларны, баетып, югары дәрәҗәдә яңадан кабатлап уза. Татар шигыре үсешендә дә без шундый ук хәлне күрәбез: синкретик сыйфатлар борынгылыкта бергә укмашып туганнар, хәзер югары дәрәҗәдә яңадан бергә үреләләр. Бу үрелмә үсәр, тирәнәер һәм бик бай яңалыклар тудырыр әле.

Х. Туфан, Ф. Кәрим, С. Хәким, Ш. Мөдәррис кебек шагыйрьләр, язма әдәбият традицияләрен тирән үзләштерү өстенә, халыкның авыз иҗатына бик игътибарлы талантлар. Аларның шәхси сыйфатлары арасында бик көчлеләреннән — халыкның җанлы теленә, аның иҗатына мәхәббәтләре иксез-чиксез зур һәм тирән булуы. Алар да халык теленә, халык иҗатына соклану бик көчле матурлык тойгысын тәшкил итә. Бу мәсьәләдә аларның күңел сизгечләре (эмоцияләре) искиткеч зирәк. Шушы хәл аларга халык телендә шигырьгә нигез булырлык хасиятләрне тоярга, бу хасиятләрнең шигырьгә ничек күзгә күренмәс, эчке агым булып килеп керүен сизәргә мөмкинлек бирә. Халык шигырь төзелешенең күзгә күренмәс формаларда, тирәндәге эчке агым төсендә хәрәкәт итә торган хәлиткеч закончалыкларын, фән ачмаган булса да, алар тойгы белеме, тойгы зирәклеге ярдәмендә сизәләр, ул хасиятләргә барып ирешәләр, тиенәләр һәм аларны үз иҗатларына ук күчереп алалар.

Безнең яшьрәк буын шагыйрьләребезгә, бәлки, бу традициягә игътибарлырак үстерү кирәктер.

* * *

Без сүзне Г. Халит мәкаләсеннән башлап киткән идек. Үз дәлилләребезне аңлатып чыккач, без әйтәбез: татар халкының классик шигырен тудырган чаралар гарәптән дә алынмаган, фарсыдан да алынмаган, аларны халык үзе тудырган, алар — халыкның үзеннән[1].

Чыннан да, бер минутка гына булса да, классик шигырь сыйфатлары гарәптән яки фарсыдан килә дип ышаныйк,ди. Ул чагында татар шигыренең хәлиткеч спецификасын аңлатыр өчен халык теленә, халык иҗатына түгел, фарси теленә юнәлергә тиеш булыр идек. Ничә гасырлар буе әнә шулай эшләп килгәннәр дә! һәм шигырьнең төзелешен аңлатуны стенага илтеп терәгәннәр. Чөнки алай дию иҗади фикергә юл ачмый, киресенчә, иҗади фикергә юлны бикли, кысырлыкка дучар итә.

Әгәр без классик шигырьнең чыганагы халык телендә, халыкның үз иҗатында дисәк, эш бөтенләй бүтән төс ала: монда иҗади фикергә киң юл, өйрәнер өчен бетмәс-төкәнмәс хәзинә ачыла. Алай гына да түгел, шигырьне җанлы яшәешендә, яңадан-яңа сыйфатлар тудырып торучы үсешендә өйрәнергә мөмкин була. Ул чагында шигырь фәне нәтиҗәсезгә сүз йөртү хәленнән чыга, хәзерге әдәби процесска көчкуәт өсти, аны тизләтә, баета торган казанышка әйләнә.

Без менә шушы соңгы юлны сайлыйбыз.

---

[1] Рус һәм чуваш халык иҗатын тикшереп карагач, аларда да ачык иҗекләрнең шигырь ритмикасын оештыруда гаять зур роль уйнаулары мәгълүм булды; анда да ачык иҗекләр халык иҗатыннан язма поэзиягә күчереп алынган. Бу хактагы тикшерену нәтиҗәләрен без икенче мәкаләгә калдырабыз.

*Җәлил Камалетдин,*
*шагыйрь һәм тәнкыйтьче,*
*Ирак язучылар союзы члены.*

# КАЗАН ТУРЫНДА КАЙБЕР ТӘЭСИРЛӘР

Татарстан язучылар союзы миңа зур хөрмәт күрсәтте: Казанга чакырды, аның культура һәм әдәбият тормышы белән танышырга мөмкинлек бирде. Шуны әйтеп үтәргә кирәк, 26 апрельдә Татарстан шагыйрьләре һәм аларның кунаклары, үзләренең шигырьләрен укыр өчен, татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай һәйкәле янына җыелдылар. Мин, гарәп халыкларына карата яхшы дуслык мөнәсәбәтендә булган бөек Советлар Союзының якын дусты, бу бәйрәмдә дә катнаштым.

Без, гарәпләр, бик борынгы заманнардан бирле Казан турында күп ишетеп һәм укып киләбез. Ата-бабаларыбызның бер вәкиле, сәяхәтче Ибн Фадлан, борынгы заманда ук бу якларга килеп чыккан һәм Идел буе халыклары турында кызыклы язмалар калдырган. Шулай ук бирегә гарәп сәүдә кәрваннары, галимнәр һәм безнең культура миссияләре дә килеп йөргәннәр. Чөнки Болгар дәүләте көнбатыштан көнчыгышка, төньяктан көньякка үтүче юллар кисешкән төштә урнашкан зур сәүдә үзәкләреннән саналган. Ерак диңгезләрне кичкән кораблар Идел буйлап Болгарга кадәр күтәрелгәннәр. Товарлар китергәннәр һәм алып киткәннәр. Бу исә, үз чиратында, халыкара мөнәсәбәтләрне үстереп җибәргән, ике халык культурасының бер-берсенә тәэсир итү көчен үстергән.

* * *

Миңа бүгенге Казанны, совет чоры Казанын, Бөек Октябрь Казанын үз күзләрем белән күрергә насыйп булды. Казан турында күп нәрсә ишеткәннән, барысын да үз күзләрем белән күргәннән соң миндә нинди тәэсирләр туды соң? Әлбәттә, бу мәкаләдә генә тулы җавап биреп бетерү мөмкин түгел. Моның өчен тулы бер китап язарга кирәк һәм, мөгаен, мин аны киләчәктә язармын да. Ә бирегә, аз гына булса да, беренче тәэсирләрем, Казаннан кайткач туган уй-фикерләрем турында язып китәргә телим. Элекке вакытларда ук инде татар халкының культурасы бик нык үскән булган. Һәм фарсы, гарәп, төрек халыклары белән бергәләп, гомум культураны үстерүгә татарлар да зур өлеш керткәннәр. Октябрь революциясенә кадәр ук Казан иң зур, иң әһәмиятле культура үзәкләреннән саналган. Советлар Союзындагы иң өлкән университетларның берсе Казанда урнашкан. Бу уку йортында, башка фәннәр белән бергә, гарәп, фарсы, монгол, кытай телләре дә укытылган. Шушы ук университетта Чернышевский гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнергә теләгән. Бирегә бөек рус язучысы Толстой һәм даһи Ленин укыган. Казанда һәм Оренбургта гарәп телендә китаплар чыккан. Казан университетының фәнни китапханәсе сирәк очрый торган кульъязмалар фонды белән хаклы рәвештә горурлана ала. Миңа Ленинградта, Мәскәүдә, Дүшәмбедә күп китапханәләр белән танышырга туры килде. Ләкин беркайда да Казан университеты китапханәсенең кульъязмалар бүлегендә саклаңган байлыкны очратмадым. Бу китапханәдә саклаңган гарәп телендәге китаплар һәм кульъязмалар белән (алар 6 меңгә якын) танышу һәм өйрәнү өчен тагын бер мәртәбә уңай вакыт туры килүен бик теләр идем.

Шәһәрнең иске районнарында көнчыгыш стиле бигрәк тә күзгә ташлана: йортлар, аларны бизәп ясалган төрле орнаментлар, рәсемнәр һ. б. Ә шәһәрнең яңа районнары исә рус стилендә төзелә. Хәзерге Казанны тулысы белән көнчыгыш рухында дип әйтү дөрес булмас иде, чөнки биредә халыкның яртысыннан артыграгы руслар.

Казан Кремле Мәскәү, Ярославль, Рязань һәм башка шәһәрләрдәге кремльләрдән үзенә генә хас яклары белән аерылып тора. Биналарда рус һәм татар халкы архитектура стиленең бергә кушылуы күзгә ташлана. Стеналар акка буялган (ә югарыда искә алынып киткән шәһәрләрдәге кремльләрнең стеналары кызыл төстә), ә керү урыны һәм башкалар (бер башнядан калганнары) рус стилендә.

Татарлардан гарәп телен белүчеләр күп. Өстәп шуны язарга мөмкин, хәзерге татар исемнәренең 99 проценты гарәптән алынган: Хәсән, Хәмит, Туфан, Җәмил, Җәлил, Мостафа, Мөхәммәт, Хәдичә, Зөһрә, Әминә, Әмир, Җәләлетдин, Камалетдин, Гали һ. б.

Казанның иске районында урнашкан мәчеткә килгәч, мин шуна игътибар иттем: намаз уку церемониясе нәкъ бездәгечә, гарәп илләрендәге кебек башкарыла, тик мәчеткә хатын-кызлар гына йөрмиләр икән. Мәчет гарәпләрдәгечә үк төзелгән: зур ишек алды, күп бүлмәләр, мулла, аның ярдәмчесе һәм мәчет идарәсе. Мәхәлләнең мулласы белем иясе кеше.

Мин мәчеткә килгән көнне үлгән кешеләргә җеназа укыганны тыңладым һәм бу процессны күзәттем. Барысы да нәкъ бездәгечә, хәтта мин үземне Дамаскта, Каһирәдә яки Багдадта кебек хис иттем: бер үк догалар, бер үк йолалар.

Татар халкы үзенең рухы, холкы, психологиясе, табигате, культурасы, үткәне һәм хәзергесе белән тулысынча көнчыгыш халкы, һәм югарыда санап кителгән барлык сыйфатлар гарәп һәм көнчыгыштагы мөселман илләре халыкларыныкы белән тәңгәл килә дип тә әйтергә мөмкин. Әгәр дә инде татар халкы кайсыдыр яклары белән булса да бу халыклардан аерыла икән, соңгысы — бигрәк тә совет чорында барлыкка килгән үзгәрешләр. Культура өлкәсендәге казанышлары буенча татар халкы, мәсәлән, рус халкы белән бер үк баскычта тора дияргә була. Татарстан, Башкортстан шикелле үк, автономияле республика һәм Россия федерациясенә керә.

* * *

Мин халык сәнгатенә зур игътибар бирүче учреждениеләр: университет, Казан театрлары, СССР Фәннәр академиясенең Казандагы институтлары янынннан уздым һәм үземә шундый зур кунакчыллык күрсәткән халыкның рухы белән тагын да якыннанрак танышу теләге туды. Театрларда, музейларда, фәнни институтларда күргәннәр барысы да татар халкының культура үсешен һәм перспективаларын күз алдына тагын да ачыграк китерәләр.

Хәзерге югары уку йортларында татар халкының уллары һәм кызлары, барлык башка милләт вәкилләре шикелле үк, тулы хокук белән белем алалар, ә патша заманында аларның күпчелеге югары уку йортларына кереп укудан мәхрүм ителгән булган.

Миңа шулай ук Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында В. И. Ленинның туган көненә багышланган искиткеч матур кичәдә булырга туры килде, һәм бу көн минем Казанга килеп төшүем белән бергә туры килде (22 апрель, 1967 ел). Артистлар һәм Казан яшьләре тарафыннан башкарылган бәйрәм программасы хәзерге татар сәнгатенең Россия халыкларына азатлык китергән Бөек Октябрь революциясе байрагы астында, һичшиксез, бик югары үсканлеген күрсәтте. Ә Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында миңа «Хуҗа Насретдин» дигән бик яхшы спектакль карарга туры килде. Бездә, ягъни гарәпләрдә, Хуҗа (яки мулла) Насретдин бик киң таралган, аның турында анекдотлар, җырлар һәм мәсәлләр языла. Хуҗа Насретдин халыкның хикмәткә һәм зирәк акылга ия булуына яхшы мисал булып тора. Халык мондый әсәрләре белән җәберләүчеләргә каршы көрәшә, алардан көлә. Шунысын да әйтергә кирәк, Казандагы Хуҗа Насретдин Багдад, Дамаск һәм Каһирәдәге Хуҗа Насретдиннан күп аерылмый икән.

Татар артистлары үз рольләрен искиткеч яхшы башкардылар. Спектакль тәмамлангач, мин ул артистлар белән якыннан танышу бәхетенә ирештем. Шунысы кызык, алар безнең гарәп халкы һәм аның сәнгате турында күп беләләр һәм сорашалар.

Университетта мин гади, ләкин чын мәгънәсендә тирән акыллы һәм югары культуралы кешеләр белән таныштым. Бигрәк тә профессор Н. А. Гуляев белән очрашып сөйләшү тирән эз калдырды. Ул

Казан университетының рус әдәбияты кафедрасы мөдире, бик талантлы галим. Ләкин бер ук вакытта гади, шат күңелле, ачык йөзле кеше һәм нәкъ көнчыгыштагы кебек кунакчыл да. Безнең тирән эчтәлекле дискуссия романтизм, реализм һәм социалистик реализм проблемалары тирәсендә әйләнде, чөнки бу галим югарыда күрсәтелгән өлкәләрне тирәнтен өйрәнгән кеше. Сөйләшүебезнең ахырында профессор Н. А. Гуляев миңа үзенең романтизм һәм реализм буенча язылган хезмәтләрен бүләк итте.

Шушы ук вакытта университетта татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары белән очрашу булды, һәм алар миңа безнең сәнгать, әдәбият, үткәндәге һәм хәзерге культура өлкәләренә караган сораулар яудырдылар. Студентлар шулай ук минем татар әдәбияты белән кызыксынуым турында да сорадылар. Мин аларга татар әдәбиятында зур урын алган язучылар — Габдулла Тукай, Муса Җәлил исемнәрен атадым.

Студентларның чынлап та бездәге яңалыклар, безнең тормыш белән бик нык кызыксынулары, яңа культураның үсүе турында язылган китапларны күзәтеп барулары күренеп тора. Студентлар белән очрашудан соң мине университетта татар теле һәм әдәбияты, фарсы һәм гарәп теле укытучылары тарафыннан оештырылган кечкенә генә мәҗлескә чакырдылар. Анда күренекле язучы һәм галим Гази Кашшаф, Ибраһим Нуруллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Флера Сафиуллина, гарәп теле укытучысы Лена Яруллина (ул яшь кенә укытучы, гарәп телен Каһирәдә өйрәнгән, гарәпчә бик шома сөйләшә) һәм башка укытучылар катнаштылар.

Казан университеты турында мин күбрәк язарга телим, чөнки миндә аңа карата иң көчле тәэсирләр сакланып калды. Берсендә мин университетның проректоры Шәүкәт Хәбибуллин белән очрашып сөйләшү бәхетенә ирештем. Ул астрономия фәннәре докторы, профессор, Советлар илендә һәм шулай ук дөнья күләмендә атаклы галим. Бу гаҗәеп кеше миңа университетның үткәне һәм хәзергесе турында, татар халкының улларына һәм кызларына социализм биргән мөмкинлекләр турында сөйләде.

Үзешчән сәнгать түгәрәгендә катнашучы студентлар һәм аларның җитәкчеләре мине зур булмаган кичәгә чакырдылар. Җыр һәм бию белән алып барыла торган бу кичәдә миңа Татарстан һәм Башкортстан халыкларының сәнгате белән танышу мөмкинлеге туды. Бу вакытны Башкортстан университеты студентларының бию ансамбле казанлыларда кунакта иде. Бу гади генә, ләкин сәләтле яшьләр мине бик яхшы каршы алдылар: чиктән тыш хөрмәт күрсәттеләр, күп истәлекле бүләкләр бирделәр. Бу кызлар һәм егетләр үзләренең ачык күңелле һәм яхшы булулары, зирәклекләре, матурлыклары, җырда һәм биюдә осталыклары белән мине әсир иттеләр. Диларә Хәсәнова, Флера Сафиуллина, Флера Ганиева һәм Мөхәммәт Мәһдиевләр бу сәнгать кичәсе белән җитәкчелек иттеләр һәм алар минем хәтеремдә үзләренең киң күңелле, зирәк, матур һәм кунакчыл булулары белән гомергә сакланып калырлар.

Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында исә татар халкының милли сәнгатенә зур әһәмият бирәләр икән. Бөек Октябрь революциясеннән соң, В. И. Ленинның милли политикасы нигезендә, татар халкының фольклор әсәрләрен җыю, аның сәнгатен өйрәнү киң масштабларда алып барыла башлаган. Мин анда Бөек Октябрь революциясе нәтиҗәсендә татар халык сәнгатенең үсүен, аңа характерлы сыйфатларны тагын да ачыграк күрдем. Бу көнчыгыш характерындагы аерым югары сәнгать. Мәсәлән, пластинкага язып алынган һәм хәзер дә сакланган элекке татар музыкасы һәм җырлары кайгы-сагыш һәм моң белән тулы. Моннан чыгып тагын шуны әйтергә мөмкин, татар халкы рухи яктан да гарәп халкы белән тыгыз бәйләнештә һәм аларның уртак яклары бар. Татар халкы да күп еллар буе хаким сыйныфның җәберен татып яшәгән, монгол һәм башка басып алучыларның золымын күп күргән. Идел буендагы мәчетләр дә үзләренең төзелешләре, орнаментлары һәм бизәкләре белән бездәге мәчетләргә, бигрәк тә Каһирә һәм Багдад мәчетләренә охшый.

Татарстан дәүләт музее Кремльгә якын урнашкан. Кремль белән музей арасында Муса Җәлилгә һәйкәл куелган. Бу һәйкәл миңа бик ошады. Муса Җәлилнең (без аны «Моабит дәфтәрләре» буенча чын батыр һәм горур кеше буларак беләбез) бу гаҗәеп һәйкәле Геркулесны хәтерләтә. Муса Җәлилнең гәүдәсе нык чылбыр белән бәйләнгән, ләкин ул моңа каршы бунт күтәрә, бу хәл белән һич килешә алмый. Әгәр инде без музейга керәбез һәм барлык экспонатларны карап чыгабыз икән, берсендә дә Муса Җәлил рухын тойган шикелле бу-

лабыз. Бу рух зур адымнар белән алга баручы, ирек һәм үсәргә мөмкинлек биргән социализм идеяләренә ихлас күңелдән бирелгән татар халкы, Бөек Октябрь улларының рухы. Музейны карарга килүче һәр кеше бирегә тыныч күңел белән керә ала, чөнки ана татар халкының үсүе, аның сәнгате, гореф-гадәтләре турында тулы мәгълүмат алырга барлык мөмкинчелекләр бар. Ә музейның сотрудниклары исә бирегә килүче кунакларны аеруча җылы каршы алалар һәм татар халкының рухы, нәрсә белән яшәве, Совет Татарстанының үсүе белән тагын да якыннанрак танышуда зур ярдәм күрсәтергә әзер торалар. Кызганычка каршы, без 16 гасырга кадәрге Болгар чоры культурасы белән таныштыра торган бүлекне карый алмадык. (Кайбер бүлекләрнең ремонтка ябылган вакыты туры килде.)

* * *

Казан үзенең университеты, театрлары, Кремле, музейлары, Иделе һәм искиткеч елга порты белән генә түгел, талантлы һәм акыллы кешеләре белән дә матур. Бу талантлы кешеләр — татар халкының үсү нәтиҗәсе һәм алар аркылы бу халыкның бөеклеген һәм алга таба үсеш хәрәкатен тоймыйча мөмкин түгел. Чыннан да алар Габдулла Тукай, Муса Җәлил һәм Галимҗан Ибраһимовның туганнары, дуслары һәм укучылары. Алар Казанның фән һәм сәнгать кешеләре. Өлкән язучы Мирсәй Әмир, мәсәлән, Татарстан язучылар союзы председателе, 60 яшьләрендәге олы кеше, яшь ягыннан үзенә уллыкка ярый торган 32 яшьлек гарәп язучысын каршы алырга килде. Ул мине самолет трапына хәтле озатып, саубуллашып калды, Мирсәй Әмир һәм Татарстан язучылар союзының башка членнары гади, яхшы, зур культуралы һәм гыйлем ияләре. Дуслык, интернационализм, үз халкың белән горурлану, көнчыгыш рухы, гарәпләргә карата мәхәббәт саклау, ачык күңел, шаян һәм тапкыр сүз, тирән белемгә ия булу, безнең хәзерге тормышыбыз, тарихыбыз һәм гарәп халкының культурасы белән зур кызыксыну кебек әйбәт сыйфатлар хас аларга.

Мин татар язучыларының яшь буыны: «Казан утлары» журналының редакторы Рафаэль Мостафин, талантлы шагыйрь Илдар Юзеев, Рәдиф Гатауллин һ. б. белән дә таныштым. Язучыларның һәм шагыйрьләрнең күбесе университетта югары белем алып чыккан, ә кайберләре кандидат яки докторлык диссертациясен яклаганнар. Мәсәлән, Ибраһим Нуруллин үзенең беренче хезмәтен бөек татар шагыйре Габдулла Тукай иҗатына багышлаган. Аларның күбесенең үз өлкәләрендә зур кыйммәткә ия булган әсәрләре бар. Рафаэль Мостафин Муса Җәлил турында язган. (Ул Германия Демократик Республикасында булган һәм анда күп нәрсәләр күреп, кыйммәтле ачышлар ясап кайткан).

Муса Җәлилнең иҗатын өйрәнүдә, аны яңадан тормышка кайтаруда шагыйрьнең якын дусты һәм мирасын саклаучы күренекле галим һәм язучы Гази Кашшаф зур көч куйган. Шуңа күрә Муса Җәлил иҗатын өйрәнергә теләүче, һичшиксез, Казанга килергә һәм монда шагыйрьнең иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнүче Гази Кашшаф шикелле галимнәр белән очрашып сөйләшергә тиеш.

Бирелә шулай ук татар халкының зур кунакчыл халык булуын әйтмичә узу мөмкин түгел. Бу өлкәдә сәнгать кешеләре дә, язучылар да, гади халык та — барысы да бер үк төрле. Юмартлык һәм киң күңеллелек татар халкы өчен бик хас сыйфат. Мине бик күп артистлар, язучылар һәм башка кешеләр кунакка чакырдылар. Алар арасында әдәбият әһелләреннән Рафаэль Мостафин, Нил Юзиев, Илдар Юзеев, университет укытучысы Бижан Ситдиков, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының артисткасы Хәдичә Гыйниятова, «Ашхана» директоры Тәлгат Вәлиев, филология фәннәре кандидаты Мөхәммәт Мәһдиев, тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин һәм башкалар бар иде. Алар мине рәсми кунак итеп түгел, ә үз туганнары шикелле кабул иттеләр. Мин аларда үземне нәкъ үз өемдәге кебек хис иттем. Семья членнарының һәркайсы миңа зур игътибар һәм хөрмәт күрсәттеләр. Казан һәм Татарстан, аның культурасы турындагы истәлекләр, бүләкләр белән баштанаяк күмеп ташладылар. Алардагы патриотизм, интернационализм кебек сыйфатлар мине дә күп нәрсәгә өйрәтте һәм боларны мин һичкайчан да онытмам. Аерата Рафаэль Мостафинга карата булган рәхмәтем чиксез, чөнки ул, Мирсәй Әмир белән берлектә, минем бик зур хыялымны, бөек Казанны күрү хыялымны тормышка ашырырга мөмкинчелек бирде. Әгәр дә Рафаэль Мостафин минем йөрәгемдә үзенә аерым урын алган икән, бу әле башка артистларны, язучыларны һәм югарыда искә алынган иптәшләрне оныту мөмкин дигән сүз түгел.

* * *

26 апрель көне минем тормышымда онытылмас көннәрнең берсе булып калыр. Бу көнне мине бөек шагыйрь Габдулла Тукай һәйкәле янына шигырь бәйрәменә чакырдылар. Дөреслектә бу — Тукай көне һәм бер үк вакытта яңа татар поэзиясе көне. Анда Әзербайҗан, Башкортстан һәм Татарстанның күренекле шагыйрьләре үз шигырьләрен укыдылар һәм шулай ук миннән дә гарәп телендә берәр шигырь укуны үтенделәр. Мин бөек Тукай һәйкәле, аның туганнары алдында уку өчен — «Багдадтан Тукайга хат» дигән шигырь язган идем. Бу шигырьдә мин, гарәп буларак, совет Татарстанының якын дусты һәм совет халкын чын күңелдән яратучы буларак, үземнең хисләремне белдереп, үземнең йөрәгемне бөек Тукайга һәм аның мирасын бүген дә саклаучы улларына бүләк иттем. Халык тарафыннан хисләремнең кабул ителүе һәм хуплануы минем өчен зур шатлык иде. Алар күпмедер күләмдә минем гарәп телендә язылган шигыремне аңладылар кебек, чөнки азмы-күпме гарәп сүзләре аларга таныш.

Шагыйрьләрнең ачык урында, урамда халык белән очрашулары бик яхшы гадәт һәм бу бөек демократиянең чагылышы. Мондый очрашу халыкны поэзия белән, ә шагыйрьләрне халык белән тагын да якынайтырга ярдәм итә. Шушындый ук традиция Мәскәү шәһәрендә дә яши. Мәскәү шагыйрьләре үзләренең тыңлаучылары белән Маяковский мәйданында очрашалар. Бу традиция шулай ук элекке гарәп шагыйрьләрендә дә һәм хәзергеләрендә дә бар.

Элекке заманнарда шагыйрьләр үзләренең шигырьләрен турыдан-туры халыкка хаҗ кылу вакытында, сугыш кырларында һәм башка урыннарда укый торган булганнар һәм шигырь укуда бер-берсе белән ярышканнар. Хәзер исә безнең шагыйрьләребез (Хафиз Ибраһим, Әл-Җаваһири, Әл-Шәбиби, Әл-Язиҗи, Әл-Басир һ. б.) бу традицияләрне яңа формада дәвам иттерәләр һәм патриотизм рухын тәрбияләү, империализмга каршы көрәш, үткән буыннарның данын кире кайтару кебек темаларны үз шигырьләрендә киң яктырталар. Габдулла Тукайның туган көнендә аның һәйкәле алдында шагыйрьләрнең халык белән очрашулары да минем истән һич чыкмас.

Мине урамда бик күп яхшы һәм гади кешеләр чолгап алды. Алар арасында ак сакаллы картлар да, студентлар да, эшче яшьләр дә бар иде, һәм алар үзләренең миңа булган яхшы мөнәсәбәтләрен һәм теләкләрен белдерделәр. Аларның кайберләре миңа истәлекләр, кайберләре Казан шәһәре һәм Идел елгасы күренешләрен чагылдырган рәсемнәр, открыткалар бүләк иттеләр. Бер чал чәчле картны һич онытасым юк! Ул минем белән татарча сөйләшә башлады, ә мин аңа русча әйттем: «Мин татарча белмим шул». Шуннан соң ачыкланды: ул русча белми икән. Шул вакытта инде ул мине кочаклап үбүдән башка чара тапмады. Андый очрашуларның кеше күңелендә эзләрен югалтулары мөмкинмени? Бу — татар халкының гарәп халкына, совет халкының чын дусларына булган мәхәббәтенең чагылышы.

* * *

Өстәп шуны әйтәсем килә: бу язмалар минем мәшһүр Казанда бөтен күргәннәремне һәм бөтен ишеткәннәремне дә эченә алып бетерә алмый. Югарыда язып киткәнемчә, болар барысы да аерым китап язуны таләп итәләр һәм бу — якын киләчәктә, һичшиксез, минем тарафтан эшләнер.

Кем дә булса Казанга бер мәртәбә килә икән, Казан аны үзенең матурлыгы һәм сихрилеге белән әсир итә һәм бу кеше, һичшиксез, Казанга янадан килмичә булдыра алмый. Шәһәр чынлап та бөтен барлыгы белән һәм бигрәк тә үзенең акыллы, яхшы, гади һәм гүзәл кешеләре белән матур.

Татарстан язучылары, шагыйрьләре, артистлары, артисткалары, студентлары, укытучылары һәм галимнәре бүләк иткән истәлекләр һәрвакыт минем белән булырлар, гарәп һәм татар халыклары, совет һәм гарәп халыклары арасындагы дуслыкның символы буларак сакланырлар. Бөек татар халкының безнең гарәп халыкларына булган дуслык, интернационализм хисләре турында мин Багдадта да язармын.

Татар һәм гарәп халыклары арасында дуслык өчен (т ә р җ е м ә ч е д ә н: бу сүзләрне автор татарча язган)! Казанга һәм аның халкына дан!

Габдулла Тукайга, Муса Җәлилгә һәм бөтен Татарстан шагыйрьләренә дан!

Социализмга һәм Татарстанда социализмны төзүчеләргә дан!

Совет һәм гарәп халыклары арасындагы, татар һәм гарәп халыклары арасындагы дуслыкка дан!

Гарәп теленнән *Лена Яруллина* тәрҗемә итте.

*Аяз Гыйләҗев*

# Ә СИН ҮЗЕҢ КЕМ, УКУЧЫ?!

Шагыйрь, драматург Әхсән Баянов повесть язды. Бу әсәр тирәсендә бәхәс башланып китте, укучылар редакциягә бер-бер артлы хатлар җибәрделәр. Шул материаллар белән танышкач, моңарчы күңелне кытыклап кына йөргән кайбер фикерләр, реаль сораулар булып, күз алдыма бастылар.

Без: әдәбият үсә, тирәнәя, язучылар тормышның тирән катлауларына, кеше психологиясенең моңарчы кагылынмаган нечкәлекләренә үтеп керә башладылар, дип куанабыз. Ә укучы? Әдәбият тирәнлекләрендә «йөзә» аламы ул? Үсәме? Аны кем үстерә? Бу эш үз агымына куелганмы, әллә билгеле бер юнәлештә алып барыламы? Гомумән, язучы белән укучы арасында мөнәсәбәтләр нинди? Шушы һәм башка фикерләремне укучылар белән уртаклашырга булдым.

Безнең нәширләр, җае чыккан саен, мактанмый калмыйлар: «Казан нәшрияты РСФСРда өченче урында, ул Мәскәү, Ленинград нәшриятларыннан гына калыша. Без өч көн саен укучы өстәленә бер матур әдәбият китабы чыгарабыз», диләр.

Өч көнгә бер әдәби китап күпме бу? Бик күп. Моңарчы кешелек тарихы калдырган иксез-чиксез китап байлыгы булганга күп. Университетның фәнни китапханәсенә, аның китап саклау залларына керегез. Хеопс пирамидасы кебек өелгән китапларга күз салыгыз. Казан нәширләренең мактанычы, безнең әдәбиятыбызның хәрәкәтен билгеләгән «өч көнгә бер китап» әнә шул бихисап байлыкка өстәлә бара. Бу бәһасыз байлык тулаем укучы кулында: эзлән, тап, укы, өйрән, ярат.

Хәзерге заман укучысы күп укыймы? Әйтик, авылларда сыер савучы кыз-киленчәкләр елга ничә китап караштыралар? Укыганны хәтерлиләрме, язучыларны беләләрме? Газета-журналларда басыла торган тәнкыйть-библиография материаллары белән танышып баралармы?

Үземнең сорашу, күзәтү нәтиҗәләреннән чыгып әйтә алам: шактый укыйлар! Безнең кулда тагын анык бер дәлил бар: татар телендә чыга торган газета-журналларның тиражы ел саен күпләп арта тора. Куанычлы хәл. Элекке укучы белән хәзерге заман укучысы арасында чагыштырмасыз аерма бар.

Менә элекке заман укучысы. Бер әби. Ул үз гомерендә ничә китап укыгандыр, әйтү кыен. Иң яраткан китабы «Моңлы хатын Бибигайшә» исемле. Ул колак артына күзләгән җеп белән бәйләп куя да, кадерләп, олылап еш кына шул нәни китапчыкны ача. Бибигайшәнең ирсез, баласыз калуын тасвирлаган беркатлы, хәйләсез такмазалар теземеннән торган, әбигә күптән мәгълүм булган тарих һәрчак аның күз яшьләрен сытып чыгара. Әби укый да рәхәтләнеп, кинәнеп бер җылый, башка китаплар белән бөтенләй кызыксынмый. Моңлы хатын Бибигайшә тарихы аның рухи ихтыяҗын тулаем канәгатьләндерә. Шушы китап — аның эчке дөньясы, аның эстетик һәм әхлак үлчәве. Әби бу китапта язылган һәр сүзгә икеләнүсез, шик-шөбһәсез ышана, аңа табына, язучы моны тормыштан бер дә бозмыйча, түкми-чәчми күчереп алып, көйгә салган дип уйлый. Әгәр китапның зәвыксыз, төссез такмазалардан гына торуын, әдәби кыйммәте бик-бик түбәнлеген, ниһаять, китапның әнә шул зәвыксызлыгы белән кеше рухын ярлыландыруга китерүен әйтсәң, бабкаларен усалдан саклаган әнкә каз кебек, сиңа ташлана! Әдәбиятның альфа һәм омегасы аның өчен шушы китап.

Мин элек бөтен укучылар да шулай булган дип расларга җыенмыйм. Әмма бу мисалда без кайбер кешеләрнең бик аз укуын, шул азга канәгать булып яшәүләрен күрәбез. Шуның өстенә күп кенә укучылар китап сүзенә, ташта басылганга икеләнүсез ышанып, сукыр рәвештә табынып килгәннәр. Китапның сәнгатьчә югарылыгы, аның шәхес-язучы тарафыннан иҗат ителеп, мәгълүм бер идеяләр алып килүе турында уйланып, фикер йөртеп тормаганнар. Югыйсә, бик арзанлы эффектларга корылган «Моңлы хатын Бибигайшә» кайберәүләрнең өстәл китабына әйләнеп китәр идемени?

Бүгенге көндә эш ничек тора? Китаплар күп басыла, аннары рус телен белү татар укучысының офыгын киңәйтте. Шулар өстенә хәзерге укучы көн саен, сәгать саен кинофильмнар, радио-телевидение, газета-журналлар аша әллә никадәр информация,

белем ала. Әдәбиятның аудиториясе гаять дәрәҗәдә киңәйде, укучының гомуми белем дәрәҗәсе үсте. Ә әдәби китапларны аңлау, кабул итү җәһәтеннән нинди үзгәрешләр бар? Дөрес, бу турыда төгәл статистик мәгълүматлар, социологик өйрәнүләр юк шикелле. Фикер йөрткәндә күбрәк шәхси күзәтүләргә нигезләргә туры килә. Хәзер дә кайбер укучылар әдәби әсәрне тормышның үзгәртелмәгән фотографиясе дип кабул итәләр, аның ноктасына, өтеренә кадәр уйсыз-бәхәссез ышаналар. Моның ачык мисалын язучылар, редакцияләр ала торган күп санлы хатларда күрәбез. Очрашуларда да еш кына бер үк традицион сораулар бирәләр: «Фәлән әсәрдәге төгән абый яки апа (боларны хикәянең геройлары була инде!) хәзер кайда яшиләр? Исәннәрме алар? Очрашалармы?» Әсәрнең герое бер матур кыз икән, егет-җилкенчәккә тәмам җитә кала: адресын белергә теләп, туктаусыз хатлар салалар.

Бу мәсьәләнең тагын бер кызыклы ягы бар. Сәхнәдә уйнала торган образларның — геройларның адресы белән бирәү дә кызыксынмый. Чөнки сәхнә образларын чын дип кабул итмиләр, сәхнәдә тамаша, уен бара. Бу кызык кына, «ул тузга да язылмаган, ташка да басылмаган!» Шуның өчен булса кирәк, драматурглар хатларны сирәгрәк алалар. Алган тәкъдирдә дә аларга күбрәк: «Сезнең пьесагызны каян табарга икән», — дигән эшлекле үтенечләр белән мөрәҗәгать итәләр.

Ташка басылган әсәрләрне турыдан-туры, тукми-чәчми тормыштан күчереп алынган дип уйлау һаман яшәп килә. Әле күптән түгел генә Пермь өлкәсендәге Барда районы Озын Ялан урта мәктәбенең 8 класс укучысы Нәсимә Мусинадан хат алдым. Кызыклы, тормышчан күзәтүләр белән тулы хатын ул болай дип тәмамлый: «Өч тәгәрмәчле арба» исемле хикәягезне укыдым... Ни өчен сез Луиза белән Рәшатны аердыгыз? Соңыннан алар аңлашып кушылмадылармы?»

Укучыларның әдәби геройларны чыннан да бар итеп, турыдан-туры тормыштан китапка кереп киткән дип кабул итү фактлары да аз түгел. Әйтик, Твардовскийның мәшһүр Теркины, атаклы солдат Швейк һ. б. Мондый бәхетле очракларда язучы тудырган әдәби герой халык күңеленә чыннан да хуш килә, укучы аңардан башка яши алмый, аны үзенең көндәлек тормышында иптәш итә. Күп илләрдә халык арасында киң таралган әдәби геройларга һәйкәлләр дә куелган. Америкада Марк Твен геройларына һәйкәлләр бар. 1966 елда «Литературная газета» Голландия шәһәре Дельфсейлда Ж. Сименон романнарының халык яраткан герое Мегрега һәйкәл ачылуын хәбәр итте.

Ләкин болар икесе ике төрле, ике нигездә барлыкка килгән күренешләр. Беренче очракта без укучының әзерлексез булуын, китапны беркатлы, нибары тормышның фотографиясе итеп кенә аңлавын күрсәк, икенче очрак укучының әдәбият белән тирәнтен кызыксынуын, аны кабул итә белүен, яратуын раслый.

Мәгълүм белеме, әдәбиятны аңлау тәҗрибәсе булган укучылар да кайвакытта язучыга тормыштагы вакыйгалар тезмәсен җыеп утыручы кеше дип кенә карыйлар. Әдәбиятны болай примитив, гадиләштереп аңлау, аны асыл, тирән сыйфатларыннан, мәхрүм итү каян килә соң? Беренчедән, моңа безнең нәшриятларда, журналларда түбән зәвыклы, примитив әсәрләр басылып чыгу сәбәпче, икенчедән, бериш тәнкыйтьчеләрнең шундый характердагы әсәрләрне күтәреп, мактап йөрүләре, аларны ниндидер үзгәрмәс эталон итеп раслауларында. Болар барысы да безнең укучыларның әдәби әзерлегә үсүгә комачаулый торган факторлар.

Әдәби әсәрне аңлау һәм аңлатуда кайбер тәнкыйтьчеләр күптән тапталган, шаблонлашкан схемалар белән эш итәргә яраталар.

Әйтик, әдәби әсәрнең схемасы. Кире һәм уңай геройлар, бүленеп, ныклы бер принцип белән тамгалап куелганнар. Уңай герой эчми-тартмый, гел яхшылык эшләп йөри, һәйбәт, кешелекле. Кире геройны арты белән мичкә керсә дә таный алаcың, ул уңай геройның нәкъ киресе: сүз тыңламый, аракы да йоткалый, акны кара дип, караны ак дип ышандырыга тырыша. Нәтиҗәдә... анысын барыбыз да китапның беренче битен ачуга ук беләбез: әйе, әйе, уңай герой теге хәерсезне җиңеп чыга!

Бик гади һәм җайлы схема! Язучылар өчен дә, укучылар өчен дә, тәнкыйтьчеләр өчен бигрәк тә. Барысы да үз урынында, сарык та исән, бүре дә тук. Әсәрнең гадәти схемасы әзер, тәнкыйтьче иптәш, техник контроль бүлегенә сакка куелган кеше кебек, стандартын тота да шапы-шопы үлчи башлый. Иңе-буе, авырлыгы, метры-метрга, җеге-җеккә, җебе-җепкә туры киләме? Килсә — булдырган, килмәсә, шалт авторның башына берне! Моннан болай тыңлаусыз булмасын, кешеләрнең тынычлыгын бозып йөрмәсен!.

Примитив әсәрләрнең иң куркыныч ягы шунда, алар укучының уйлау сәләтен бетерәләр, һәрвакыт, һәрчак әзер, стандарт фикер тәрбияләп, шуны сеңдереп киләләр. Андый арзанлы әдәбият укучының җәмгыять үсешенә, тормыш күренешләренә җентекле күз белән карау сәләтен үтерә, кешеләрне уйга, анализга сәләтсез гап-гади винтиклар булырга мәҗбүр итә. Әдәбият исә, барыннан да элек, хөр фикерле гражданнар тәрбияләргә тиеш. Тормышны бизәп, яшәүне ансат, уен итеп кенә сурәтләүче язучылар гади укучыны ялгыш нәтиҗәләргә китерәләр. Я ул, тормыш белән әдәбият арасындагы каршылыкларны үзе табып, ни тегесенә, ни бусына ышанмый башлый. Яки исә, әдәбиятта язылган беркатлы тормышны чын итеп кабул кыла да, үзе ялгышып яши башлый. Әдәбият кешесе тормышның тирән каршылыклар күрәше, фикерләр, характерләр күрәше икәнлеген бервакытта да онытмаска тиеш.

Әдәбият күренешләрен схематик аңлатулар, ясалма рәвештә язучыларны «акка,

карага» бүлеп йөртүләр, укучыда язучының шәхси мастерлыгын, аның кеше буларак фикерләрен, индивидуальлеген ачарга комачаулый. Укучылар да шуңа ияреп китсәләр, стильләре, дөньяга карашлары төрле-төрле булган язучыларны әлеге дә баягы яманаты чыккан схема буенча аерып йөртә башлыйлар. Кай очракта бу аларның мәхәббәтләрен яки нәфрәтләрен билгеләүче үлчәү булып та хезмәт итә. Язучының стиль үзенчәлеген тою, аны шәхес буларак аңлау, иҗатының идея-эчтәлек юнәлешен эзлекле тотып алу — болар барысы да укучының югары культурасын, әзерлеген раслаучы фактлар. Аңарда бу нечкәлекне бер яктан, югары художестволы әсәрләре белән, язучы үзе тәрбияләсә, тәнкыйтьче дә турыдан-туры булышырга тиеш. Тәнкыйтьче укучы белән язучы арасында арадашлык итүче, язучы күтәргән тормыш күренешләрен әдәби хәрәкәткә бәйләп аңлатып баручы булырга тиеш. Укучы язучыны, тормышка салкын күзәтче булып, каяндыр югарыдан карап утыручы һәм кәефе килгәндә күргәнбелгәнен кәгазьгә теркәп баручы дип уйламаслык, язучының тормышта иң актив шәхес булып, тормыш күренешләреннән үзенә кирәкне генә сайлап алуын, аларга анык бер идея юнәлеше биреп, әсәргә теркәвен белергә тиеш. Һәр оста язучының үзенә генә хас «һөнәр сере» бар. Аны беркинди схемалар, бүленешләр белән дә аңлатып булмый.

«Казан утлары» журналы менә ике ел инде «Укучылар сүзе» дигән бүлек алып бара. Бик кирәкле, гыйбрәтле һәм күпне сөйли торган бүлек ул! Анда капма-каршы фикерләр, бәхәсләр, шик-шөбһәләр, мактау сүзләре, усал-усал тәнкыйть фикерләре янәшә урын алалар. Бик дөрес! Югыйсә, минем бер әсәрем турында бер үк газетада ике төрле фикер басылгач, кайберәүләр: «Ничек инде, бер үк газета, бер үк әсәр турында капма-каршы фикер әйтеп чыга?» дип, бик сәерсенгәннәр иде. Бик кызганыч. Мондый фикер әйтүчеләр газета укучы меңләгән кешеләр бер үк төсле фикер йөртергә тиеш дип уйлыйлар микәнни? Ни өчен әсәр бөтен кешегә дә һичсүзсез ошарга яки ошамаска тиеш? Һәркемнең үзе генә яраткан җыры юкмыни? Нигә көчләп-көчләп, тырышып-тырмашып укучыларны нәкъ бертөсле фикерләргә табындырырга?

Әдәбият, бигрәк тә аның тәнкыйть өлеше, укучыда үзбаш уйлау сәләтен үстерергә тиеш. Тузга язылган сүзләр күп, ташка басылган сүзләр дә күп, әмма тәнкыйть бер генә. Социалистик реализм методының киңлеге, юмартлыгы турында рус әдәбият фәнендә күп яздылар. Бездә исә социалистик реализмны һаман да берьяклырак аңлау, аны әлеге дә баягы схемага тартымрак итеп күрсәтергә тырышу яшәп килә. Хакыйкатьне, дөреслекне әсәрдән укучы үзе табарга өйрәнсен. Әдәби китап табыну, сукыр рәвештә инану өчен язылмый. Тормыш күренешләре әсәрдә язучының аң призмасы аша үткәннәр. Әсәр артында үзенең аңы, дөньяга карашы, нидер раславы, нидер кире кагуы белән аерым кеше — язучы тора. Ул сиңа мөрәҗәгать итә, укучы! Син укы, уйлан. Уйланмыйсың икән, бу синең фаҗигаң!..

1966 елның көзендә Казанда — республика үзәк китапханәсендә — укучылар белән очраштык. Шул күңелле мәҗлестә Мөслим районында унынчы классны тәмамлап килгән, хәзер университетның филология факультетында укучы (димәк, гомерен әдәбиятка багышларга карар кылган!) бер студент чыгыш ясады.

«Яхшы әсәрләрне журналда ничек тәнкыйтьләргә мөмкин? — диде ул бик ачыргаланып. — Менә без, унынчыда укыганда, Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы буенча укучылар конференциясе үткәрергә җыендык. Әсәр безгә бик охшады. Нәкъ шул чакта журнал битләрендә романга тәнкыйть сүзләре басылды. Без ни әйтергә дә белмәдек, укытучыбыз да тәмам югалып калды. Конференцияне үткәрмәдек, ул шулай өзелде».

Мин бу чибәр егетне бик кызгандым. Гомумән, бу мәктәптә, бу укытучыдан әдәбият дәресләре тыңлаган укучыларны кызгандым. Алар шулай һәр басылган сүзгә инанып, колларча табынып киләләр микәнни? Әллә инде Г. Әпсәләмов бер чакта да тәнкыйтьләнергә тиеш түгел, татар әдәбиятында тәнкыйтьләнә торган кеше Әмирхан Еники генә дип уйлыйлармы?!

Укучылар романны укыганнар, яратканнар. Бик әйбәт, бик табигый. Чыннан да, һәйбәт роман! Ул укучыларда яхшы тәэсир, матур уйлар тудырган икән, алар моңа нигезле рәвештә ышаналар икән, журналда басылган тәнкыйть сүзләре аларда бәхәс уятырга тиеш иде! Журналда басылган фикерләр белән бәхәскә керсеннәр, аларны тетеп салсыннар иде. Алай булмаган, кызып-кызып романны мактарга йөргән укучылар, суга төшкән тавык кебек, җебеп калганнар. Ышанмыйм мин андый укучыларга. Романны, Әпсәләмовны яратуларына да ышанмыйм. Кирәк чакта хак сүз өчен кангакан килеп сугышачакларына да, нык торачакларына да ышанмыйм. Әгәр син язучыга ышанасың икән, аның идея концепцияләрен үз итеп кабул итәсең икән, ахырынача сүзеңдә тор! Үзең тапкан, тормышта әле сөелеп, әле кыйналып үзең сайлаган хакыйкатьне көн саен, җил искән саен алыштырып булмый ич! Дөньяга караш, кешелеккә караш, эстетик нормалар, өстәге кием кебек, сезонга карап алышынмый. Мин сукыр рәвештә, фанатикларча киреләнеп ышану турында түгел, марксизм-ленинизм тәгълиматларына нигезләнгән аңлы, дәлилле ышануны күз алдында тотам. Диалектик материализм, тормышның каршылыклар көрәше икәнен раслаучы тәгълимат, үзе инде ышанычлы компас!

Китаплар күп. Күп һәм төрле-төрле. Укучылар да күп. Алар да төрле-төрле. Укучы бөтен басылып чыккан китапны укып бетерә алмый. Шуның өчен укучы үз күңеленә хуш килгән язучыны сайлап ала, аны укый, ярата. Әгәр бу шулай икән, укучы киң күңелле дә булырга тиеш. Ул башка авторлар хезмәтенә дә (сүз чын язучылар,

каләм мастерлары турында бара!) хөрмәт белән карый белсен. Бәхәсләрдә түземлелек, такт күрсәтсен. Ләкин, һичшиксез, бәхәсләшсен! Бездә әнә шул түземлелек, киң күңеллелек җитеп бетми. Безнең бер-ике китап укыгач та, нәни генә диктатор буласыбыз килә. Безгә ошаган әсәр генә яшәсен, мин яратканны гына басsыннар. Язучы да мин теләгәнне генә язсын.

Мәдинә Маликованың «Казан утлары» журналының 8 санында басылган «Кем ул Әнис Бадигин?» дигән мәкаләсе дә әнә шундый түземсез кискенлек, диктаторлык рухы белән сугарылган. Автор повестьны укып чыккан да, кайнарланып, кусәкнең иң саллысын эләктергән һәм, абайламыйча-нитмичә, түбәләргә керешкән. «Ташка басылган» бу мәкаләнең югарыда телгә алынган бериш әзерлексез укучыларда теләктәшлек уятуы бар. Алар уйлансын, хакыйкатьне тапсын өчен, мин дә повесть турында берике сүз әйтергә уйлыйм.

М. Маликованың ачуын иң нык кузгаткан мәсьәлә — Ә. Баянов повестенда хатын-кыз образларының чагылышы. Ул, повестьтагы Фәһимә, Лена образларын үз канаты астына алып, язучыны дөреслеккә, әдәбият кануннарына хыянәт итүдә гаепли. Бу чыннан да шулаймы? М. Маликова тырышып-тырышып яклаган Лена чыннан да чая, яхшы холыклы, әйбәт кешеме?

Повестька мөрәҗәгать итик.

Менә Лена белән танышабыз.

Ояда кош балалары авыз ачып утыра. Әнис Бадигин бер кошчыкны тотып ала да һавага чөя, тагын берне, тагын... Ни өчен? Кем өчен?... Бу кыланчык үсмернең үз фәлсәфәсе, куркыныч фәлсәфәсе яралып килә: «Көчсезләрне рәнҗетүдән куркырга ярамый»...

Шушы куркыныч, әшәке фәлсәфәнең туып килүен күргән Лена эче катып көлә, Әниснең егетлеген хуплап соклана.... Менә Лена шәһәргә укырга килә. Юк, юаш, мескен бер авыл кызы булып түгел, яулап алучы булып килә. Чөнки аның абыйсы шушы шәһәрдә Министрлар Советында эшли. Ансат кына укырга урнаша, чөнки «авылдан отличник документлары табып килгән». О, Лена ялгыз түгел, аның көчле абый-апалары авылда да бар икән ләбаса!..

Лена Әнискә гашыйк була. Бик сәер, театральный, ясалма бу мәхәббәт. Лена, «артистлар сыман башын артка чөеп», үзенең мәхәббәтен белдерә. Оялчан, саф булып түгел, кыланып, өйрәнелгән хәрәкәт белән, артистларча... һәм ничек ди әле! «Мин бик көнче, кара аны, мин сине үземнән башка берәүгә дә бирмәячәкмен».

Әниснең укырга кая керүен дә нигездә Лена хәл итә. Кыз өчен аның кайда укуы, кем булуы да мөһим түгел, тик Әнис аның янында гына булсын. Вакыты килер, Лена үз ирен дә абыйсы кебек үк, биектә оча торган могтәбәр әһел ясаячак. Үзенең укырга сәләте юк икән (бәлки теләгедер дә!), зарсыз-моңсыз гына мәктәбен ташлап чыга да шундук эшкә урнаша.

Шәһәр Әнисне куркыта. Шәһәр тормышы иркә Әнисне, тормышка җайлашмаган, йомшак авыл малаен өркетеп, кире авылга таба куа. Тик аның юлын Лена кисә: «Җүләр... тапкансың выход!» ди ул. һәм бик кулай, бик җайлы юл тәкъдим итә: әйдә, өйләнешәбез!

Лена батыр, көчле, ул бер почмактан икенчесенә актив рәвештә Әнис боламыкны сөйри. Үзләренә квартир кирәк булгач, Ленаның моныcын да уңышлы хәл итәчәгенә Әнис тамчы да шикләнми. Ул кызны җитәрлек күрде, сынады. «Лена тотынса... ул аны башкарып чыга да чыга инде», дип уйлый Әнис.

һәм чая Лена кыш уртасында квартирантларны акыртып-бакыртып урамга кудырта. Туй дип атала торган фарста Әнис эчеп-исергәч, Ленаның үз якыннарыннан берәү, җан ачысы белән: «Нинди яшь малайны харап иткәннәр!» дип куя.

Тормыш исереклегә дә, хәмер пары да миенә йөгергән, элек-электән авантюризмга омтылыбрак яшәгән Әнисне бу сүзләр сискәндереп җибәрә. Әмма ул үзе кереп капкан читлекне җимереп чыгарлык хәлдә түгел. Ул пассив рәвештә, тормыштан читтә торып, уйлана гына ала: «Кайчандыр җанымны үзенеке иткән Бетховен инде миннән читләште бугай», дип җанының күгәрек белән каплануына үкенеп куйгалый. Ләкин сүздән эшкә, хәрәкәткә күчә алмый.

Лена Әнисне сөяме? Сөйми. Хәтта Фәһимә дә сөйми аны, Валя да яратмый аны. Нигә соң алар барысы да Әнис дип өзелеп торалар? М. Маликова бер нәрсәгә игътибар итмәгән. Повестьта телгә алынган, Әнис Бадигинга ниндидер мөнәсәбәттә булган кызлар барысы да яшь ягыннан аңа караганда олыраклар. Мәхәббәттә дә, тормышта да алар тәҗрибәлерәк, акыллырак. Шуның өчен дә инициатива, активлык кызлар кулында. Фәһимә дә, Лена да, Валя да, МТСтан ашлык кабул итәргә килгән үлчәүче кыз да беренче булып сүз каталар, мәхәббәтләрен башлап үзләре белдерәләр.

Бу ни хәл? Кайда соң татар кызларының атаклы тыйнаклыгы, сабырлыгы? Менә монда без катлаулы тормыш фаҗигасе белән күзгә-күз очрашабыз. Эш шунда: Фәһимәләр, Леналар яратырлык егетләр барысы да фронтта, авылда «дефицит булып» әнә шул Әнис кебек яшь этәчләр генә калган. Буй үскән, акыл үсмәгән. Әнис азмыкүпме музыкаль малай, шул сәбәпле кызлар аңа тартыла да. Тартылучылар арасында Лена кебек әрсезләре дә, Фәһимә кебек тыйнаклары да бар. Үз ишләреннән, яшьтәшләреннән аерылып калган, сөеләргә-сөяргә өлгермәгән яшь күңелләр кая барып сугылырга белмәгәч, әнә шул Әнис кебекләргә барып баш иялар. Бу — шул чорның иң кырыс дөреслеге. Фәһимә Әниснең бала-чага икәнлеген, акылы сай икәнлеген,

яратуны аңламавын белмиме, төшенмиме? Бик белә, аңлый. Фәһимә белән мәхәббәтләре нәкъ кызып кына килгәндә, болынга ат белән председатель — Әниснең кардәш абыйсы Сафуан килә һәм малайны үзе белән авылга кайтырга чакыра. Бер якта кайнар мәхәббәт, икенче якта председатель атына утырып йөрү. Әнис соңгысын сайлый... Сизгер Агыйдел кызы Фәһимә барын да аңлый: «Эх, син юньсез малай! Бер тиенлек акыл да юк синдә! Бер тиенлек тә!» ди.

Фәһимәнең Әнис белән мавыгуы әсәрдәге иң көчле, иң хисле, иң фаҗигале урыннар. Фәһимә, очраклымы, әллә алдан уйлапмы, атылып үлә. М. Маликова катгый хөкем чыгарып та өлгерә: Фәһимәнең үлемендә аз да түгел, күп тә түгел, Әнис кенә гаепле! Ленаның фаҗигасендә дә Әнис кенә гаепле, ди ул.

Ялгыш караш. Акыллы Фәһимәне нибарысы боламык, пешмәгән бер егет корбаны дисәк, без Әнисне артык күтәргән булырбыз. Хәлбуки, Фәһимәнең һәлакәте күп тапкырлар тирәнрәк яшеренгән. Тик автор, ни өчендер, аны ачыкламаган, тиешле урынга нокта куймаган. Фәһимә образы логика сораган дәрәҗәдә укучыга ачылып җитми.

Ә Әнис Бадигин үзе кем соң? Каян килеп чыккан бу хәзерге заман усалы? Авыл малае. Табигать аңа күпмедер музыкаль сәләт, матурлыкны тою хисе биргән. Аңа уналты яшь. Ул өченче елын инде печән чаба. Аның без белгән тормышы шактый мәгънәле башлана. Ул үз баянында да кешеләрдән куркып уйнарга мәҗбүр. «Курку гадәткә кергән», ди Әнис бер урында. Куркак кеше көрәшкә, хәрәкәткә сәләтсез була. Әнис тә шундый. Аның кош балаларын кырып йөрүе, теше белән тере куянны буазлавы куркак һәм садист икәнлеген ача. Шулай да Әнис алга талпынып карый. Музыка мәктәбендә укыйсы килә. «Мин шунда укыйрием». Менә син кая сикермәкче. Авылда андый мәктәпләр юк. Уналты яшьлек үсмер моның белән килешергә теләми: «Ә ни өчен юк?» Бу гаделсезлек аның җанын әрнетә, гомумән авылдашларының яшәеше, көнкүреше аны канәгатьләндерми. Кибән башына менгән Тимербикә апасыннан ул: «Әйт әле, син анда басып торганда ниләр күрәсең, ниләр уйлыйсың?», дип сорый. Омтылышсыз, җансыз Тимербикә аның ачуын чыгара, ул бу мохитны «ыргылып, сикереп үтәргә тели». Фәһимәгә дә: «Мин каядыр китәчәкмен!» ди.

Тормыш та, эш тә матур әле Әнискә. Юк, М. Маликова әйткәнчә, повестьның баш өлеше Ә. Баянов аерым бер талант күрсәтеп язганга матур түгел, әле үсмернең тормышы м а т у р, тирә-ягы м а т у р. Ул әле әкиятләр, хыяллар дөньясында яши, аның тирә-ягы ал да гөл. Ул җирдәге моң-зарны аңларга өйрәнмәгән. Әле үзенең бәхет өчен көрәшергә көчсез икәнлеген, күңеленең гариплеген аңлау өчен, аңа күпне күрергә, күпне кичерергә кирәк булыр. Нишлисең, Әниснең тормышы туры гына бармый, ул күңеле теләгән кешеләрне очратмый, эзләми дә, шәһәргә барып туп-туры Ленаның һәм аның кардәшләренең җәтмәсенә эләгә. Шушы хәләте белән тиз ризалаша, көрәшми, рухы сына, үзенең яшьлек хыялларыннан бик тиз, ансат баш тарта, бер-бер артлы кешелек моралена хас булмаган тупаслыклар эшли. Квартирадан куып чыгарылган Шәһиәхмәтовны тотып тукмый... Болай гына, сүз арасында, егетлек дәрәҗәсен саклап калу өчен генә. Кош балаларын үтергәндә шаркылдап көлгән Лена ир кешене тотып тукмый алган Әнис турында нәрсә уйламас! О, егет икәнсең син, Әнис Бадигин дияр. Леналар мохиты бу кавырсыны катмаган сәер егеттән ялган кеше, әшәке кеше, кара эчле кеше, эгоист ясыйлар, бөтен тормышын гарипләндерәләр. Әнис Бадигин әсәргә турыдан-туры усал булып килеп керми, ул безнең күз алдыбызда акрын-акрын үзгәрә, түбәнгә, пычракка тәгәри.

Ләкин повесть бер Әнис Бадигин турында гына түгел. М. Маликова әсәрнең кыйммәтле ягына, Әнистән башка якларына бөтенләй игътибар итми. Әгәр әсәр шушы пешмәгән үсмернең тозсыз мәхәббәт маҗараларына гына корылса һәм нибарысы аның төпсез эгоизмын күрсәтүгә генә хезмәт итсә, повестьның бәясе бик чамалы булыр иде. Дөрес, автор «лирик повесть» дип, аның жанрын дөрес билгеләмәгән, гомумән мәхәббәт линиясенә артык игътибар биреп, кирәкле-кирәксез фәлсәфи чигенешләр белән мавыккан, тормыш тасвирларын сараңландырган. Ләкин автор теләгәнме-теләмәгәнме, әсәр, Бадигинның мәхәббәт маҗараларыннан узып китеп, тормыш чынлыгына үтеп керергә омтылыш ясаган. Бу омтылышны, һичшиксез, хупларга кирәк.

Кызларны һәм Әнис язмышын тасвирлаганда, автор кырыс дөреслек ягында, дигән идек без. М. Маликова исә стандарт, барыбызга да мәгълүм тәчелекне таләп итә. Һай, Әнис, консерваторияне алтын медаль белән бетереп, Фәһимәгә өйләнеп, атказанган артист булып китсә, бала-чагалар үстереп, Агыйдел буенда карлыган җыеп, эчми-тартмый гына яшәп ятса, нинди гүзәл булыр иде! Тик тормыш берәүгә дә стандарт гомер юлы әзерләп, аны шомартып, гөлләр чәчеп куймаган, укучыны алдарга, тирбәтергә ярамый, тормыш законнары күптән мәгълүм булса да һәр буын, һәр кеше аны үзенчә ача. Берәүләр бу яшәү юлында — аны көрәш дип атыйк — чыныгалар, җәмгыять өчен файдалы кеше булып китәләр. Икенче берәүләр сыгылалар, һәм җәмгыять алар турында үзе кайгыртып яшәргә мәҗбүр була. Әнис тә шундыйлардан. Дөрес, ул ахырдан авылга кайта, эшли, комсомол оешмасы секретаре булып сайлана. Ләкин аның канаты сынык, ул үз көчен чамаламыйча югарырга омтылган, ләкин оча алмаган, урта кул кеше булып яшәү аңа күңел рәхәте бирми. Чөнки ул тормышка берни бирмичә күпне алырга өметләнгән, ул Леналар йогынтысында үскән, муллыкны, рәхәт яшәүне күз кырые белән генә булса да күргән кеше. Нишлисең, әгәр шулай яшәсә Әнис Бадигин әле бер генә абынмас, яшәү мәгънәсен ниндидер шаккатыризмнарда түгел, гадилектә һәм тырыш, намуслы хезмәттә икәнлеген аңлар. Тимербикә

кебек гади кешеләрдән көлеп, мыскыллап карамас. Аңламый икән, гомере буе сөрлегеп, кыйналып, канәгатьсезлеген эчкә җыеп, куенында таш асрап яшәргә мәҗбүр булыр.

М. Маликова Әнис Бадигинга, аның белән бергә повестька приговор арты приговор чыгарып хөкем итсә дә, әсәр үзенең мәгънәви эчтәлеге, тормыш күренешләренә үзенчә үтеп керә алуы белән, дөреслеге белән кыйммәтле.

Мин дә яратмыйм Бадигинны! Шаһиәхмәтовны куып чыгарганда, бөеренә таянып, гаярьләнеп торуын күз алдыма китерсәм, йодрыкларым йомарлана. Нәфрәтләнәм, күрәалмыйм. Ләкин бу тормыш. Бар бит, Леналар да бар, аның абыйлары да бар, аларга койрык булып киткән Бадигиннар да бар. Без аларны белергә, нәфрәтләнергә тиеш.

Автор Әнис Бадигинны үзенең идеалы, уңай герое, чынбарлыгыбызда үзе күрергә теләгән бердәнбер кешесе дип тәкъдим итми! Монда бер «ләкин» бар... Әсәр башындагы катлы-катлы кереш сүзләр, томанлы эндәшләр, ятышсыз кинаяләр М. Маликованы буталышка китергәннәрдер? Әхсән Баяновның шундый кирәксез жестларга хиреслеге бар. Әсәрнең башындагы кереш сүзләр, купшы мактанулар — ят, кирәксез мотивлар. Бу кереш сүзе Лермонтовның «Безнең заман герое»на керешенә ошатырга тырышу гына. Әсәр ахырындагы Агыйдел симфониясенең үлүенә офтанулар исә Экзюперине бик-бик хәтерләтәләр. Әнис Бадигин авызыннан әйтелгән мондый югары сүзләр ялган булып яңгырыйлар, аннары мондый ук тышкы охшашлыклардан әсәрне арындырырга кирәк булган.

Журналда әсәрне беркадәр «төзәтеп» басканнар сыман. Кыскартып мәгънәгә зарар китергән урыннар да бар. Бадигинның хаклык эзләп Кавказга сәяхәт ясавы аңлашылмый. Милиционерның да ни өчен аны үз итүе, ярдәм кулы сузуы билгесез.

Җитешсезлекләре бар повестьның. Әмма әсәрдә күңелне тетрәтерлек, тормыш дөреслеген мастерларча ачып салган битләр дә бик күп.

Үтә каршылыклы Сафуан образын алыгыз. Бер яктан, башак эзләп, хатын-кызларның итәк асларын актара, икенче яктан, игеннәрне кызганып, трактор тәгәрмәче астына ята...

Ә теге акылдан язган, сәке астына качкан Хәтирә...

Шул Сафуан бит инде аның котын алды... Шул Сафуан үзе үк янып үлә. Нинди каршылыклы, катлаулы бу тормыш дигәнең!

Иркәлеккә караганда катылыкны күбрәк эләктергән Әнис Бадигинның сынып төшүе күпләргә гыйбрәт. Кеше ихтыяры белән генә, кеше акылы белән генә яшәмә. Әгәр табигать сиңа талант биргән икән, талантыңны, намусыңны яшьтән үк сакла, күңелеңне пычратма, җирдәге үз бәхетең өчен, халык бәхете өчен нидер эшлә, тырыш, көраш. Югыйсә, гомерең буш, куанычсыз, хыялларың кысыр булыр. Повесть әнә шул турыда сөйли.

М. Маликова исә әсәрнең бу якларына игътибар итми, үз кәефенә ошамаган өчен генә, бер кизәнүдә повестьны, авторны юкка чыгара.

М. Маликова француз фольклорын яхшы белә икән. Ул бер француз мәкален бик оста һәм урынлы кулланган. Мин дә бик киң таралган икенче бер француз мәкален аның хәтеренә төшерер идем. «Бала коендыргач, ялгаштагы су белән баланы да чыгарып түкмә», диләр французлар.

Әхсән Баянов тигез генә атлап бармый. Ләкин «Син аңларсың мине» поэмасын, «Күзләре нинди иде?» драмасын, «Яшьлегемне эзлим» повестен язган Әхсән Баянов соңгы ике-өч ел эчендә әдәбиятның төп көчләренең берсенә әйләнеп баруын ачык күрсәтте. Шуның өчен без, укучылар, бала коендыргач, сабыйны да тәрәзә аша түкмик инде! Сабыр, акыллы, уйчан булыйк. Әсәрне укыгач, кулга каләм алырдан элек, әсәр турында да, тормыш турында да, стандарт тәнкыйтьчеләр турында да, үзебез турында да ныклап, акыл белән уйланыйк. Шул чагында гына без татар әдәбиятының иртәге көне өчен тыныч һәм ышанган булырбыз.

———□———

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## ОКТЯБРЬ КОЯШЫ АСТЫНДА

Әле шушы көннәрдә генә Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан китапларның берсе әнә шулай исемләнгән. Октябрь революциясенең 50 еллыгы уңае белән басылган бу китапта узган ярты гасыр эчендә республикабызда барлыкка килгән бик күп үзгәрешләр турында сүз бара. Патша Россиясендәге иң артка калган губерналарның берсе булган Казан губернасының Октябрь революциясеннән соң ничек итеп промышленность һәм авыл хуҗалыгы буенча бик нык алга киткән бүгенге Татарстанга әйләнүе хакында сөйләнә. Китап Татарстан АССРның җитәкче работниклары тарафыннан язылган. Аның авторлары: Ф. А. Табеев, М. Т. Троицкий, Л. С. Князев, В. П. Никонов һәм Г. И. Усманов.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Шушы елның 29 сентябрендә Татарстан язучылары союзы каршындагы партия оешмасының партия җыелышы булып үтте. Ул җыелыш КПСС Үзәк Комитетының һәм СССР Министрлар Советының совет халкының тормыш хәлен тагын да яхшырту чаралары турындагы 1967 ел, 26 сентябрь карары буенча фикер алышуга һәм Язучылар союзының яшь язучылар белән элемтәсен ныгыту чараларын ачыклауга багышланган иде.

Беренче көн тәртибе буенча сүз «Казан утлары» журналы редакторы язучы Р а ф а э л ь М о с т а ф и н г а бирелде.

Октябрьның 50 еллыгы алдыннан игълан ителгән бу карар бөтен илебез халкы өчен бик куанычлы һәм зур вакыйга. Бу карарны тормышка ашыру илебез хезмәт ияләренең экономик хәлен тагын да яхшыртырга ярдәм итәчәк. Дәүләтнең экономикасы һаман саен үсә, көчәя бара дигән сүз бу... Илебез хезмәт ияләре тормышын яхшыртуга юнәлтелгән бу карарның безгә, язучыларга да, бик зур файдасы тиячәк. Экономик хәле яхшырган саен, халкыбызның культура дәрәҗәсе дә үсә барачак бит. Димәк, киләчәктә халык язучыларның китапларын тагын да күбрәк укыячак. Әнә шул укучыларның таләпләрен канәгатьләндерү өчен әдипләребез киләчәктә тагын да күбрәк иҗат итәрләр, художество эшләнеше ягыннан да, идея-эстетик юнәлеше буенча да камил булган әсәрләр тудырырлар дип уйлыйбыз.

Язучылардан М и р с ә й Ә м и р, З ә к и Н у р и, И д р и с Т у к т а р, Н ә б и Д ә ү л и һәм СССР әдәбият фондының Татарстан бүлеге директоры Л и р о н Х ә м и д у л л и н да партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең илебез хезмәт ияләренең тормышын тагын да яхшыртуга юнәлтелгән карарын чын күңелдән хуплауларын әйттеләр.

Аннары җыелышта икенче көн тәртибе — яшь язучылар белән эшләү чараларын яхшырту мәсьәләсе тикшерелде.

Беренче сүз Язучылар союзы каршындагы әдәби консультант шагыйрь Илдар Юзеевкә бирелә:

— Республикада әсәрләре даими рәвештә матбугат битләрендә басылып торган йөзгә якын яшь авторлар бар. Ә әдәбиятка килергә омтылып каләм тибрәтүче башлап язучылар саны исә тагын да күбрәк. Менә шул яшь язучыларга практик ярдәм итү формаларының иң файдалысы — семинарлар үткәрү. Бу елның май аенда РСФСР язучылары союзы, комсомол өлкә комитеты һәм Татарстан язучылар союзы Идел буе яшь язучыларының зона семинарын үткәрделәр. Ул семинарга республикабыз яшь язучылары әсәрләре дә тәкъдим ителде һәм, русча сүзгә-сүз тәрҗемә ителеп, рус язучылары һәм тәнкыйтьчеләре тарафыннан да бәяләнде. Яшь шагыйрь Фәнис Яруллин иҗаты семинарда катнашкан язучыларда аеруча зур кызыксыну тудырды. Авыр хәлдә һәм хәрәкәтсез рәвештә гел урында гына ятуына карамастан, Фәниснең иҗаты һаман үсә һәм ныгый бара. Шуның өстенә ул университетта укуын да дәвам итә... Семинарда Фаил Шәфигуллин, Туфан Миңнуллин, Роберт Батуллин, Альберт Хәсәнов, Заһирә Гомәрова әсәрләре дә тикшерелде. Т. Миңнуллин һәм Р. Батуллин югары театраль белем алган яшь язучылар. Алар прозада да, драматургиядә дә эшлиләр һәм икесе дә әдәби иҗат белән җитди рәвештә шөгыльләнергә омтылучы өметле яшьләр, — диде Илдар Юзеев.

Яшь язучылар беренче чыныгуны әдәбият түгәрәкләрендә алалар. Газета-журнал редакцияләре, югары уку йортлары һәм күп кенә мәктәпләр каршында андый түгәрәкләр даими эшләп килә. Университетның әдәби иҗат түгәрәге үзенең эшен аеруча җанлы һәм кызыклы алып бара. Түгәрәк членнары, бер-беренең әсәрләрен тикшерү белән бергә, әдәби осталык мәсьәләләренә багышланган бәхәсләр дә уздыралар, авторларның үзләрен чакырып, аларның китаплары буенча фикер алышулар да үткәрәләр. Мәктәпләрдә укучылар,

авылларда колхозчылар белән очрашу кичәләре уздыралар, радио һәм телевидение буенча чыгышлар ясыйлар. Әмма бу түгәрәк членнарының күбесен шигырь язучылар тәшкил итә. Проза белән шөгыльләнүчеләр аз, тәнкыйтьчеләр бөтенләй юк диярлек. Ә тәнкыйтьчеләр безгә бик кирәк. Соңгы елларда яңа китаплар бик күп чыга, әмма, кызганычка каршы, аларның бик сирәге генә рецензияләнә. Яшь авторларның беренче китаплары да күп вакыт рецензияләнмичә кала. Моның белән һич тә килешәсе килми... «Татарстан яшьләре» редакциясе каршындагы әдәби түгәрәк тә әйбәт кенә эшләп килә. Төрле профессия кешеләрен туплаган бу әдәби берләшмәнең 25 даими члены бар. Әмма монда да жанр буенча чикләнгәнлек күзгә ташлана. Берләшмә утырышлары, нигездә, поэзия әсәрләрен тикшерүгә кайтып кала. Чөнки авыз тутырып сөйләшерлек проза әсәрләре юк. Бу — барлык әдәби түгәрәкләр өчен диярлек типик хәл. Гомумән, әдәбиятыбызга прозаикларның, тәнкыйтьчеләрнең бик аз килүе барыбызны да борчырга тиеш...

Драматургиягә килгәндә без тагын да аянычрак хәл белән очрашабыз. Бу иң авыр саналган жанрга килүче яшьләр бөтенләй күренми диярлек. Ә театрлар, үзешчән коллективлар яңа әсәрләр көтәләр. Без булган яшь драматургларга да тиешенчә игътибар бирмибез әле. Әйтик, Таһир Закиров күчмә театр белән шактый уңышлы эшли. Аның инде берничә пьесасы сәхнәгә куелды. Әмма Т. Закиров пьесаларының уңышлы һәм кимчелекле якларын күрсәтелгән бер генә рецензия дә басылып чыкканы юк. Монда драматурглар секциясе дә үзенең сүзен әйтергә тиештер. Бәлки, Т. Закировны Язучылар союзына членлыкка тәкъдим итәргә дә вакыт җиткәндер инде. Сәләтле яшьләрне Союзга тарту буенча без һаман җитәрлек эшләмибез әле.

Әдәбиятка алмашны безгә мәктәп тәрбияләп бирә. Әдәбият укыту яхшы куелган мәктәптә сәләтле укучы тизрәк ачыла. Шигырь, хикәя язучы укучыларның саны соңгы елларда бик нык артты. Әлбәттә, моңа пионер газетасы һәм журналының чыгуы зур йогынты ясады. Менә әле генә Татарстан китап нәшриятында «Иркен минем туган илем» исемле җыентык басылып чыкты. Анда укучыларның «Яшь ленинчы» газетасында чыккан шигырьләре, хикәяләре, рәсемнәре тупланган. Бик куанычлы хәл бу!

Район газеталары каршындагы әдәбият түгәрәкләрендә бик күп сәләтле яшьләр тупланган. Аларның иҗат продукцияләре район газеталарындагы әдәби сәхифәләрдә дөнья күрәләр. Ярый ла һәрбер газета редакциясендә Газиз Нәбиуллин кебек тәҗрибәле язучы утырса! Дөресен әйтергә кирәк, район газеталарының күбесендә әдәби әсәрләргә таләп йомшак. Шул ук сүзне район газеталары каршындагы иҗат түгәрәкләренә дә әйтергә туры килә. Күпчелек очракта яшь автор үз әсәренә квалификацияле анализ ала алмый. Алар тәҗрибәле язучыларның ярдәменә мохтаҗ. Мөслим районында узган әдәбият атналыгының түгәрәк өчен бик зур файдасы булды. Анда Хәсән Туфан, Фатих Хөсни, Атилла Расих h. б. катнашында түгәрәк членнарының иҗатын принципиаль югарылыкта тикшерү булды. Соңыннан бу түгәрәккә Зәет Мәҗитов консультант итеп билгеләнде һәм ул анда еш кына барып йөри.

Шундый ук иҗади сөйләшү Апас районы газетасы каршындагы әдәбият түгәрәгендә дә үткәрелде. Питрәч районы түгәрәгенә Сәрьян Хәсәнов беркетелде.

Иҗат яшьләренә игътибардан ВЛКСМ өлкә комитеты да читтә калмас дип уйлыйбыз. Бик күп еллар инде ВЛКСМ өлкә комитетының яшь язучыларны җыеп сөйләшкәне юк. Яшь язучылар семинарларын үткәрүдә комсомол да инициатор булырга тиеш. Яшь язучылар арасында әдәби конкурслар бик сирәк үткәрелә, яки үткәрелсә дә, ахырына кадәр җиткерелми. Әдәбият өлкәсендә Ленин комсомолы исемендәге республика премияләре булдыру турында да уйларга кирәктер. Башка республикаларда андый премияләр бар.

Яшьләр өчен әдәби журнал чыгару турында бик күп җыелышларда әйтелде инде. Ләкин бу мәсьәлә һаман да хәл ителми. Журнал чыгару өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Язучылар да җитәрлек, тираж өчен дә куркасы юк. Әдәби журналлар биргән доходтан гына да берничә журнал чыгарып булыр иде. Татарстан яшьләренең урынлы бу таләбен кабат-кабат тиешле оешмалар алдында күтәреп чыгарга кирәк.

Аннары Язучылар союзының Әлмәт бүлеге җитәкчесе язучы Гариф Ахунов сүз алды һәм, ачылуына нибары ун ел гына вакыт үткән булса да, бу бүлектә унлап язучылар союзы члены үсеп чыкканлыгын әйтте, күп кенә яшь өметле авторлар үсеп килүе, Әлмәт, Лениногорск әдәби түгәрәкләрендәге эшнең торышы турында сөйләде.

Яшь язучыларның иҗаты һәм алар белән элемтәне ныгыту буенча фикер алышуда язучылардан Госман Бакиров, Гариф Галиев, Ләбибә Ихсанова, Нәби Дәүли, Шамил Рәкыйпов, Самат Шакир, яшь язучылардан Рөстәм Мингалимов, Айдар Хәлимов, Әдхәт Синегулов, Туфан Миңнуллиннар катнашты. Алар күп кенә файдалы тәкъдимнәр кертү белән бергә, яшьләр өчен әдәби журнал бик кирәк икәнлеген искәртеп үттеләр.

Соңыннан Язучылар союзы идарәсе председателе Мирсәй Әмир сүз алды. Ул җыелышта сөйләнгән сүзләргә йомгак ясады һәм әйтелгән фикерләр практик эш барышында искә алыныр, диде.

## АТНАЛЫК ӘЙБӘТ ҮТТЕ

Шушы елның 18—24 сентябрендә республикабызның Апас районында татар әдәбияты атналыгы булып үтте. Октябрьның 50 еллыгына багышлап үткәрелгән бу атналыкта язучылардан Әхмәт Юныс, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Рафаил Төхфәтуллин, Аяз Гыйләҗев, Самат Шакир, «Казан утлары» журналының әдәби сотруд-

нигы Вакыйф Нуруллин, Татарстан китап нәшрияты редакторы Таһир Нурмөхәммәтов иптәшләр катнашты.

Колхозларда эшнең кызу чагы — бәрәңге һәм чөгендер алу чоры булуга да карамастан, язучылар белән очрашу кичәләренә һәр авылда халык шактый күп килде. Укучылар да, колхозчылар да язучыларның чыгышларын кызыксынып тыңладылар һәм үзләре дә аларның әсәрләрен яттан укып күрсәттеләр. Очрашу кичәләрендә татар язучыларының китапларын сату да оештырылган иде. Атналык көннәрендә меңгә якын китап сатылды. Атналыкта катнашкан язучылар үзләренең китапларын алган укучыларга һәм колхозчыларга автографларын да язып бирделәр. Борнаш мәктәбендә китап сату аеруча уңышлы үтте. Анда ике йөздән артык китап сатылды. Бу мәктәп укучылары (директоры ип. Садриев) китапны аеруча яратып укыйлар икән. Мәктәптәге 300 укучының барысы да Габдулла Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов сайланма әсәрләренең барлык томнарын да сатып алган булуы — моңа ачык шаһит.



*Әдәбият атналыгына барган иптәшләр. Сулдан: Р. Төхфәтуллин, И. Юзеев, Ә. Юныс, В. Нуруллин, Ш. Галиев, А. Гыйләҗев, С. Шакир, Т. Нурмөхәммәтов.*

## СЕЗОН МӘСКӘҮДӘ АЧЫЛДЫ

Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрының 1967—68 ел сезоны башкалабыз Мәскәүдә ачылды. Үзенең бер атналык (24—30 сентябрь) гастрольләрен ул Кремль театрында һәм Пушкин исемендәге театрда уздырды һәм башкала тамашачыларына «Чаткылар», «Фатыйма Сабри» һәм «Гүзәлем Әсәл» исемле спектакльләр күрсәтте. Шуны да әйтергә кирәк, Россия Федерациясенең милли театрлары арасында бер безнең театр гына РСФСРның культура һәм сәнгать көннәрендә катнашу бәхетенә ирешсе.

Мәскәүдән кайтуга, 30 сентябрьдә, театр яңа сезонны үз бинасында ачып җибәрде. Ул көнне тамашачылар драматург Хәй Вахитның «Күк капусы ачылса...» исемле премьерасы белән таныштылар.

## ЯЗУЧЫ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Казандагы 89 нчы мәктәпкә атаклы язучыбыз һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов исеме бирелүгә, укытучылар һәм укучылар коллективы Г. Ибраһимов музее оештыру эшен башлап җибәрделәр. Бу эштә Татарстанның атказанган укытучысы Фатыйма Җәләлиева җитәкчелек итә. Өлкән класс укучылары әдипнең тормыш юлын, иҗатын һәм иҗтимагый эшчәнлеген чагылдыра торган шактый күп материал тупладылар инде. Музей советы да төзелде. Укытучылардан һәм өлкән класс укучыларыннан музейга экскурсоводлар да билгеләнде.

## РСФСРның ИҢ ЯХШЫ МУЗЕЕ

Бөек Октябрьның 50 еллыгына багышлап, музейларга смотр үткәрелгән иде. Анда РСФСР дан 400 дән артык музей катнашты һәм күптән түгел Мәскәүдә шул смотрга йомгак ясалды. Нәтиҗәдә Татарстан дәүләт музее «РСФСРның иң яхшы музее» дип танылды. Бу исемгә тагын СССРның Революция музее, Дәүләт тарих музее (Мәскәү), Дәүләт рус музее (Ленинград), Ленинград тарих музее, Новгород музей-заповеднигы, Пушкин музее, Ярославль музей-заповеднигы, Клин шәһәрендәге П. Чайковский музее, Совет Әрмәнсенең Үзәк музее лаек булды.

## ОПЕРА ТЕАТРЫ ӘЛМӘТТӘ

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры артистлары республикабызның Әлмәт шәһәренә барып, «Кодача» исемле музыкаль комедияне сәхнәдә уйнадылар. РСФСРның халык артистлары Ф. Насретдинов, М. Булатова, ТАССРның атказанган артисты В. Галкин, артистка Ф. Тимеровалар катнашында район культура сараенда һәм Техника йортында куелган спектакльләрне әлмәтлеләр яратып карадылар. Опера һәм балет театры артистлары «Татарстан» колхозына да бардылар һәм анда үзешчән сәнгать членнары белән әңгәмә үткәрделәр.

## Хөрмәтле укучыларыбыз!

*Киләсе елда „Казан утлары“ журналы битләрендә каһарман шагыйрь Муса Җәлил турында яңа материаллар басылачак. Бу материаллардан сез Муса Җәлилнең ничек пленга төшүе, аның дошман лагерендагы көрәше, фашистлар тарафыннан ерткычларча үтерелүе, яшерен оешманы кем һәм ничек итеп сатуы һ. б. турында бик күп яңа мәгълүматлар алырсыз. Муса Җәлил һәм аның иптәшләре белән бер камерада утырган итальян көрәшчесе Рениеро Ланфредени редакциягә үзенең Берлиндагы Шпандау төрмәсендә язылган көндәлек дәфтәрен җибәрде.*

*Бу яңа материал да „Казан утлары“ журналы битләрендә басылачак.*

Җаваплы редакторы Рафаэль Мостафин

Редколлегия: Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Кил Юзиев

Производствога бирелде 15/IX-1967 ел. Басарга кул куелды 19/X-1967 ел. ПФ. 09036. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 56346 экз. Заказ М-1504. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

# ТӨНГЕ ИДЕЛ

ИЛДУС ЯКУПОВ музыкасы. РӘДИФ ГАТАУЛЛИН сүзләре.




Тып-тыныч төн, күкләр аяз,
Идел өсте зәңгәр, зәңгәр.
Асылташ нур белән балкып,
Иделенә карый шәһәр:
Идел зәңгәр.

Җиргә карап йолдыз яна,
Сиңа карап яна йөрәк.
Йөрәк яна: без эзләгән
Әллә якын, әллә ерак? —
Яна йөрәк.

Җил кагыла, чәче тузгып
Дулкынлана Идел өсте.
Зәңгәр төндә без икәүбез...
Зәңгәр матур,
яшьлек төсе,
Идел төсе...

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

# Казан утлары

**(ОГНИ КАЗАНИ)**

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210